PRESSA.RU

1926–1991 елларда **АЗАТ ХАТЫН**



2017 **АВГУСТ № 8**

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ТӨП НИГЕЗ

ул бирәү генә

ӨЙДӘГЕ ЭШ – ЭШМЕНИ

ирләр шулай уйлый, ә чынлыкта...

ЗӘМИРӘ РӘҖӘПОВА СЫЙЛЫЙ

кремлы профитрольләр

Миләүшә СӘЛАХЕТДИНОВА:

«УЙЛАР ДА, ГАМӘЛЛӘР ДӘ ЧИСТА БУЛСЫН»



PRESSA.RU



И-и ямьле туган ягым!

И-и ямьле туган ягым!
И-и ямьле туган ягым!



Минзәлә районының Татар Мөшегесе һәм Урыс Мөшегесе авыллары янындагы таудан юк, җиде түгел, ә унике (!) чишмә чыга! Салкын чишмә, Никифор чишмәсе, Тау чишмәсе... Арада иң атаклысы – Шифалы чишмә. Аның составында көмеш бар, диләр. Элек-электән, төрле чирләргә дәва эзләп, халык тирә-күрше районнардан – Мөслимнән, Актаныштан гына түгел, ераклардан – Казан артларыннан ук Изге тауга килгән. Шифалы чишмә барысына да булышкан. Бүген дә аның сукмагыннан кеше өзелми – җәен ял көннәрендә утызар машина җыела, диләр. Килүчеләрнең күбесе – чит төбәкләрдән. Теләгән кеше хәтта кыш көне дә чишмә суында коенып чыга ала, теләк теләп, дога кылырга теләүчеләр өчен мәчете, часовнясы төзелгән. Шифалы чишмә янында ук зур таш ята, шушындый ук ташларның икенчеләре – Изге тау өстендә. Әйе, хикмәтле урын бу...

Риза ИШМОРАТ

Әй, ямьле син, Минзәләм ягы!

*Кырларыңда гөрләп иген уңа,
Урманыңда балан-миләшләр.
Гөл-чәчәкләр күмгән болыннарың,
Бакчаларың тулы җимешләр.
Әй, ямьле син, Минзәләм ягы,
Синдә минем яшьлегем таңы.*

*Күңелгә дәрт бирә иртәләрең,
Моңландыра айлы кичләрең.
Җанга якын синең бөтен җирең,
Синдә минем гүзәл хисләрем.
Әй, ямьле син, Минзәләм ягы,
Синдә минем яшьлегем таңы.*

*Кешеләрең синең киң күңелле,
Ут-су кичкән көчле батырлар.
Хезмәтләре белән танылганнар,
Җырга оста, сүзгә тапкырлар.
Әй, ямьле син, Минзәләм ягы,
Синдә минем яшьлегем таңы.*

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Җитәкче-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Җитәкче урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәмматова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Миләүшә Сәлахетдинова
Фото: Анна Арахамия

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225x290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 28.07.2017 ел.
Заказ А-1790.
Тираж 5126.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU

30 АВГУСТ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨНЕ



Гамил АФЗАЛ

* * *

Безнең тарих озын,
үскән кызым,
Борыла-борыла аккан сулар кебек,
Һәр борылышта
берәр бабаң торган,
Бу камышлар шаулый шулар кебек.
Бу басуда әбиең урак урган,
Бу болында бабаң печән чапкан,
Бу урманнар һаман шаулап торган,
Борылып-борылып сулар аккан.
Сандугачлар сайрый сиңа карап,
Ай елмаеп тора зәңгәр кичен,
Җилләр исә чәчләреңне тарап,
Ак болытлар ага синең өчен.

Безнең гомер озын,
үскән улым,
Урман буйларында күксел рәшә,
Әнә сиңа мең чәчәкле болын,
Һәр бөҗәккә абый булып яшә!
Башларыннан сыйпа арышларны,
Башларыннан сыйпа куакларны,
Кабатлама безнең ялгышларны,
Кабатлама безнең гөнаһларны!

Фото: Рамил Якупов

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА








18

МИЛӘҮШӘ МӘЧЕТЕ
А. Юнысова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8

«ХӘТЕР ГЕНӘ СҮНМӘСЕН...»
М. Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





22

САБА НИГЕЗЕ
Ф. Мостафина



14

ИСКЕ ЯҢА ДӨНЬЯ
Ч. Юнысова



26

«БӘХЕТЛЕ МИН...»
Г. Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



30 ЯЗЫЛЫП БЕТМӘГӘН ПОРТРЕТ
Л. Юнысова

ЯШӘЕШ 



44 «ӨЙДӘГЕ ЭШ – ЭШМЕНИ?!»
Л. Гәрәева



48 УРТА АЗИЯ
Г. Закирова

ШУЛАЙ УК: 

32 БЕРӘҮГӘ БЕРӘҮ КИРӘК
(хикәя)
К. Кәрим

42 ӘЙТЕГЕЗЧЕ, МӘТРҮШКӘЛӘР
Э. Закирова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



60 БЕЗ ҮЗЕБЕЗ ЧҮЛМӘКЧЕ

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА:

САРМАН МИЛӘҮШӘСЕ. ИГЕЛЕКНЕҢ ЧИГЕ ЮК.

ГАФУ ИТӘРГӘ КИРӘК. БАРЫСЫН ДА! ИР ФИКЕРЕ.

«КЫҢГЫРАУЛЫ МӘКТӘП ЕЛЛАРЫ». БЕР ҖЫР ТАРИХЫ.

ЗИНИРА ҺӘМ РИЗАТ РАМАЗАНОВЛАРДАН МАСТЕР-КЛАСС.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Мондый бәйрәмнең Каратай авылында булганы юк иде әле. Сабантуйлары да районда гына уза хәзер, бара алганы – шунда барып карый, бара алмаганы – телевизордагы тамашага гына да риза.

Бәйрәмнәрсез авыл ятим кебек икән ул. Күңел балачактагы Сабантуйларны, җыеннарны сагына, урам тутырып мәйданга агылган кунакларны, гармун, җыр тавышларын юксына икән...

Авылдашыбыз, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге мөдире, әдәбиятчы-текстолог, галим Зөфәр Рәмиевнең дә күңелен бу хәл әрнеткән булган. Үзебезнең авылда да бәйрәм оештырыйк, дип, авыл Советы рәисе Хәмидуллин Мөниргә мөрәҗәгать иткән ул. Мөнир Габдулла улы, аның бу гозерен кире какмыйча, оештыру эшләрен башлап йөрүне үз өстенә алган. Бу тәкъдимгә авылдашлар да кушылган, беркем дә, безгә ник кирәк бу бәйрәм, димәгән, кулыннан килгәнчә һәркем ярдәм итәргә тырышкан.

Ниһаять, көткән бәйрәм көне дә килеп җитте. Авылыбыз урамнары ничә елга беренче тапкыр җыр-моң, гармун тавышларына күмелде – Кама Тамагы районы, Каратай авылында (халык телендә атамасы шулай булса да, рәсми документларда Уразлино булып йөри) авыл бәйрәме гөрләде. Яшел мәйданга авылдашлар, кайткан кунаклар, тирә-күрше авыллар агылды. Ай-һай, күңел юксынган булган икән лә мондый очрашуларны! Ничә еллардан бирле күрешмәгән дуслар, танышлар, авылдашлар, классташларны күрештерде бит бу бәйрәм. Көне дә сорап алган шикелле, көяшлы – чын җәйге көн иде. Тукаебыз әйтмешли, җиле дә бәйрәм көен көйли иде кебек.

Авыл бәйрәме дисәләр дә, чынында Сабантуй рухында узды ул. Шундый ук уен-көлке, җыр-моң, тальян тавышлары, балаларның күңелле чыр-чуы... И рәхәтләнде инде бу көнне балалар. Аларга әллә никадәр уеннар әзерләгәннәр. Чүлмәк тә ваттылар, кашыкка йомырка да салып йөгерделәр, күз бәйләп бүләк тә кистеләр, капчык киеп тә сикерделәр. Билгеле, өлкәннәр дә читтән генә карап тормады. Көянтәле чиләкләр белән тамчысын да төшермичә су ташулар онытылмаган икән әле. Ерак араларны якын итеп кунакка кайткан кызлар да, ханымнар да, апалар да берсен-берсе уздырып, су ташыды, чүлмәк ватты, капчык киеп йөгерде...

Кама Тамагы муниципаль район башлыгы урынбасары Владимир Сороковнин котлау сүзе белән башлап җибәргән бәйрәмне бик матур, җанлы һәм ихлас итеп Гөлшат Шәрәфетдинова алып барды. Галим Зөфәр Рәмиев тә сүз алып, авылдашларны, кунакларны бәйрәм белән котлады. «Мин бик мәмнүн булдым», – дип, авылдашларның тырышлыгына югары бәя бирде ул.

Дөрестән дә, сокланырлык һәм мактауларга лаек иде Каратай халкы. Мәйданда уеннар кызса, сәхнәдән дәртле җырлар, халык көйләре, гармун моңнары яңгырап торды. Авыл халкы үзе дә талантларга бай икән дип, чын күңелдән хозурландым. Дания Мәүләтшина, Нурсия Мәрдиева, Гөлүсә Вәлиуллина, әтиле-кызлы Эльза белән Хәниф Гарифуллиннар җырлаганда йөрәкләрне иркәләп, рәхәт дулкыннар узгандай булды... Гармун моңнары булмаса, нинди генә күңелле бәйрәмнең дә яме булмас иде кебек. Авылның мөхтәрәм агасы, заманында данлыклы механизатор – гармунчы Хәмит Гафуров, бәйрәмгә ямь дә, нур да, моң да өстәп, күңелләрне тибрәтте, дулкынландырды...

Ә мәйдан артында табын гөрләде. Өстәлләр мул, табыннар түгәрәк, күңелләр көр иде. Самавырлар җырлады, учакка асылган казанда телне йотардай тәмле пылау пеште, балаларга да, өлкәннәргә дә, авыл активистларына да күчтәнәчләр мулдан өләшенде. Шушыларның барысын да үз көчләре белән башкарып чыккан Каратай җирлегенә, Мөнир Хәмидуллинга сокланырлык. Табыннарны әзерләшүче апалы-сеңелле кыз туганнар Гыйләҗева Гөлназ, Гыйззәтова Гөлнур, Закирова Нурания һәм башка уңган ханымнар авылдашларының күңелен күреп, һәркемгә күркәм игътибар күрсәттеләр.

Бәйрәмнән бик күңелебез булып, Зөфәр абый әйтмешли, мәмнүн булып таралыштык. Без таралыштык, ә кичен авылның өлкән буын тиңдәшләре, яшьлекләрен искә төшереп, кабат мәйданга җыелган. Әнә, күршебез Рауза апа да, Хәлимә апа да, җил-җил атлап, шунда таба ашыгалар... Өздереп-өздереп сузган җырлар таңга кадәр тынмады...

Тымызык кына җәйге кичтә йолдызлардан коелган нур сыман булып ишетелгән гармун тавышлары җырлы-биюле яшьлегемнең кайтавазы, кайнар сәламе булып тоелды...

Фирдәвес ИСМӘГЫЙЛЕВА.
Каратай (Уразлино) авылы.



Авылына туфлидән генә кайтып, асфальт юллардан керт-керт кенә басып йөргән хезмәттәшләремә карап шулкадәр кызыгам. Безнең авыл урамнарында да бер булыр микән ул асфальт юллар, дим.

Дөрес, үзәк урамының яртысына асфальт түшәлгән түшәлүен. Тик авылның башка урамнарында да кешеләр яши бит. Асфальт булмаса, таш түшәлгән булса да, риза булыр идең әле.

Быел авылда Сабантуй иллә дә яңгырлы атнага туры килде. Яңгыр дип торып булмый, бәйрәмгә кайтасы килә. Хәер, Казан–авыл арасын атна саен гына түгел, атнага ике дә, өч тә урарга туры килә. Туган нигезне ташлап булмый, чүп басып, нәүмиз ятмасын дип, бакчасын да утырткан булабыз, җәйге елларыбыз да шунда уза. Үзебезчә, авылдагы тагын бер генә йорт булса да яшәсен, бер генә тәрәзәдә булса да ут янсын дибез. Тик... кайтканда – бер, киткәндә – бер җан өшеп, кот очып тора. Кайтканда авылга кереп булырмы, дисең, киткәндә инде чыгалырбызмы дип борчыласың.

Безнең урамга җиңел машина белән җәйге корыда һәм көз көне җир катырып, кар тирән ятканчы гына кереп була. Башка вакытларда машинаны чатта калдырып, аякка тирән эчле галошларыңны алып киясең дә, күчтәнәч салган букчаларыңны аркага асып, җәяү тәпилисең. Кире киткәндә инде, иңбашыңда бәрәңгеле капчык, култык астында тозлы кыяр банкасы, аякта һаман шул тирән эчле галош... XXI гасырда бит бу!!! Кешелек космоска чыккан заманда авыл эченә кереп булмасын инде? Нефтьле республикада?! Арчада, зурдан кубып, асфальт заводы ачылган заманда?! Элек мәдрәсәсе белән дан тоткан, XVIII гасыр архитектура үрнәге булып сакланган борынгы таш мәчетле Кышкар авылында?!

Арчага ераграк урнашкангадыр инде, республиканың дәүләт программалары безгә кадәр килеп җитә алмый, дисәм, һәр авылны үзәк юлга тоташтыру программасы үтәлгән икән. Тик кайсы акыллы башының фикере булгандыр инде, асфальтны мәктәп, медпункт, авыл Советы, почта урнашкан һәм Кышкардан ике генә чакрымдагы Яңа Кишет белән ике арага түгел, Симетбаш дамбасына түшәделәр. Яңа Кишеттәге ак кирпечтән салынган ике катлы өр-яңа урта мәктәпне укучыларсыз калдыруда шушы юлның да тәэсире зур булды. Кышкар халкы, балаларын бата-чума Кишеткә төшергәнче, сигез-тугыз чакрымдагы Яңа Кырлай мәктәбенә йөртә хәзер. Шулай итеп, ике куянны бергә тота ул. Беренчедән, 10-11 нче сыйныфларга барыбер Кырлайга барырга кирәк (мәктәпләрне оптимальләштерү безгә дә кагылды), ә болай, кечкенәдән иптәшләренә дә, укытучыларга да күнегә; икенчедән, балаларны Кырлайга кадәр автобус алып бара, алып кайта, ә Кишеткә ул әле җәяү тәпиләр иде. Асфальт булмагач, автобус ул юлга керә алмый.

Авыл Советына гозере төшсә, ә ул гел төшеп тора, Кышкар халкы хәзер тавыклары кытакласа безгә ишетелеп торган Кишеткә егерме чакрым урап барырга мәҗбүр. Авыр эштән аяклары беткән ул апалар пычрак ерып ничек үтсен ул юлны? Шуңа да алар, балалары кайткач, машина белән Симетбаш аша урап барып кайта авыл Советына. Ике арада юл булмагач, шулай йөрми хәлең юк. Бару-кайтуны исәпләгәч, авыл Советына сәфәр кырык чакрымга тула. Ул апалар әллә шушы җирне бөтәйтү өчен көч куймаганмы, тир түкмәгәнме? Хәзер алар онытылган утраудагы кебек...

Авыл юлларына вак таш җәю программасын ишеткәч, и безнең сөенүләр! Таш кына түшәсәләр дә риза булыр идең. Авыл урамындагы чокырларга тулган сазны кичү өчен көймә кирәк булмагае әле берзаман. Яз җиткәч, яз булмасмы; җәй җиткәч, җәй булмасмы, дип, бик көткән идек. Язлар да үтте, инде җәй дә үтеп бара, урамнар да шул килеш, чокырлар да...

Юлсызлыгына да, сусызлыгына да күндек бугай инде. Дуңгыз фермасы беткәч, Кышкарның Казаклар очы ничә еллар сусыз яшәде. Авылдагы бердәнбер һәм хан заманында ук буралган коедан су ташып җәфаландык та, һәрберебез үз ишегалдына кое бораулатырга мәҗбүр булды. Республикадагы «Чиста су» программасы тагын безгә кадәр килеп җитә алмады. Гәрчә Арча муниципаль районы башлыгы Илшат Нуриев бу мәсьәлә белән таныш булып, су булырга тиеш дисә дә. Ярар инде, болганчык булса да, үзебез казыткан коеларның суы гына бетеп китмәсен. Тик менә шул юллар... Күрше-тирә хуҗалыкта мич сүтәбезме, түбә алыштырабызмы, таш, кирпеч, шиферны урамдагы чокырларга тутырган булабыз да, бездәге чокырларны алай гына күмеп бетерерлек түгел шул.

Элегрәк «Вамин»да булган җирләребезне Әтнәләр алган икән. Халык, өметләнеп, шул тарафтан ярдәм көтә. Боларыннан булмады, бәлки, яңалары бераз булышыр авыл юлларын рәтләргә? Югыйсә ул ташны Айдан ук төшерәсе дә түгел. «Нишләсе, кычкырсаң, кеше ишетәсе», дияр иде дәү әнием, мәрхүмәкәем. Кычкырмый да булмый шул. Син дә әйтмә, мин дә әйтмә, кемдер берәү сүз башларга тиештер инде.

Лилия ГӘРӘЕВА.
Арча районы, Кышкар авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU

Заманында без, журналистлар, аны кем генә һәм ничек кенә дип атамый идек: ул – сессия утырышларын көтелмәгән юнәлешкә кертеп җибәрү кодрәтенә ия булып, «фикерен өздереп әйтә белгән усал телле уңайсыз депутат» та, ул – «олы ышаныч казанган халык илчесе» дә, ул – 54 яшендә хәрби эшен калдырып, зур сәясәткә чумган «чын полковник» та... Ә шулай да аның исеме тирәсендә йөргән сүзләрнең күбесе татарның язмышын тамырдан үзгәртеп җибәргән (һәрхәлдә, без моңа ул чагында нык ышана идек) вакыйгаларга бәйле була торган иде. Сүзебез – бу үзгәрешләрнең беренче көннәреннән үк республиканың статусын күтәрү өчен көрәшнең алгы сызыгына баскан экс-депутатыбыз Фәндәс САФИУЛЛИН турында...

Ул үзе турында: «Миндә гаделлек хисе нык көчле», – ди. Шуңа да аның, Казан танк училищесында булачак офицерларга тыныч кына лекцияләр укып йөргән җиреннән, кайнап торган сәясәт дөньясына ташлануына бер дә гаҗәпләнмим. Ул башкача булдыра алмаган да. Ул – шундый. Дөньяда барган хәлләргә тыныч кына, арка куеп кына яши алмый.



«ХӘТЕР ГЕНӘ СҮНМӘСЕН...»



Мәдинә АВЗАЛОВА

«МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК», «СУВЕРЕНИТЕТ» ДИП УТ ЙОТЫП ЙӨРГӘН ЧАКЛАРЫБЫЗ ИСКӘ ТӨШӘ. ЧИРЕК ГАСЫРДАН АРТЫК ВАКЫТ ҮТКӘН. Ә БАРЫСЫ БҮГЕНГЕДӘЙ КҮЗ АЛДЫНДА.

Гасырлардан килгән бер хыял

Ирек мәйданы кайнап торган казанны хәтерләтә. Югары Совет сессиясе барган көннәрдә анда егермешәр-утызар меңләп халык җыела. Һәркайсының кулында лозунглар, плакатлар... Барысы да Татарстанга мөстәкыйльлек даулый. Ә каршыдагы мәһабәт таш бинада әнә шул мәйдандагы умарта оясыдай гөжләп торган халыкның язмышы хәл ителә. 1990 ел августының соңгы көннәре... Ниһаять, без хокукларыбыз турында урамнарга чыгып, парламент мөнбәренә менеп әйтер дәрәҗәдә өлгердек. Максатыбыз да әйтеп калу гына түгел, шуңа ирешү ләбаса!

Ә бит моның өчен безгә күп еллар узарга, гасырлар кичәргә туры килде. Мөстәкыйльлек идеясе тиктомалдан барлыкка килмәде. Бу безнең күптәнге, бик күптәнге хыялыбыз иде. Шул вакыйгаларны берәм-берәм күз алдыннан кичереп, үзенең тыныч, әмма ышандыргыч, көр тавышы белән салмак кына сөйләп утырган әңгәмәдәшем республиканы, кем әйтмешли, утлар, сулар кичеп, бүгенге көнгә китереп җиткергән дулкынландыргыч та, гомергә истә калырлык итеп сискәндергән дә ул көннәрне сәгате белән генә түгел, минуты белән хәтерлидер сыман.

– Дәүләтчелегебезне тергезү идеясе безнең халык күңелендә ничәмә-ничә гасырлар яшәгәндер ул, – дип башлый сүзен мәшһүр экс-депутатыбыз. – Әгәр дә «милли үзбилгеләнү» төшенчәсе яңгырамаса, Октябрь революциясендә большевиклар җиңеп чыга алмас иде. Ул төрки халыклар, шул исәптән, татар халкы күңелендә дә мөстәкыйль яши башлауга зур өмет уятты. Һәм бер генә минутка да сүрелмәде. Чөнки тигез хокуклылык дигән нәрсә күңелләргә нык беркетелгән булган. Башта, белгәнебезчә, СССР составына дүрт союздаш республика – РСФСР, Украина, Белоруссия һәм Закавказье Федератив республикалары керде. Аннары аларның саны уналтыга җитте. Татарстан белән Башкортстанга андый статус бирелмәде. Конституция буенча союздаш республика статусын алу өчен без чит дәүләтләр белән чиктәш булырга тиеш булып чыктык. Шул бер җөмлә белән безнең юлны кистеләр. Тик, ничек кенә булмасын, бу фикер югалмады. Сугыш елларында ул турыда уйларлык булмады булуын. Ә менә бөек үзгәртеп кору чоры башлангач, безнең партия җитәкчеләре (Гомәр Усмановны әйтүем) янә бу темага әйләнеп кайттылар.

1989 елларны хәтерлисезме?! Нәкъ шул елны Татар иҗтимагый үзәге оешты. Татарстанны союздаш республика итү идеясенә бөтен җәмәгатьчелекне җәлеп итә алды. Моны бөтен авыллар, районнар күтәреп алды. Җитди хәрәкәт, җитди үзәк иде бит ул!

Халык сайлаган депутатлар

Республика елъязмасына моңарчы күрелмәгән вакыйгалары белән уелып калган 1990 елның марты. Татарстан Автономияле Республикасының Югары Советына сайлаулар бара. Фәндәс Сафиуллин ул сайлауны «тарихта беренче һәм инде башка андый булмаган чын демократик сайлау» дип атый. Тормыш, сайлау тәҗрибәсе, чыннан да, шуны күрсәтә. Югары Советка депутатлыкка кандидат итеп теркәлгән 250 депутатның күбесе Татарстанны союздаш республика итү өчен көрәшәчәген белдерә. Фәндәс Шакир улы Сафиуллинның сайлау алды программасына да шундый җөмләләр кертелә.

– Әйе, чыннан да, – дип дәвам итә сүзен әңгәмәдәшем, – «Татариягә союздаш республикалар дәрәҗәсендәге хокуклар һәм мөмкинлекләр, илнең башка регионнары белән бертигез хокуклар бирү»; «Республикада яшәүче барлык милләт халыкларын тигез хокуклар белән тәэмин итү, милләтара, милли һәм дини дошманлык чагылышларын кискен кисәтү»; «Милли мәдәниятне, тел һәм мәктәпләрне үстерү өчен шартлар тудыру» өчен көрәшәчәкмен, дидем. Бу чакырылышта «Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларация» кабул ителде. Аны без референдум аша раслый һәм үзебезнең Конституциябез аша беркетә алдык. Ә Югары Советның уникенче чакырылышына сайлау, чыннан да, демократик, халыкчан булды.

Тулы хокуклы союздаш республика булып яшәү – безнең дә тормышка ашмый килгән хыялыбыз иде.

Сайлау өчен хәзерге кебек миллионлаган сум акча да кирәкми иде. Ишегалдына халык җыела да үзенә ошаган, ышаныч белдергән кандидатны күрсәтә. Авылдан сайланган булсам, юлга күпмедер акча кирәк булган булыр иде. Ә болай... Казан шәһәреннән, үзебезнең училище коллективы күрсәткәч, андый мәсьәлә тумады. Без бер округтан алты кандидат идек: арабызда элеккеге хөкүмәт рәисе дә, республиканың прокуроры да, комсомол җитәкчесе дә, психик авырулар хастаханәсе баш табибы да бар иде. Ә мин исә отставкадагы полковник, пенсионер... Гомумән, мин өч мәртәбә сайлануымның өчесендә дә: «Сезгә дә, үземә дә хыянәт итмәм, бер сайлап алган сәяси кыйбламнан тайпылмам!» дип вәгъдә бирдем. Ул вәгъдәмне булдыра алганча Татарстанның Югары Советында да, Дәүләт Советында да, Россия Думасына депутат булып сайлангач та үтәргә тырыштым.

Әле дә хәтердә: 1990 елның язы-җәе менә-менә булачак зур вакыйгаларны көтеп узды. Хәер, көтеп кенә микән? Шул вакыйгаларга әзерлек белән дисәм, дөресрәк булыр. Дәүләт статусын күтәрү турындагы мәсьәлә Югары Совет ишекләрен каерып ачып, төрле оешмаларга, хезмәт коллек-

PRESSA.RU

тивларына барып иреште. Үз фикерен белдермәгән бер генә кеше дә калмагандыр, мөгаен. Ул вакытларда без – журналистлар да ут йотып яшәдек. Ничек булыр, ни белән бетәр? Кем нәрсә әйтер? Кайсы депутат кем ягында булыр? Кыскасы, матбугатта бу тема көн үзәгеннән төшмәде. Һәм, ниһаять, көтелгән көн килеп җитте. Август ахырына ТАССР Югары Советының тарихи сессиясенә төрле авторлардан Декларациянең төрле проектлары керде.

Ул тарихка Татарстанның суверенитеты өчен көрәшкә зур өлеш керткән олы шәхесләрнең берсе буларак кереп калыр.

Исеме матур, кемнәр куйган...

– Ул көнне ничек онытасың?! – ди Фәндәс абый, – исегездәме, дип башлаган соравыма. – Декларация буенча биш проект керде. Утырышта бер көн бәхәсләшкәннән соң, уртак проектны расларга карар кылынды. Килештерү комиссиясе әгъзаларына – шуны эшләмичә, бүлмәдән чыкмаска. Шундый катгый таләп менә. Комиссиягә юристлардан, галимнәрдән, белгечләрдән торган 29 кеше кертелде. (Бу сан һәрчак так булырга тиеш.) Сессия бара. Шулчак депутат Анатолий Васильев микрофонга йөгереп чыкты да: «Мин бу комиссиягә Фәндәс Сафиуллинны тәкъдим итәм», – дип ярып салды. Залдагылар гөрләтеп кул чаба башлады. Ә утырышны алып баручы Минтимер Шәймиев: «30 нчы булып барса, 31 нче кеше дә кирәк булачак бит аннары», – ди. Үзе дә аптырашта калгандай булды, тик соңыннан килеште тагын. Ләкин: «Тавышка куйыйк, әгәр бер генә кеше каршы булса да, үтмәячәк» дигән катгый шарт куйды. Ни дип уйлыйсыз?! Үттем бит. 250 депутатның 250 се дә миңа тавыш бирде.

Әңгәмәдәшем бер мәл тын калып тора. Алай гына түгел, депутатларны «Декларация» проекты белән таныштыруны да Фәндәс Сафиуллинга йөкләделәр. «Татар рухлы кеше укысын...» – диләр. Ә аңарчы... ТАССР Югары Советының 29 август көнне башланган икенче тарихи сессиясендә «Татарстанның дәүләт суверенитеты» турындагы мәсьәлә буенча чыгыш ясарга әзерләнгән депутатлар арасында ул үзенең тирән фикерләве, каршы әйтә алмаслык дәлилләр китереп сөйләве белән янә залдагыларны хәйран итә. «Әйе, – ди ул, – суверенитет ул – чыгу дигәнне аңлата. Ләкин Россиядән, ягъни Советлар Союзыннан чыгу дигән сүз түгел ул. Ә бәлки, мафиоз ведомстволарның чикләнмәгән хакимлегеннән котылуны аңлата. Безне үз программабыз булмауда гаеплиләр. Ә нигә безгә ул? Без Ельцинның программасын да алырга риза. 100 проценты белән... Без аны боерганнары өчен түгел, безгә барганы өчен кабул итәргә әзер. Суверенитетның мәгънәсе дә шунда». Ә республиканың исемен ул «совет» дип тә, «социалистик» дип тә түгел, «Татарстан Республикасы» дип исемләргә тәкъдим итә. Бер генә капиталистик ил дә үзен «капиталистик» дип атамый бит. Депутатлар аны бу юлы да көчле алкышларга күмә. Шулай инде. Дөрес сүзгә җавап юк.

«Урамда халык көтә. Бүген кабул итик, дидем»

– 30 август, кичке сәгать тугызлар. Без әле һаман Декларация проектын камилләштерү, килештерү белән мәшгуль. Кайберәүләр: «Әллә иртәгәгә калдырыйкмы?» – дип тә әйтә башладылар. Шунда мин кискен каршы чыктым: «Әгәр дә 31 енә калдырсак, халыкның кәефе үзгәрә башларга мөмкин, урамда безне халык көтә. Төнге уникегә кадәр мәсьәләне хәл итик, дидем. 30 август – ул безнең тарихка Татарстан бәйрәме көне булып кереп калырга тиеш», – дидем. Озак утырдык, әллә алтыҗиде сәгать шунда... Әмма проектны эшләп бетергән вакытны сәгатенә-минутына кадәр хәтерлим: 22 сәгать 45 минут иде. Аннары комиссия исеменнән тавышка куярга әзер Декларация проектын игълан иттем. Укыганда дулкынланудан баш әйләнеп китте. Халык кул чаба, ә мин, кинәт югалып, каршыларында басып торам. Гомеремдә онытасым юк ул минутларны...

Фәндәс Сафиуллинның укып бетерүе булды, бөтен зал аягүрә торып, кул чаба башлады. Күзләргә яшь килде. Әйтерсең, без инде максатыбызга ирешкәнбез. Без дә редакцияләребезгә кайтып, төнге сәгать уникедә коридор буйлап «без суверен дәүләт» дип кычкырып йөрдек. Бу – депутатларның гына түгел, барча халыкның уртак уңышы, уртак казанышы иде. Әмма көрәшләр дә, әйткәнемчә, алда иде әле. Гәрчә, әңгәмәдәшем Югары Советтагы «Народовластие» төркемен көчле оппозиция, ул булмаса, «законнарыбыз йомшак булыр иде, без кирәк түгел, дип уйлаган законнар керми калган булыр иде, алар аркасында без төгәл эшләнгән, юридик яктан дөрес документлар кабул иттек», дип торса да, Декларациягә шик белдерүчеләр, аңа шикләнеп караучылар, беренче чиратта, алар булды. Татарстанда төрле милләт халкы яши. Күпләрнең яңа статусның рухыбызны, мәдәниятебезне, телебезне саклап калуга юнәлтелгән булуына исләре китмәде. Татар халкы өчен ул – яшәү белән үлем шикелле... Бу төркем депутатларыннан: «Халыктан сорамыйча кабул иттеләр. Моның нигезе юк», – дигән хәвефле сүзләр дә ишетелгәли башлады.

«Халык үз фикерен белдерде»

– Мин үзем референдум үткәрүгә баштан ук каршы идем, – ди Фәндәс абый, Мәскәү ягыннан салкын җилләр исә башлаган ул көннәрне искә алып. – Бер илдә дә андый хәлнең булганы юк иде бит

әле моңарчы. Тәвәккәлләдек, дөресрәге. Чөнки бу – бик җаваплы, хәлиткеч адым иде. Әгәр дә референдумда җиңеп чыкмасак, безне ни көткәнен күз алдына да китерүе кыен иде. Ул арада Россия матбугаты: «Татарстан Россиядән аерылып чыгу турында референдум үткәрә», дип сөрән салды. Ул да булмады, моңарчы «референдум кирәк» дип торган мәскәүлеләр безне, аерылып чыгарга телисезме, дип, гаепли башладылар. Президент Борис Ельцинның, Генераль прокурорның «референдум үткәрмәскә», дигән фәрманы килде. Кыен хәл: үткәрсәң дә ярамый, үткәрмәсәң дә ярамый. Ләкин инде тарих тәгәрмәче зур тизлек алган иде, референдумны үткәрмәү турында сүзнең булуы да мөмкин түгел иде. Дөресен әйткәндә, аны туктату да мөмкин түгел иде. Безнең прокурор: «Сайлау участокларын ачмаска», – дип карады каравын. Әмма участоклар минутына кадәр соңга калмыйча ачылды. Референдум көнне чамалыйсыздыр инде безнең хәлне: ут өстендә булдык, аның нәтиҗәсен белмичә, беребез дә өйләргә таралышмадык. Җитәкчеләребез ул көннәрдә өйләрендә кунмады. Аларны кулга алып бик каты үгетләмичә, референдумны туктатып булмый иде инде. Без 61,4 процент тавыш җыеп, җиңүгә ирештек.

Ни дәрәҗәдә мөстәкыйль?

Тормышларыбызны, ә бәлкем, кемнәрнеңдер язмышларын да тамырдан үзгәртердәй ул көннәрдән соң чирек гасырдан артык вакыт узып китте. Мөстәкыйль яшәүче дәүләтнең асылын, барлыгын социаль-икътисадый казанышлар, мәдәниятнең, мәгарифнең, сәнгатьнең үсеше чагылдыра. Бүгенге көндә Татарстанның сәяси абруе үскәннәнүсә бара: Татарстанның чит илләрдәге һәм Россия төбәкләрендәге вәкиллекләре, Бөтендөнья татар конгрессы оешу, Казанда уздырыла торган төрле Дөнья чемпионатлары, халыкара фестивальләр, күргәзмәләр шул хакта сөйли.



■ «Россия белән мөнәсәбәтләр үзгә, үзенә бертөрле булырга тиеш, – ди Фәндәс Сафиуллин чыгышында. – Декларация кабул иткәч, алар махсус закон белән беркетелергә тиеш. Россиядән аерылуның ике генә юлы бар: күккә ашу яисә җир астына төшү».



■ Әйе, ТАССР Югары Советына уникенче чакырылыш сайлау – ул Татарстанда парламент демократиясенең, законнар чыгаручы хакимиятнең һәм халыкның бердәмлеге, сүз һәм фикер ирекге тантана иткән беренче һәм бердәнбер бишьеллык булды.



■ Референдум мәсьәләсендә Фәрит Мөхәммәтшинны Мәскәүгә чакыртып алдылар. Бер төн эчендә Мәскәүдән Казанга килеп җиткән хәрбиләр ТАССР Югары Советы Рәисе урынбасары Зилә Вәлиеваны Россия Федерациясенең Конституция Суды карары белән куркыттылар. Аның бу вазыйфаны үти генә башлаган чагы. Ләкин ул нык торды, артка чигенүләр мөмкин түгел иде.



■ Татарстан халкы суверен дәүләт булып яшәүнең сөйләшү-аңлашуларга корылган тыныч юлын сайлап, үзенең сәяси өлгергәнлеген күрсәтте. Аның 1992 елда кабул ителгән Төп законы – Конституциясе, Декларация һәм референдум нәтиҗәләре, флаг, тугра, гимн кебек дәүләт символлары бар. 1994 елда бик тә мөһим булган тагын бер документы – ул да булса Россия Федерациясе белән үзара вәкаләтләрне бүлешү турында Шартнамәсе булдырылды, ә 2007 елда ул, шактый йомшартылып булса да, озайтылды.

PRESSA.RU

– Кызганыч, әле ул чагында ук милләтебезнең белемен, аң дәрәҗәсен, мәдәниятен үстерүне, әхлакый һәм рухи сәламәтлеген ныгытуны төп бурычыбыз итеп куя алмадык. Иң үкенечлесе – Югары Советның 1994 нче елларда ук кабул иткән Татар дәүләт милли университетын булдыру турындагы карарын тормышка ашыра алмадык. Гаеп үзебездә түгел микән... Милли мәгариф системасын булдырмадык (үзебезнең үк татар канлы этиәниләребез «Мәктәптә татар теле кирәкми», дип кычкырып торганда мөмкинме соң бу?!). Монысын да Мәскәүгә сылтый алмыйбыз. 1990–1999 нчы еллар – иркле елларыбыз иде. Вакытыбыз да, мөмкинлекләребез дә бик мөһим милли проблемаларыбызны кирегә бора алмаслык итеп хәл итәргә җитәрлек иде. Суверенитет өчен көрәшнең төп стратегик максаты – милләт буларак татарны, аның милли-мәдәни нигезен саклап калу һәм үстерү иде. Башка милләтләр өчен безнең суверенитет ул кадәр җитди мәсьәлә түгел бит. Алар өчен ул: «Суверенитет дигән нәрсәдән тормышыбыз кайсы якка үзгәрер икән?» дип, нигезле борчылу өчен сәбәп кенә. Шуңа күрә тормышыбызны беркем дә борчылмаслык, кимсетелмәслек итеп яхшырту – болар безнең уртак бурычыбыз иде. Республика җитәкчелеге бу юнәлештә шактый көч куйды, безгә үзебезгә дә бүген милли мәнфәгатьләребезгә битараф, ваемсыз булмаска иде.

Тарихи хәтер сүнмәсә, киләчәккә өметебез сүнмәс. Ә милли рухын саклап калган халык үзен дә саклап калыр, гаделлек, мөстәкыйльлек өчен көрәштә, һичшиксез, үз максатына ирешер.

«Дәүләтчелеген югалтуның төп сәбәпләрен аңларга теләмәгән халык аны яңадан торгыза алмаячак».

ҮЗ ЙӨЗЕБЕЗНЕ ЮГАЛТМЫЙК



Дөньяларның иминлеге, тормышларның бөтенлеге, яшәүнең матурлыгы — татулыкта, милли үзенчәлекләрне хөрмәт итүдә, гасырлар буе сыналган гореф-гадәтләрне саклауда.

Шулай буласын белеп бардым. Аның белән очрашканда сүзне кайсы очтан башларга, дип баш ватып торасы юк. Ул үзе белә. Әңгәмәне башлап кына җибәрәсең... Ул иң кирәкле темага җавапны көтелмәгәнчә, төгәл, үзенчә итеп әйтеп бирә. Менә бу юлы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хакимият органнары арасында вәкаләтләрне бүлешү турындагы Шартнамә белән шактый четерекле хәл килеп чыкты. 2007 елда имзаланган Шартнамәгә 10 ел вакыт узып китте, ә яңасы һаман төзелми. Шул уңайдан Татарстан Дәүләт Советы депутатлары Россия Президенты Владимир Путинга мөрәҗәгать белән чыктылар. Мөнәсәбәтләрне яңабаштан кору юнәлешендә эш башлана гына әле. Әңгәмәдәшем – республика язмышы хәл ителгән киеренке елларда Татарстан Югары Советы Рәисе урынбасары, аннары министр, Премьер-министр урынбасары вазыйфаларын үтәгән шәхес, «Татарстан хатын-кызлары» оешмасы җитәкчесе, «Казан кирмәне» музей-тыюлыгы башлыгы **Зилә Рәхимҗан кызы ВӘЛИЕВА** фикеремне эләктереп ала да, республика тарихында онытылмас эз калдырган ул көннәргә әйләнеп кайта.

ДӘҮЛӘТ ЭЧЕНДӘ ДӘҮЛӘТ БУЛАМЫ?

– Төбәкләрнең үзенчәлеген исәпкә алу – гайре табигый хәл түгел. Ул бөтен дөньяда шулай. Бигрәк тә федератив илдә. Югыйсә нинди федерация була инде ул?! Әле күптән түгел генә Краковка ЮНЕСКО утырышына барганда, Хельсинкига керергә насыйп булды. Бу унитар илдә фин һәм швед телләре дәүләт телләре булып игълан ителгән. Хәлбуки шведларның саны 8 процент кына булса да. Безне йөртүче гид үзе дә ике телне яхшы белә. Ул биредә бик күп татарлар яшәвен әйтеп тә гаҗәпләндерде. Финляндия дәүләте Европаның телләр турындагы хартиясенә кергәндә, татар телен төбәк теле итеп рәсмиләштергән. Кызганычка, безнең илдә бу хартия ратификацияләнмәгән, чөнки телләрне саклау гарантияләрен үтәү шактый четерекле нәрсә.

Мине тагы бер нәрсә хәйран итте: Финляндиянең бер утравында үзенчәлекле кавем яши икән. Шул кавемнең борынгы төсмерен, горефен саклау өчен, утраудагыларның егетләрен фин армиясенә алмыйлар икән. Һәм берәү дә моңа гаҗәпләнү дә, канәгатьсезлек тә белдерми. Табигый хәл буларак кабул итә.

Гомумән, зирәклеге, акылы булган һәркем катлаулы вазгыятьтән чыгу

юлын килешү аша эзләп тапкан шикелле, алга карап эш иткән дәүләтләр дә мөнәсәбәтләрне бары килешү юлы белән хәл итәләр. 1990 елларда без моны нәкъ шундый юл белән башкарып чыга алдык. Татарстанның мөстәкыйльлеге турында Декларациясне дә, үзебезнең Конституцияне дә кабул иттек, референдумны да тыныч кына үткәреп җибәрдек. Ул чагында барган вакыйгаларга карата халык фикерен белү аеруча мөһим иде.

Шартнамәне озайту турындагы мөрәҗәгать – ул урынлы һәм дөрес гамәл. Кайвакыт: «Нәрсәгә ул? Аннан безгә ни файда? Безгә барыбер колак салмыйлар», – дигән сүзләр ишетелгәли. Ә нигә кирәк булмасын?! Татарстан – уңышлы үсеп килүче республика. Безне хәзер беләләр, хөрмәт итәләр, безнең белән санлашалар. Казанны, башкалабызның йөрәге булган Кремльне күрергә киләләр.

Шушы көннәрдә беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев белән Кремль биләмәләрен карарга дип чыккан идек. Безне күрүгә, бер төркем туристлар Минтимер Шәриповичны әйләндереп алдылар, бергәләшеп фотога төштеләр, Казанны яратуларын, соклануларын белдерделәр. Үзләре Мәскәүдән икән.

Гади халык күпкә аңлырак ул. Аның өчен мөнәсәбәтләрнең әнә шундый якын, җылы булуы мөһим. Татарстан да дәүләт эчендә дәүләт булып яши. Әмма моннан беркемгә дә зыян юк. Республика үзәк каршында бөтен бурычларын үти, хәтта арттырып үти. Татарстан депутатлары керткән күп проектларның башка регионнарда да бик теләп кабул ителүен дә онытмыйк. Мисалга, армиягә яңа алынган солдатларны сугыш барган җирләргә җибәрмәскә, дигән фикер бездән чыкты, тузган торак программасы Татартсанда сыналып, үзенең файдалы булуы раслады. Шартнамәгә кул куймаслык бернинди сәбәп юк. Без яхшы яктан аерылып торырга тырышабыз.

РЕФЕРЕНДУМ ТУРЫНДА

Әлегедәй хәтердә, 1992 елның мартында референдум булырга бер көн кала, Президиум утырышы җыйдык. Ул чагында шушы мәсьәлә буенча Югары Совет Рәисе Фәрит Мөхәмәтшинны ашыгыч рәвештә Мәскәүгә чакыртып алдылар. Минем Рәис урынбасары булып яңа гына эшли башлаган чак. Президиум үткәрү, әзерлек эшләрен оештыру миңа кушылды. Мәскәүдә катлаулы утырыш барганын телевизор аша беләбез. Ә үзебез Югары Совет Президиумында төн уртасына кадәр баш ваттык. Үзәк катгый итеп референдумны үткәрмәү таләбен куя. Төнге икеләр тирәсендә таралдык. Чигенмәскә булдык. Иртәнге сигезенче яртыда эшкә килсәм, кабул итү бүлмәсендә хәрби киемнән ике кеше утыра. Йөрәгем жу-у итеп китте. Алырга килгәннәр инде болар мине, дим. Үзем сер бирмәскә тырышам. Берсе әйтә: «Сезгә Россия Федерациясенең Конституция Судыннан рәсми кәгазь алып килдек», – ди. Тынычлана төштем. «Референдум үткәрмәскә...» дигән карарны укыдым да: «Соң инде», – дидем. Бу фельдъегерьлар Татарстанда референдум булмасын дип, рәсми документның чын нөсхәсен (копияләр ярамый) поездан алда – машинага утырып алып килеп җиткәннәр.

Әмма 1992 елның 21 мартында референдум бернигә карамый булды. Чөнки халык үзенең ни теләгәнен яхшы белә иде. Һәм ул үз фикерен катгый рәвештә әйтә алды.

ТАТАРСТАН КОНСТИТУЦИЯСЕ ТУРЫНДА

Бүген без илдә, бөтен дөньяда үз позициябезне ныгыта алдык. Россия белән мөнәсәбәтләрне көйләдек. Татарстан Конституциясендә – халыкның омтылышын, үзенчәлеген гәүдәләндергән, дәүләтчелеген үстерерлек мөмкинлекләр ачкан маддәләр бар.

Республиканың Төп законын эшләгәндә без шул хакта уйладык. Иң элек эшче төркем оештырдык. Ул төркемгә Казан университетының юридик факультеты галимнәре Борис Леонидович Железнов, Евгений Батырович Солтанов кебек көчле юристлар тартылды. Арада дәүләт төзелеше проблемалары белән шөгыльләнүче бер хатын-кызыбыз – Талия Ярулловна Хәбриева да бар иде. Ул бүген Россия Федерациясе хөкүмәте каршында эшләп килүче Закон чыгару һәм чагыштырма хокук белеме институты директоры, күренекле галим, Россия Фәннәр Академиясенең беренче хатын-кыз вице-президенты.

Конституция проекты әзерләнгән вакытларда хокукчылар Югары Совет бинасыннан чыкмадылар да диярлек. Лекцияләрен тәмамлыйлар да туптуры безгә киләләр. Проект әзер булгач, депутатлар белән районнарга, авылларга чыгып китә башладык. Йөрмәгән җир калмады. Халык без килгәнне белеп, шундук очрашуга ашыга, кызыксына, үз фикерен әйтә. Гаҗәп актив иде ул чагында халык. Битарафлар юк иде. Авыллардан кайтабыз да, телевидениедә туры эфирда бара торган «Депутат сәгате» тапшыруына китәбез. Һәр яңалыкны, һәр проблеманы уч төбенә салып сөйләгәнгә, Конституция кабул иткәндә бернинди дә аңлашылмаучанлык, ризасызлык килеп чыкмады. Кискен каршылыкларны Килештерү комиссиясендә җайлый идек.

ХАТЫН-КЫЗ ҺӘМ СӘЯСӘТ ТУРЫНДА

1990 елда ТАССР Югары Советына сайланган 200 депутатның 35 е хатын-кыз иде. Утырышлар сузыла башласа, алар: «Өйдә безне бала-чага, ирләребез көтә», – дип, кайту ягын карый башлыйлар иде. Депутат, халык илчесе булуның ни дәрәҗәдә җаваплы булуына алар тора-тора, шул сәяси дөньяда кайный-кайный төшенделәр. Тормыш өйрәтте, вазгыять таләп итте. Бервакыт мин, хөкүмәттә хатын-кыз булмый икән, ул инде демократик республика хөкүмәте булмый, ә сугышучы ил генералитеты була, дип чыгыш ясадым. Күп балалы әниләргә «Ана даны» медале бирү тәкъдимемне үткәрә алдык.

Парламент утырышларында ялкынлы чыгышлар яңгырый, зур бәхәсләр чыга иде. Шуңа карамастан, республика мәнфәгатьләрен якларга кирәк булганда, без бердәм команда идек. Ул вакытта уртак һәм изге бурычыбызны үтәү – үз йөзебезне саклау турында кайгырту берләштерде безне. Бу сынау хәзер тагын яңадан урап кайтты. Бүген дә барыбызга бердәм булып, республикабызның, халкыбызның кабатланмас йөзен, үзенчәлеген сакларга кирәк.

PRESSA.RU




Фото интернеттан алынды

ИСКЕ ЯҢА ДӨНЬЯ

Чулпан ЮНЫСОВА

– НИШЛӘП УТЫРАМ ИКӘН ИНДЕ МИН МОНДА? АШАРГА ИПИЕМ, КИЯРГӘ КИЕМЕМ БАР ИДЕ БИТ ӘЛЕ...

Балалар йокыдан тордылармы икән? Мине югалтканнардыр инде... Әбекәйләре ашата алды микән? Кечкенәсен әле һаман кашык тотып үзем ашата идем бит...

Икенче балам белән декрет ялыннан чыкканнан соң беренче эш көнем бу. Үземнең халәтемне ничек дип аңлатыйм икән? Сүзен тапмыйм. Әйтерсең, мине бирегә көчләп, ирексезләп китереп утыртканнар. Ярый әле башымда нинди уйлар бөтерелүен тирә-юньдәгеләр белми. Кызларым башымнан бер минутка да чыкмый. Миннән башка өйдә инде әллә ниләр булып беткәндер кебек... Ә бит беренче баламнан соң эшкә чыкканда болай авыр булмаган иде. Яшьрәк чак булгангамы соң.

Олы кызымны соңарып тапмасам да, үзебезнең һәм күрше палатада ятучы бәбиләгән хатыннар арасында мин иң өлкәне идем. Декретка да эштән алҗып киттем ул чакта. Бала тугач, эш турында берара тәмам онытып тордым. Мәшәкатьләр артты бит: эч авыртулар, беренче тешләр, беренче адым... Бер ел шулай сизелмичә үтеп китте. Ә икенче ел... Икенче кыш бик озакка сузылды кебек. Өйдә гел халат киеп йөрүдән дә, башымда гел «ат койрыгы» ише прическалар гына булудан да бик туйдым ул чорда. Балаларыбыз бер тирә булган күрше хатынына атлаган саен: «Минем киенеп-ясанып өйдән чыгып китәсем, башкалар кебек кич кенә кайтып керәсем, эшлисем, яңадан-яңа үрләр яулыйсым килә», – дия идем. Бала да, мин дә көннәрне үткәрә алмый интегә идек бугай. Ике яше тулыр-тулмас кызымны балалар бакчасына илтеп куйдым да, икенче көнне үк эшкә чыгып чаптым. Нәкъ үзем теләгәнчә: киенеп-ясанып. Бала да бакчага авыр ияләшмәде кебек. «Балам нишли икән?» – дип, башка әниләр шикелле тәрәзәдән тәрәзәгә борчылып карап йөргәнемне дә хәтерләмим. Еласа, туктар, дип уйлаганмындыр, күрәсең... Бер айдан соң баланың борыныннан маңка ага башлады. Маңка гына куркыныч түгел дип, дәвалыйсы урынга, кызымны бакчага йөртүне дәвам иттем. Ахырда ул бронхитка үк әйләнде. Баштарак баламны карарга ял алсам да, авырулары еш-еш кабатлангач, «мин тагын больничныйда әле», дип, эштәгеләргә әйтергә кыенсына башладым. Өстәвенә, ул хезмәт хакында да чагылыш тапты. Әле бит ипотека да түлибез. Кеше арасында йөргәч, кешечә киенәсе дә килә...

Ул чакта ярдәмгә кайнатам алынды. Пенсиядә килеш эшләп йөргән кайнатам, хезмәт урыныннан китеп, авырган вакытта оныгы белән өйдә утыра башлады. Ул вакыттан соң күп сулар акса да, хәзергә кадәр коллегаларым баламны «бабай кызы» дип йөртә. «Олы кызыңны кайнатаң карап үстереп бирде», – дип әйтәләр. Мин үпкәләмим – хак сүзләр. Әтигә рәхмәтлемен генә. Ул миңа тыныч күңел белән эшләргә мөмкинлек тудырды.

Күрше хатыны исә, сабыена балалар бакчасы алданрак булуга карамастан, кызына 3 яшь тулгач кына эшкә чыкты. Бик аптыраган идем аңа. Ничек шул гомер өйдә утырырга мөмкин?! «Җаның бармы соң синең, кеше арасында йөрисең килмимени соң?» – дип аптыратып бетердем. Артык сүз сөйләргә яратмаган күршем, андый чакта елмаеп карап кына тора иде миңа.

Олы кызыма 6 яшь тулгач, Ходай безгә тагын бер кыз бүләк итте. Монысы да көтеп алган, «апасына сер төенчеге булыр, тагын бер кыз бирсәң иде», – дип Ходайдан сорапялынып алган сабый.

Ике кызыбыз – ике канатыбыз булды дип, шатланып, вакытның үткәнен сизми дә калдык кебек. «Апабыз» укырга керде, һәм һәммәбез мәктәп мәшәкатьләренә күмелдек: бию түгәрәге, төрле ярышбәйге, олимпиадаларга чаптык. Кечкенәсенә 2 яшь тулгач, бер танышым беренче тапкыр: «Балалар бакчасы булдымы әле?» – дип сорады. Ул сораудан утка баскан кебек куркып киттем: «Кечкенә бит әле ул». Һәм шул минутта ук: «Олысы бу вакытта балалар бакчасына йөри иде бит!» – дигән уй җанымны телеп алды. Алты елдан соң баламны кызганып күземнән яшьләрем атылып чыкты.

Кечкенәмә 3 яшь тулыр вакыт килеп тә җитте. Балалар бакчасына бирү тәртибе дә, миңа үч иткән кебек, бернинди хилафлыкларсыз, алга барды. Чират та килеп җитте, урынны да бирделәр. Ә кызчыгым минем өчен һаман да кечкенә сабый кебек иде шул... Ни гаҗәп, эшкә чыгу теләге өч ел эчендә бер тапкыр да башыма килеп карамады. Бөтен җанын-тәнен биреп, гаиләсен күрми көн-төн эш дип чапкан бер танышым көтмәгәндә кыскартуга эләкте. Ул ярык тагарак янында калган кебек тоелды миңа. Яраткан эше дә юк, абруе да, балалардан да ерагайган, гаилә дигәненең дә исеме генә... Миңа андый язмыш кирәкми, бар көчемне кызларымны тәрбияләргә бирәм дигән уй беренче тапкыр шул чакта килде.

Бала алдында үземне гаепле хис иттем: йә, нинди әни булганмын инде мин?!

Мөмкинлегебез бар (ипотека да, кредит та түләмибез!), балалар үскәндә эшкә чыкмыйм, дигән карарга килеп, әлеге теләгемне бер көнне әтиебезгә җиткердем. Тик төпле, салкын акыллы ирем: «Хатын-кыз әни булудан кала, шәхес тә бит әле. Син кеше арасына чыгарга тиеш, өйдә утыру эш түгел ул. Карьера яса, акча тап дип әйтмим, әмма күңелең өчен бер эшең булырга тиеш», – дип, ниятләремне сыпырып ыргытты.

Мин, ул әйткәнчә, «кеше арасына» чыгарга җыена башладым. «Чыгу» сүзе үзе үк куркыта икән ләбаса мине! Ни кеше белән сөйләшә-аралаша, ни киенә, ни инде эшемне башкара белмәм кебек тоелды. Күңелемә якын джинсыкроссовкиларны салып, ничек күлмәк, озын үкчәле туфлиләр киярмен икән дип шөбһәләндем. Иң беренче эш итеп интернетка кереп, башкалар хәзер нәрсә кия икән дип кызыксындым. Чөнки соңгы өч елда мине мода, киемсалым бөтенләй кызыксындырмады шул: уңайлы, җайлы булса, шул җитте. Китап кибетеннән кеше белән аралашырга өйрәткән акыллы китап та күтәреп кайттым (дөрес,

PRESSA.RU

аны укырга вакыт кына тапмадым). Үз оясыннан чыкмый яшәгән әрлән кебек идем бугай мин... Психологлар, һәр кешенең үз комфорт зонасы була, һәм ул аннан чыгарга куркып яши, диләр. Минем дә үзем өчен рәхәт булган дөньямнан чыгасым килмәде. Уйларымның очы-кырые юк: эшли алырмынмы, коллективым ничек каршы алыр, ә иң мөһиме: балаларым минсез нишләр?

Шуны да онытмагыз – бала тәрбияләү ул әнинең генә бурычы түгел.

Кечкенә кызымның туган көнен шаулатып үткәрдек тә, икенче көнне мин – эшкә, балаларым җәйгә әбекәйләре янына кайтып китте. Өзгәләнеп аларны уйлыйм... Әни шалтырата. Әллә берәр нәрсә булганмы?! Юк икән... «Сине искә дә алмыйлар, монда аларга ирек. Бернигә борчылмый, рәхәтләнеп эшлә», – ди.

Беренче эш атнам узып та китте. Кеше белән дә сөйләшә беләм икән, эшем дә онытылмаган, башка яңа идея-фикерләр дә килә, компьютер клавиатурасында бармаклар да элеккечә йөгерә... Иртән эшкә барырга чыккач, өй тирәсендә очраган танышлар, тирә-күршеләр арасында: «Сиңа эш килешә икән, әнә ничек матурланып киткәнсең», – дип мактап куючылар да булды инде. Тик күңел барыбер урынында түгел...

Өченче баласы белән декрет ялында утырган элеккеге күршем шалтыраткан иде. «Мин башка эшкә чыкмам инде, бу балаларны ничек карап бетерерсең?» – ди. Уйланып калдым әле. Әллә мин дә олы кызымның киңәшен тотыйм микән? «Әни, безгә тагын бер бәби кирәк», – диде ул беркөнне. «Нигә, кызым, сеңлең бар бит инде?» – дим. Ул бик акыллы кыяфәт чыгарып: «Тагын бер бәби алып кайтсаң, син бит безнең янда өйдә генә торачаксың», – дип нәтиҗә ясап куйды. Ә бәлки...



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru



Айсылу НӘГЫЙМОВА,
психология фәннәре кандитаты,
социология фәннәре докторы

Бала табып үстергән һәр әни алдына иртәме-соңмы килеп баса торган иң әһәмиятле сорауларның берсе бу: кайчан баланы бакчага бирергә, гомумән, бирергәме, кабаттан эшкә чыгаргамы? Чыннан да, нишләргә?

Сабый 1,5-2 яшьләргә кадәр әнисенә психо-эмоциональ яктан бик нык бәйләнгән була: әнидән аерылып тору анда тирән психологик дискомфорт тудыра (галимнәр бу халәтне «сепарацион шөбһә» дип атый). Бары тик өч яшьләр тирәсендә генә балада тирә-юньдәге кешеләр белән кызыксыну туа башлый. Галимнәрнең фикеренчә, сабыйның балалар коллективына кереп китүе өчен кулай вакыт – дүрт яшьләр тирәсе.

Баланы, гомумән, бакчага бирергә кирәкме соң? Җавап бертөрле генә була алмый. Гомумән алганда, сабыйның балалар бакчасына йөрүе бик әһәмиятле. Беренчедән, балалар бакчасы ул сабыйны ашату, тәрбияләү урыны гына түгел, ә бердәм белем бирү системасының беренче баскычы да. Бакчага йөргән балалар билгеле бер программа буенча белем алалар, мәктәпкә әзерлек этабын узалар. Икенчедән, сабый өчен бакча җәмгыятьнең бер моделе булып тора – ул анда яшьтәшләре белән аралашырга, дуслык мөнәсәбәтләре булдырырга өйрәнә, шул ук вакытта тәрбияче белән бала арасында туа торган формаль мөнәсәбәтләрнең нигезенә төшенә, ә бу исә киләчәктә балага җәмгыятьтә яраклашырга ярдәм итәчәк. Моннан тыш, балалар коллективына керү сабыйның психикасы формалашуда уңай йогынты ясый: ул шәхси эгоизм белән иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең балансын булдырырга өйрәнә.

Билгеле инде, сабыен беренче тапкыр бакчада, чит кешеләр карамагында калдырып чыккан әни үзе дә кискен сепарацион шөбһә өянәге халәтен кичерә (тирән борчылу хисе, башка берни турында да уйлый алмау, һәм башкалар). Шунысы яхшы: бу өянәк бары тик берничә көнгә (сәгатькә, атнага) сузыла, аннан әни кеше дә аек акыл белән фикер йөртә башлый.

■ Табигать шулай итеп яраткан – телибезме без аны, юкмы – әкренләп балаларыбыз җылы кочагыбыздан киң дөньяга чыгарга тиеш. Кендек бавы киселүгә сез беренче «аерылу» кичерәсез, балалар бакчасы аның икенчесе (алда әле андый «аерылулар» күп булыр – мәктәп, югары уку йортына китү, гаилә кору, сездән аерым яши башлау һәм башкалар). Бу «аерылуларны» тиешенчә, сабырлык белән кабул итәргә өйрәнергә кирәк. Шуны да онытмагыз: сезнең психологик халәтегез балагызга да йогынты ясый – никадәр тыныч булсагыз, ул да сездән аерылып калганда азрак борчылыр.

■ Эшләргәме яки әни генә булып яшәргәме, дигәндә, мин һәрвакыт икесен дә бергә алып барырга кирәк, дип җавап бирәм. Сез нинди генә уңган хуҗабикә, яхшы әни булсагыз да, вакыт үтү белән якыннарыгызга кызыксызга әйләнәчәксез, чөнки яшәеш безнең аңыбызны, фикерләү тәртибен, тормыш фәлсәфәбезне формалаштыра. Өй, гаилә мәшәкатенә генә күмелеп яшәгән хатын-кыз тышкы кыяфәте белән дә, эчке дөньясы белән дә иренә кызыксыз була бара, балалар да үскән саен әниләре белән аралашырга темалар кимегәнен сизә. Нәкъ менә шул категория хатын-кызлар күп вакыт иренең хыянәтенә, дорфалыгына түзеп яшәргә мәҗбүр, чөнки аерылышу алар өчен мөмкин булмаган хәл – профессия дә, эш тәҗрибәсе дә инде күптән югалган...

■ Бала тәрбияләү процессына әти кешенең дә актив катнашуы кирәк, мөмкин булганда әби-бабайлар, башка туган-тумача да ярдәм кулы суза ала. Зур гаилә казанында кайнап үскән бала тормышка яхшырак әзерләнгән, адаптив, аралашучанрак булып үсә, интеллектуаль үсеше дә камилрәк.

ҖӘМГЫЯТЬ



■ **Тынычлык бистәсендәге Каенлыкта Казан Сабан туе гөрләде. Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ЮНЕСКО генераль директорының урынбасары Нада әл-Нәшиф белән килде. Президент районнар тәкъдим иткән йорт-утарларын карап чыкты, төрле бәйгеләрдә катнашты, батырларга бүләк өләште, тимер акча сугып карады, татар халкының милли бәйрәме Сабантуйны ЮНЕСКОның матди булмаган мәдәни мирасы исемлегенә кертү турында сүз алып барды. Сабантуйда республика җитәкчесен шулай ук «WorldSkills Kazan 2019» талисманнары белән таныштырдылар. Бу үз тырышлыклары белән бар өлкәдә дә уңышларга ирешкән Алмаз исемле малай һәм Алтын исемле кыз маскотлары.**

■ **Болгар тарихи-археологик комплексында ЮНЕСКО канаты астында булган Халыкара волонтерлар лагере ачылды. Әлеге проект Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен торгызу Республика Фонды һәм Казан (Идел буе) федераль университетының халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Шәрыкны өйрәнү институтының «Халыкара мәдәни мирас» ресурслар үзәге тарафыннан оештырылды. Ул ЮНЕСКОның 50 волонтерлар лагере исемлегенә керде. Һәм андый лагерьлар 2017 елда дөньяның 32 илендә эшли башлаячак. Волонтерлар археологик казыну, реставрация һәм консервация эшләрендә катнашачак, Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгына килүчеләр белән эшләячәк.**

МӘДӘНИЯТ

■ Мамадыш районы Җөри авылында узган «Питрау» керәшен мәдәнияте фестиваленең «Керәшен чибәре» бәйгесендә быел 10 кыз катнашты. Көянтә белән су ташу, визит карточкасы, иҗади номер, интеллектуаль тур, йола тәртипләре буенча ярышып, алар үзләренең булдыклылыгын күрсәтте. Алабуга кызы Екатерина Максимова «Керәшен чибәре-2017» дип танылды.

■ Биектау районының Кече Битаман авылында Туфан Миңнуллин исемендәге I Бөтенроссия драматурглар семинары узды. Анда республикабыз театрларыннан, Башкортстанның Нур, Сибай, Туймазы театрларыннан вәкилләр килде. Драматурглар һәм режиссерларның танышу, аралашу мәйданы булды ул. Пьесалар укылды, аларга анализ ясалды. Әлеге чара Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Биектау муниципаль районы ярдәме белән оештырылды.

КОТЛЫЙБЫЗ



■ **«Россия Федерациясенең атказанган артисты» дигән мактаулы исем Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең баш балетмейстеры Раилә Мөхәммәт кызы Гарипова-га тапшырылды. Ул инде 40 елга якын әлеге ансамбльне җитәкли.**

СПОРТ



■ Казанда авиаузышлар буенча Дөнья чемпионаты Red Bull Air Race узды. Кремль яр буе янында Казансу өстеннән дөньяның 20 авиаспорт пилоты очты. Республикада гына түгел, Россиядә дә беренче ярышлар иде бу. Самолетлар, «Казан-Арена» футбол стадионы территориясеннән старт алып, җир өстеннән 25–50 метр биеклектә «Миллениум» күпереннән Кремль дамбасына кадәр очты. Бу тамашаны карарга бик күп туристлар да килгән иде.

МӘГАРИФ

■ Тайландның Накхон Патхом шәһәрендә 76 ил вәкилләре катнашында узган 49 нчы халыкара химия олимпиадасында дүрт кешедән торган Россия мәктәп укучылары командасы 2 алтын, 2 көмеш медаль яулап кайтты. Казандагы 131 нче лицей укучысы Руслан Котляров алтын медаль иясе булды.

■ Биләрдә VI «Сәләт» халыкара яшьләр белем бирү форумы узды. Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кунак булды. Ул «Фәнсар» фәнни-белем бирү үзәгенә килеп, быел гына ачылган «Әдип йорты»н, яңа төзелгән 25 метрлы бассейнны, футбол кырын карады, брендлы кием тегү һәм татар халык ашлары остаханәләрендә булды.



PRESSA.RU



МИЛӘҮШӘ МӘЧЕТЕ



Асия
ЮНЫСОВА

МӘТӘСКӘ АВЫЛЫНДА ТАТАРСТАНДАГЫ 1528 НЧЕ МӘЧЕТНЕ САЛЫП КУЮНЫҢ МАКСАТЫ ТАГЫН ДА ОЛУГРАК – ҮЗЕННӘН СОҢ ДА АВЫЛ ӨСТЕНДӘ АЗАН ЯҢГЫРАП ТОРСЫН, АВЫЛДАШЛАР ДОГАДАН АЕРЫЛМАСЫН! ДИМӘК, «МИЛӘҮШӘ МӘЧЕТЕ» ДИГӘН ИСЕМГӘ ТУКТАЛАМ.

Язмама исем куя алмый йөдәдем. Тегеләй дә дөрес булыр кебек, болай да. «Күккә омтылган «Бәхет» дигән вариантым да бар иде. Имеш, Миләүшә Галимҗан кызы Сәлахетдинованың озак еллар дәвамында «Бәхет» акционерлар җәмгыятенең генераль директоры булып торуына ишарәлим. «Алма апа мәчет сала» дигәнен дә уйладым. Янәсе тугыз баланың җиденчесе булып туган Миләүшәнең гомер буе туганнарын яратып, барлап, кайгыртып – кыскасы, күпсанлы, абый-апа, эне-сеңел балаларына Алма апа булып яшәвен белдерәм. Миләүшә ханым авылдашларын да өзелеп ярата. Тәтенсез авылга күченгән әби-бабайлар, ата-ана рухын кадерли, догадан калдырмый, каберләрен исә чәчәктән өзми. Чәчәкләргә сибәсе суын Казаннан ук алып кайта да, үзе югында сибәрләр дип, сулы савытын калдырып китә. Ул югында да гөлләр суга сусамасын!

«Патша кызы булганмын»

Ислам динен бер дип белгән кеше авызыннан чыккан мондый җөмлә, әлбәттә, мине елмайтты. Әмма, «динебез моны инкарь итми», дигән икенче җөмләсен ишеткәч, кыйссаны тыңлыйсы иттем. «Минем бу Җиргә җиденче килүем икән. Беренче яшәешемдә патша кызы булып туганмын. Үзсүзле, тыңлаусыз, иркә кыз булганмын. Никтер, патша атам мине милектән мәхрүм иткән. Байлык миңа бу – җиденче гомеремдә килгән. Шөкер, зур йортыбыз, машинабыз бар. Мәчет салып куйдык менә. Гомумән, электән дә байлык безнең тирәбездә йөргән. Әтием ягыннан бабам Әхмәтҗан кара бай булган. Байлыгын үз хәләл көче белән, ялчы хезмәтеннән файдаланмый баеган кешеләрне кара бай дип йөрткәннәр. Шул йортка килен булып төшкән әниемнең, киенеп торуга вакыт әрәм итмәс өчен, тула оек-чабатаны салмый йоклый торган идек, дип сөйләгәне хәтердә. 30 нчы елларда байлыкларның кая киткәнен беләсез». Сугыш башлануга шахтер Галимҗан, инде җәмәгатен биш бала белән калдырып, ут эченә китә.

Илдә чыпчык үлми. Миңлевафа биш баласын да исән саклап каршы ала ирен. Эш сөйгән, тик тормаган кеше әмәлен таба – балалар исәяләр. Җиденче сыйныфтан соң Миләүшә дә фермага сыер саварга төшә. 14 яшьлек кызның таң беленгәнче торып, кар ерып ферма сукмагыннан атлаганын уйлыйм да җаным өшеп китә. Әнисе Миңлевафаттәйниләр кичергәндер. Алай дисәң, михнәттән башы чыкмаган авыл хатынының үз хәсрәте үзенә җиткәндер. «Догаларыңны кабатлап йөр, кызым!» – ананың тал чыбыгыдай кызына бар ярдәме – шул киңәш. Кабатлый инде, кабатлый. Ярый әле һәр кич саен әнекәе ятлаткан догаларым бар дип сөенә.

Миңлевафаттәйнең мәшәкате баштан ашкан. Миләүшәдән башка да ничәү бит әле анда. Өстәвенә, сугышасугыша Берлинга барып җитеп, башына мина ярчыклары «төяп», аяк табанын яртылаш калдырып кайткан Галимҗанын көйлисе-тәрбиялисе дә бар. Бу җиденче булып туган кызы, үзенә охшап, тынгысыз. Мәдрәсә белеме эләгеп калган ана кызының яктылыкка омтылуын сиземли – беренче сыйныфка яланаяк барган Миләүшә затлы тормыш күрергә туган сыман кылана. Хәерлегә булсын!

Урта Азиядән илне сагынып ике елга бер кайтып китә торган кешеләр торган җирләрен мактап, илдәге яшь җилкенчәкнең күңелен иләсләндерергә һәвәс иде элгәре. Үзбәкстаннан кунакка кайткан күршеләре фермада сыер сауган чәчәк кебек сылу, нәфис Миләүшәне үзләре белән рәхәт җиргә китәргә күндерәләр. Ходаярхан дигән кышлакта да Миләүшәне сыер фермасы гына көтеп торган икән. Йә, тагын да шул сыер савасы булгач, меңнәрчә чакрым ара үтеп, нигә килергә иде инде үзбәк арасына? Монда да әче таңнан ферма сукмагына төшәсе, дүрт чакрым атлыйсы. Урта Азия төне бездәге ише түгел, анда төннәр кап-кара. 15 яшьлек Миләүшәгә куркам дип, иркәләнергә түгел, зарланырга да чара юк – әнекәе ерак. Кызны җәнлекләр дә кызгана бугай. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгылыктан кинәт түшенә сикергән ул җәнлек нәрсә булгандыр – Миләүшә әле дә белми. Әллә бүре, әллә эт, әллә бүтән бер җан иясе, кайнар тынын кызның битенә бөркеп, юк та була.

> *Тамырлары, сабак-чәчәкләре белән тормышка чытырдатып ябышкан, үлмәскә тырышкан әрекмән сыман икән бит ул.*

Бер көнне ферма мөдире, үзенчә кызны кызганып: «Минем улым машина белән сөт ташый бит. Аңа утырып кайтырга җайлаш әле син», – ди. Менә бәхет! Кышлакка кайтып җиткәндәрәк юньле генә күренгән бу егет кисәге кызга ташлана. «Кыргый барс кебек сугыштым. Плюш җакетым уелып-уелып төште, бирешмәдем. Икенче көнне фермадан киттем. Теге абзыйга да, аның улына да рәнҗедем. Татар баласы дигәчтен дә... Балалар бакчасына эшкә урнаштым. Якындагы урта мәктәпкә укырга кердем. Дәресләрдән соң шул мәктәпне, тагын ике конторааны барып җыештырам».

Миләүшә ханымны тыңлыйм да андагы яшәү көченә исем китә. Укудагы уңышларын күреп, Ленинградка җибәрергә булалар кызны, әмма комиссия татар кызына тәрәккыяткә юлны ачмый торырга була. «Калып тор!» Мондый гаделсез карарны ишеткән үткен кыз, монда калса, алга таба да гел шлагбаумга юлыгып торасын аңлап ала. Миләүшәгә хәзер нишләргә? Бүген кияүгә алырга атлыгып торган үзбәк егетләре дә бихисап. Юк, бу вариант аныкы түгел! Ленинградтан мәхрүм калды, дип сөенми торсыннар әле. Югарыга юл фәкать белем алу аша гына! Кыз Коканд пединститутына укырга керә. Ходаярханнан Коканд шәһәренә күчеп килгән иде инде ул, хәзер менә Ташкентка ук китеп бара. Анда мохит яктырак. Туку комбинатында татар кызлары күп, диләр.

Миләүшәгә дә анда эш табыла. Контролер! Бер дә начар түгел. Өйдәгеләргә ай саен диярлек чәй-шикәрле,

PRESSA.RU





кием-салымлы посылкаларны һаман җибәреп кенә тора. Акча юнәтү өчен өчәр җирдә эшләгәч, күңел ачуга, кызык эзләүгә вакыты да калмый. Яхшы киеме дә юк бит әле үзенең. Тулай торакта бергә яшәгән үзбәк кызлары Шәрәфә, Баһар белән өчесенә рәешкә кия торган 3 сум илле тиенгә сатып алынган гофре итәкле бер күлмәкләре бар. Егетләр киногa чакырган чагында шул күлмәкне чиратлашып кияләр. Менә шундый патша кызы ул! Эх, шул чагында булган булсамы бүген юбилееена сатып алган төсле ак күлмәге!

Ташкентта җир тетрәгәнне кичергән кешеләр туган якка омтылды ул чагында. Кызлары үзбәккә кияүгә чыгып, бөтенләйгә шунда калыр дип хафаланган әти-әни дә тынгысызлана. Кыз үзе дә авылны, Акъяр инешен сагына.

Миләүшә икенче сынауны көтеп тормый. Аякка басуга үз иленә кайтып китә.

Кайта Миләүшә. Казанда кибетче булып эшкә урнаша. Торырга урын юк. Әлегә аның иң зур хыялы – берәр подвалда, караваt кына сыярлык булса да, почмак табу. Ә менә эшен ярата ул. Бергә эшли торган сатучы апаларны ярата. Бигрәк тә Галия апаны. «Син кемгә охшап шулай сабыр?» дип сорасалар. «Галия апага, – дип җавап бирә ул. – Күпме бергә эшләп, мин аның авызыннан бер яман сүз, бер зар, бер үпкә ишетмәдем. Хәтта тавышын күтәргән чагы да булмады аның. Үз әнием дә миңа гаҗәпләнә торган иде. «Әтиегезгә син кияүгә ягымлы булган кебек тәмле сүзле булсам, ул мине кул очында йөрткән булыр иде», – ди. Гаҗәеп гыйбрәт. Юк, теге Галия апа түгел әле, Миләүшә үзе! Начар нәрсә тиз йога ул. Ә менә яхшыны йоктыра белү, гыйбрәт ала белү сәләте сирәк кешедә генә очрый. Миләүшә – сирәкләрнең берсе. Ә бит аның үзен дә үрнәккә куючылар бар. Кешенең тиенен дә кысмас, кеше өлешенә бер мыскал кермәс – гаҗәеп гадел сатучы! Югыйсә кибеткә эшкә керәсен белгәч, өстеңә чыкканны түләргә сыерың бармы соң, дип кисәтүчеләр дә табыла. Аның гаделлеге сабый чактан сыналган сыйфаты. Авылдашлары аны еш кына балалары янында өй сакларга калдыралар. Бер күрше апа юри сыный, күренә торган урынга акча куеп калдыра, янәсе, кыз кыек куллы түгелме икән?

Ахирәте Равилә ханымнан, Миләүшә дустың турында белгәннәреңне сөйлә әле, дип үтенгәч, ул бер җөмләне җиде тапкыр кабатлады: «Ул кешеләргә гел игелек кенә кыла. Бик яхшы кеше ул Миләүшә!» Югыйсә Ахирәтләр аланыннан егерме җәй рәттән бергә җиләк җыйган дусты турында сүзе бетмәстәй булырга тиеш иде кебек.

Алай икән. Димәк, дәлилләрне үземә табасы. Эзлисе дә юк икән. Кайнанасы белән генә түгел, иренең бертуган апасы Мәгъмүрә белән дә 30 ел бер түбә астында яши алган, белеш әбиләр авызыннан «синең белән телефоннан гына сөйләшсәм дә, терелеп китәм» дигән сүзләрне ишеткән килен, караучысыз әбиләргә үз коеларыннан чиста су өләшеп, аларны мунча кертеп, ризык ташып йөргән мәрхәмәт иясе, кибет ишегалдындагы иске йортта ялгызы гомер кичерүче маржа әбине соңгы көненә кадәр тәрбияләгән, авылның күперләрен кайгырткан, төн уртасында да мохтаҗларга ярдәм кулы сузарга ашыккан, туганнарын хәстәрләп, ярдәмләшеп торган, туган нигезен яңарткан, шулай итеп әрвахлар догасына ирешкән һәм МӘЧЕТ САЛГАН Миләүшә бит ул!

Дөрес юлның башы – Коръәндер

Ташкентта җир тетрәгән көннәрдә Миләүшәнең хастаханәдә яткан чагы була. Сары белән чирли. Кинәт бөтен дөнья шомлы тынлыкка чума. Аннан хастаханә ятаклары атынчык атына башлый. Андагы халык моның ни икәнен белә. Һәр кеше үз җанын кайгырта.

Лә хәүлә вә лә куәте!

Җиһан иясе адәм балаларына кодрәтен күрсәтеп алмакчы! Бу кодрәткә каршы торырлык ни чара?! Миләүшәнең чарасы – әнисе ятлаткан догалар. Шулар ярдәме белән ме соң – хастаханә бинасы ишелми кала. Ә тирә-юнь, гомумән, меңнәрчә еллык Ташкент үзе хәрабә хәлендә.

Миләүшә Сәлахетдинованың «Татарстанның атказанган сәүдә хезмәткәре» кебек мактаулы исемнәргә ирешү юлларын, шәһәрнең Мактау тактасында тору елларын барлый башласакмы? Алай да данлы биографиясенең башы булган 108 нче санлы кибеткә тукталмый булмас. Кремль урамында урнашкан, соңыннан «Бәхет» дигән исем алган ул уникаль кибетне күпләр белә булыр. Ни өчен уникальме? Чөнки заман таләбен тоеп, азык-төлек кибетенә китап керткән иде директор. Китаплы җиргә зыялылар юл саба. Монысы да шәп! Икенче шәбе – директор һәр клиентын ачык чырай белән үзе каршыларга, тәмле сүзле әңгәмәдәш булырга да иренми. Чөнки директор Сәлахетдинова үзе дә хәзер инде Мәскәүдәге мәшһүр Плеханов исемендәге институт дипломына ия булган югары белемле җитәкче. (Бу институтны МГИМО белән янәшә куя торганнар иде.) Институтта сәүдә эшенә генә түгел, зәвык белән киенергә, теләсә нинди дипломатик очрашулар вакытында үзеңне ни рәвешле тотарга да өйрәтәләр.

Дәрәҗәле Миләүшә Галимҗан кызының кием-салымы кемнең дә күзе төшәрлек хәзер. Күзе төшкән кеше борылып карарлык. Берәүсе – Дамир исемле егет солтаны борылып карый да! Бер күрүдән ярату була бу. Кавышуны озакка сузмыйлар. Икесенең дә икенче никахы бәхетле никах булып чыга. Менә инде дүрт дистә ел алар янәшә атлый. Туйда кигән үтә матур ул күлмәкнең аклыгы бу икәүнең гомер юлын һаман да яктыртып бара сыман. Кайвакыт Дамир Шакирҗан улы шаяртып куя: «Син элек мине генә ярата идең. Улыбыз Динар тугач, яратуың аңа күчте, хәзер инде Кәрим оныгыбызны гына яратасың». «Алай әйтүең бик үк дөрес түгел, бәгырь кисәгем. Мин иң нык итеп Аллаһыны сөям!» Хәләленең бу җавабына Дамир Шакирҗан улы ни дисен? Ул инде хатынының чигә юлыкса да, михнәткә тарыса да Аллаһыга шөкер итүенә күнегеп бетте. Инде күп илләр гизгән Миләүшәсе белән бергә хаҗ сәфәренә дә барып, бер уйда, бер теләктә булып яшәү турында хыялланасы гына кала.

Илләр гизү дигәннән... Миләүшә ханым биографиясендә дә бар ул биштәр аскан сәфәрләр. Кытайга, Польшага, ул илләрдән Татарстанга җилкәдә тауар ташыган челноклык михнәтләре. Ул сәхифәләр берәр җирдә теркәлде микән, әллә ил язмышына уралып, вакыт чоңгылына чумды микән? Эшне эшләп күрсәтә белә торган Миләүшә ул маршрутларда да сынатмагандыр. Сәфәрләр арасында ямьлеләре дә бар. Иргә аркаланып, иркә хатын сыйфатында янәдән ике ел Ташкентта яшәп кайткан дәверне әйтәм. Ике генә ел! Әмма шул арада аның 108 нче кибетендә 12 директор алышынып өлгергән. Кабат үзенә, уночемче директор сыйфатында, кибетен «Бәхет» иткәнче тырышасы булачак әле аңа. «Татарстанның иң булдыклы кешеләре» дигән исемлектә теркәлгәнче бизнес өлкәсендә ирешкән уңышларын, аның ничә йөзләгән кешене эшле иткәнен санап тормыйм. Әмма бу урында аның хакындагы «гайбәт»ләрнең тагын берсен сөйләп үтәсем килә.

Динебезне яратам. Коръән – бер нурдыр. Гөнаһлы булудан безне ул гына коткарыр».

«Бер генә дошманы да юктыр аның...»

Бу «гайбәт»не Миләүшә Галимҗан кызы болайрак шәрехләде: «Пәйгамбәребез янына берәү килгән дә өченче берәү турында ямьсез, тәмсез сүзләр сөйләгән. Пәйгамбәр «әйе, әйе» дип, ул кешене җөпләп торган. Бераздан бүтән бер кеше килеп, теге кеше турында гел яхшыдан сөйләп киткән. Пәйгамбәр бу юлы да аның белән килешкән. Бу сөйләшүләргә шаһит булып торган адәм бик аптырап сорап куйган: «И хәзрәти галәйһиссәлам, ике тапкырында да теге адәмнәр белән ризалаштың, аларның кайсысы хаклы булды соң?» Пәйгамбәребез: «Алар икесе дә үзләре хакында сөйләде», – дип җавап биргән. Димәк, һәр кеше үзенең әхлагыннан чыгып фикер йөртә. Мин үзем һәрнәрсәдә чисталык яратам».

Ахирәте Равилә Шамил кызы әйткән иде шул: «Миләүшәнең чисталыгына чыдарлык түгел», – дип. Киң мәгънәдә аңланган чисталык булган икән бу. Ә мин аның, «көн дә зур өебезне җыештырып чыгам, оныгым килүгә чиста булсын дим», диюенә эчемнән генә уйлап куйган идем: килсә ни... Килсә ни генә түгел икән шул. Килүнең хикмәте бар – онык дәү әни янында куна кала, дәү әни куенында яңа дога ятлый. «Улым Динар да мәчеткә җомга намазларына йөри. «Намазга барган саен иманым артканын тоеп кайтам, – дип әйтә. – Әни, әйдә, Мәтәскә авылында мәчет салабыз», дигән сүзне дә башлап улым әйтте. Авылда түбәсеннән су ага торган агач мәчет бар иде безнең. Бу сүзләрне шул мәчетнең кызганыч хәлен күреп әйтте инде ул. 2010 елны намазга бастым. 2013 елны изге эшкә керештек».

Урын алу кадәресе дә ансат кына булмагандыр. Аннан кирпеч кайтарту, осталар табу... Әйбәт осталар Арча кирпеченнән сигез метр биеклектәге мәчет бинасын корып куя. Манара күтәрелә, ихата корып куела. Һәр ишекнең, һәр тәрәзәнең үз тарихы бар. Инде менә мәчет ишегалдына брусчатка җәяр көн дә килеп җиткән. 2300 данә ташның һәркайсы Аллаһыга шөкер әйтеп түшәлгән. Мәчет эченә җәелгән намазлык-келәм теге ахирәтнең яңа мәчеткә бүләге. Корбан бәйрәме җитәрәк зәңгәр нур кебек балкып, күккә ашып торган әкияти (мәчетнең икенче катына менгәч тә җиде кат күк гөмбәзе ачылгандай тоела) рәвешле, «Миләүшә мәчете» рәсми төстә бисмиллалы ишекләрен ачар. Дубай каласында тирән дини белем алып кайткан Илнур хәзрәт бәйрәмгә чакырып, азан әйтер. Мәтәскә авылы өстеннән бабайлар рухын шатландырып, изге Коръән сүрәләре яңгырар...

PRESSA.RU



САБА НИГЕЗЕ

Фәнзилә МОСТАФИНА

ТӨП НИГЕЗ, ТӨП ЙОРТ. БУ ТӨШЕНЧӘЛӘР ТАТАР ХАЛКЫНДА ГОМЕР-ГОМЕРГӘ ИЗГЕ САНАЛГАН. СОҢГЫ ВАКЫТТА ГЫНА КЫЙММӘТЛӘР ҖУЕЛЫП БАРА.







«Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы татар милләтенә кагылышлы актуаль темаларны күтәрү, югала барган гореф-гадәтләрне халыкка кайтару җәһәтеннән тырышлыгын дәвам итә. Оешманың чираттагы күчмә утырышы Сабада үтте. «Төп нигез», «Васыятьнамә» кебек четерекле темаларга багышланды ул.

Тарту көче

Саба районы Башкарма комитеты рәисенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары Таһир Шәрәфиев әйтүенчә, Сабада 11300 ләп гаилә бар. Дөньяның төрле кыйтгаларыннан җыйналган 150 хатын-кызга үрнәк итеп күрсәтү өчен шул гаиләләр арасыннан яхшыларын сайлап алганнар. Андый сайланыш үтү өчен, дөрестән дә, күз өстендә каш булырга кирәктер!

Кызыл Мишә авылында гомер итүче Гаттаровларны авылда гына түгел, районда да белмәгән кеше сирәк. Данлыклы, мактаулы нәсел. Дөнья буйлап сибелеп яшәсәләр дә, төп нигезгә әзне суытмый торган нәсел. Төп нигездә әби белән бабай – тугызынчы дистәне ваклаган Зәләфрүз әби белән Тәлгать бабай Гаттаровлар исән-саулар. Кунакларны да Зәләфрүз апа үзе каршы алды. Ә артында – ныклы тыл: биш бала, кияү-киленнәр, 15 онык, 11 турун... Төп нигездәге нәсел җыенына өч айлык сабыйга хәтле күтәреп алып килгәннәр. Бу бәләкәч әлегә әтисенең ышанычлы кулларын гына тоя, бераз үсә төшкәч, нигез һәм нәсел ныклыгын да тоя башлар.

Төп нигезнең тарту көче диген. Кызыл Мишә авылы егетләре, солдат хезмәтеннән кайткач, барысы да диярлек Свердлау өлкәсенә заводта эшләргә чыгып китә башлый. Тәлгать тә кызыга анда китәргә. Авылда эш тә юк, шунда китәм, дип җыена башлаган улын әнкәсе туктата: «И улым, син, үзем үсеп җиткәч, сезне ипигә туендырырмын, дип әйткән идең, китәсеңмени инде?» Шулай итеп, Тәлгать Свердлауга китми кала. Арча районының Үрнәк бистәсендәге техникумга барып, механизатор һөнәрен үзләштерә, әти-әнисенең тамагын икмәккә туендыра. Төп нигезнең дә утын сүндерми саклый. Хәер, заманында әтисе – Гаттар мулла да – шушы ук язмышны үткән була бит. Әтисенең васыятен үтәп, төп нигезне саклау өчен, Гаттар Кызыл Мишәгә кайтып урнаша. Тик авылларында муллалык итә алмый кала. Хәллерәк кешеләрне кулак дип эзәрлекләү башлангач, булган байлыгыннан баш тартып, колхозга керергә мәҗбүр була.

Гаттаровларның төп нигезендәге нәсел очрашуына ерактагы туганнары да кайткан иде. Гөлнур, Рәйханә, Фәимә – Гаттар мулланың олы кызы Гәүһәрнең балалары. Гәүһәр, авылдан беренче булып югары математик белем ала да юллама буенча Кемерово өлкәсенә китеп бара, шунда гаилә кора. Еракка китсә дә, төп нигез белән арасын өзми, балаларына да элемтә җебен тапшыра ала. «Ерак юл үткәнсез, диләр. Ерак түгел ул – Кемероводан 3000 чакрым гына. Нәрсә ул 3000, әле Гөлнур апа, 4500 чакрым үтеп, Иркутскидан да кайтып җитте. Ул да әллә ни ерак түгел, ди. Ә Фәимә сеңлебез: «Ә миңа 5000 чакрым ара да ара түгел – шуның кадәр юл үтеп, Улан-Удэдан очып кайтып җиттем», – ди. Төп нигезне якын итеп, бернинди авырлык та коймыйча кайтып җиттек без», – дип сөйли уртанчылары Рәйханә.

...Кызлар шигырь укый. Шигырь юллары аша Гаттаровлар гаиләсенең, алай гынамы соң, бөтен милләтнең тарихына чумабыз:

Йөз ел элек безнең әби
Килен булып төшкән бу йортка.
Сөйли иде: «Әнкәй белән әткәй
Пышылдаша чаршау артында:
«Нинди килен булыр Оркыя,
Килен бит ул шушы төп йортта».
«Борчылма, карчык, – әткәй әйтә, –
Килен белән бием – бер калыптан,
Өйрәтерсең әкренләп аны да».

Өйрәнә Оркыя, төп нигезнең җылысын саклап кала белә. Үз килене Зәләфрүзгә дә өйрәтеп калдыра. Инде бүген төп нигезнең сагында – яшь килен Резеда. Килен вазыйфасының никадәр җаваплы булуын аңлый Гаттаровлар, шуңа күрә рәхмәтләрен җырга салып җиткерә: «Рәхмәт сезгә, төп йорт киленнәре, төп нигезнең ямен саклаганга...»

> *Шулай эшләмәсә, аны – ерак Себер, ә нигезне эзсез юкка чыгу көткән булыр иде.*

Нигезле нигезсезләр

Әби-бабайлар, оныклар, туган-тумачалар белән шау итеп торган нигезне калдырып, Югары Утарга юл тотабыз. Автобуслар матур гына бер бина каршына килеп туктый. Бу да нигез. Тумыштан акылга зәгыйфь булган, шунлыктан әти-әниләре карый алмаган балалар яши торган нигез. Балалар йорты. Әле генә күргән тулы гаиләдән алган тәэсирләр сүнеп бетмәгән: шау итеп килеп керәбез дә, каршыбызга килеп чыккан балаларны күреп, бер мәлгә аптырап калабыз.

– 1962 елда ачылган балалар йорты бу. Татарстанда мондыйлар икәү генә – Казанның Дәрвишләр бистәсендә дә, бездә. Биредә 4 яшьтән 18 яшькәчә 79 бала тәрбияләнә. Күбесе – «отказнойлар». Сигезенең генә ата-анасы бар, килгәләп йөриләр. Тик бик сирәк... – директор РСФСРның атказанган социаль тәэминат хезмәткәре, «Алтын йөрәкле кеше» бәйгесе лауреаты, 53 ел гомерен шушы интернатка багышлаган Имаметдин Гәрәй улы Гәрәев үзенең икенче йорты турында сөйли. Үзе әкрен генә атлап, балалар йорты белән таныштырып йөри. Биналар төзек, чиста, зур. Тагын берне төзеп бетереп киләләр – Президент 55 миллион сум акча бүлеп биргән булган. Тирә-юньдә чәчәкләр үсә. Экзотик җәнлекләр шактый биредә: дөя, лама, пони дисеңме, тәвә кошы, аккош, тавыкмы... Маймылга хәтле бар. Авыл җирлегендә акылга зәгыйфь балалар йортында тудырылган шартларга сокланып, хәйран калып, директор артыннан атлыйбыз.

Фото: Руслан Һадиев

PRESSA.RU

Тик беренче чиратта игътибарны тәвә кошлары да, маймыллар да түгел, балалар җәлеп итә, билгеле. Аларның 30 ы ятып кына тора – авыр дәрәҗәдәге хасталар. Ә бер ише, әнә, онытылып спорт мәйданчыгында уйнап йөри. Имаметдин Гәрәй улын күрүгә, йөзләренә елмаю куна. «Папочка» дип дәшәләр. Без – чит кешеләр. Шуңа күрә безгә бераз шикләнебрәк, сагаебрак карыйлар. Без дә – шулай ук. Гадәти балалар түгел бит, нәрсә көтәргә белмәссең. Соңрак, балалар йортыннан киткәндә, бу уй юкка чыгачак, әлбәттә. Ә әлегә ул бар. Әлегә без кая килеп эләккәнебезне аңламыйчарак йөрибез.

– Биредә ун ел эшлим инде – әле һаман мондагы балаларның сәламәт булмаулары белән килешеп бетә алмыйм. Курчак театрында уйнарга

Нигезледән нигезсез бу сабыйларны да күреп китү кирәк булган икән.

һәм биергә өйрәтәм мин аларны. Кайвакыт, онытылып китеп, алардан әллә ниләр таләп итәм. Аннары гына барып җитә. И-и, бу балалар моның хәтлесен генә эшли алсалар да бик яхшы бит әле, дим үз-үземә. Хәер, без аларга «тегенди балалар» дип карамыйбыз. Һәм, ышанасызмы, мин бу балалар йортына үзем теләп, шушында эшләргә хыялланып килеп кердем, – дип сөйли тәрбияче Рәмзия Сафина.

Биш-ун минут үтүгә, без дә балаларга ияләшәбез. Шундый ук алар: бииләр, җырлыйлар, сәхнәгә менеп шигырен дә сөйлиләр, сәламәт балалар кебек үк футбол да уйныйлар. Алар гына безгә шикләнеп карауларын дәвам итә. Шулай шул, аларның ышанычын тиз генә яулап булмый. Ә бер яуласаң – мәңгелеккә җитә. Норвегиядән килгән гаилә дә бер баланың ышанычын яулау өчен ике ел йөргән. Ике елдан соң гына баланы уллыкка ала алганнар. Израиль, Иорданиядән дә алып киткәннәр балаларны. Ә Руслан, Рәмис һәм Динарны үз әти-әниләре кайтып алып киткән. Акылга зәгыйфь бала туганын белгәч, балалар йортына тапшырганнар да бераздан кире килеп алганнар. Бүтән беркайчан да аерылышмаска дип. Андый очраклар аеруча кадерле интернат хезмәткәрләренә. Кызганыч, сирәк кенә.

Балалар йорты белән саубуллашып, кире автобусларга төялешәбез. Хатын-кызларны бу балалар йортына алып килүләре дә юкка гына булмаган лабаса.

Милләт нигезе

Чираттагы нигез – район үзәгендә урнашкан сәләтле балалар мәктәбе. 2013 елдан гына эшли әле ул, шулай да үзен уңай яктан танытып өлгерде инде. 2016 елда «Уңышлы мәктәп» грантына лаек дип табылган белем бирү йорты укучылары узган уку елында республика күләмендәге олимпиадаларда – 32, Россиякүләм этапта – 1, ә Халыкара этапта 2 призлы урынга ия булган. Район өчен бик югары күрсәткеч бу!

Бу мәктәптә укучылар, беренче сыйныфтан башлап, инглиз теле белән беррәттән, кытай телен дә өйрәнә. Һәм, әлбәттә, татар теленә дә зур урын бирелә. Югыйсә рус кызы Ангелина Осипова чатнатып татарча сөйләшеп тора алмас иде. Күршедәге Теләче районыннан ул. «Үземне күбрәк яктан ачарга теләдем, шуңа күрә бу мәктәпкә килдем дә. Татарча берничә сүз генә белә идем, монда килгәч, телне яхшылап өйрәндем», – ди 9 нчы сыйныфны тәмамлаган кыз. Дөрестән дә, милләтен әйтмәсәләр, аны татар кызы түгелдер дип уйлап та карамассың.

«Үзебезгә төшкән җаваплылыкны аңлыйбыз, милләтне үстерүгә кечкенә генә булса да өлешебезне кертергә тырышабыз», – ди директор Ләйсән Билалова. Моның дәлиле күз алдында булганга, Ләйсән Рәкыйп кызы әйткәннәр гадәти купшы сүзләр генә булып яңгырамый.

Мәктәпнең горурланып сөйли торган байлыгы да бар. Юк, сәләтле укучылары турында түгел әле сүз, ташка уелган байлык турында. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, архитектор Рөстәм Шәмсутов мәктәпнең диварларын эчке яктан татар халкының борынгы язу тарихы үрнәкләре белән бизәгән. Биш язу да чагылыш тапкан – рун, уйгыр, гарәп, латин графикасы һәм кирилл әлифбасы. Тиңе булмаган дивар – Мәскәү шәһәрендә яшәүче эшмәкәр, мәгарифне һәм мәдәниятне үстерү фонды җитәкчесе Исмаил Әхмәтовның бүләге. Балалар да, укытучылар да, мәктәп турында сүз чыкса, тизрәк шул диварлары белән мактанырга ашыга. Мактанырсың да! Аларда гына бит ул, дөньяда берәү генә!

Мозаика рәвешендә эшләнгән әлеге язулар белән илһамланып, үзләре дә мозаика түгәрәген булдырганнар сәләтле балалар мәктәбендә. «Бер яктан, бу балаларга өстәмә һөнәр бирү булса; икенчедән, матурлыкны күрә белергә өйрәтү», – диләр. Дивардагы татар язулары да, бер яктан караганда, бизәү элементы булса, икенче яктан – нигезең, килеп чыгышың белән танышу чарасы бит.

* * *

Өч көн булдык без Сабада. Өч көн дәвамында нигезләрне барладык. Сабаның нигезләрен. Гаттаровлар кебек берсе өчен икенчесе күкрәк куярга әзер торган нәселләр, Имаметдин Гәрәй улы кул астында эшләүчеләр кебек, чит балаларны да, үз итеп, канат астына алучылар, милләт өчен сәләтле балалар үстереп бирүчеләр булганда, ныклы әле Сабаның нигезе. Тагын бер нигез өчен күңелебез сөенеп кайтты: Татарстанның һәм РСФСРның халык артисты Шәүкәт Биктимеровның да туган авылы Миңгәрдәге нигезе исән. Шәүкәт аганың вафатыннан соң, музейга әйләнгән борынгы йорты янәшәсендә тагын ике нигез калкып чыккан – артистның улы Искәндәр белән кызы Гүзәл салган нигезләр. Пенсиягә чыккач, Казаннан Миңгәргә күченеп кайтырга җыена алар. Төп нигез куенына. Димәк, төп нигезгә дә юкка чыгарга юл куймаячаклар.



Фоторепортаж: www.syuyumbike.ru

ВАКЫТ АГА, РУХ КАЛА

«Татар үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?», «Милләтебез яшәрме, бетәрме?» – бөек Тукайлардан калган сөаль бит бу.

Әгәр дә мәгәр, төрекләр, гарәпләр яки алман, французлар сыман аерым, үзбаш булып яшәгән булсак, әлбәттә, мондый сорау белән ми черетмәс тә идек. Юк шул. Без гомер бакый «рус белән тормыш кичердек сайрашып, тел, гадәт вә әхлак алмашып…» Бәс, шулай булгач, язмышыбыз бу, дип тынычланыйкмы? Хәл-әхвәлебез милләтпәрвәр затларны, «Сөембикә» кебек затлы журнал чыгаручыларны борчымый димени?! Милләт язмышы дөнья тоткасы хатын-кызларга бәйле. Ул бала тудыра, кешегә җан бирә, күкрәк сөтен имезеп үстерә. Туган телендәге беренче аваз, сүзне – бишек җырын бала анасыннан ишетә. Намус, вөҗдан, тугрылык төшенчәсен, тырыш булырга кирәклекне дә балага ана сеңдерә, тәрбия бирә. «Бер кызны тәрбияләү ике угылны тәрбияләүдән макбулдыр (яхшырактыр)», – ди Исмәгыйль Гаспралы. Чирек гасыр элек – 1992 елда «Ак калфак» хатын-кызлары оешмасы дөньяга килүне четерекле хәлләрдән чыгу юлын эзләү дип тә, татар хатын-кызларының белемгә, яңалыкка сусавы, борынгы йола, гореф-гадәтләребезне, халкыбызның яшәү рәвешен, бай тәҗрибәсен онытмаска, ә бәлки яңартырга омтылу дип тә шәрехләргә буладыр. Әйе, хатын-кызлар оешмасын булдыру «Сөембикә»леләр хыялы иде. Баш мөхәррир Роза Туфитуллова, фикердәшләр – Флора Әхмәтова-Урманче, Филисә Хәкимова, Гөлзадә Сафиуллина, Тәэминә Биктимерова, Камәрия Хәмидуллина, Лена Шагыйрьҗан, Розалина Шаһиева, Дания Гаязова, мин фәкыйрегез – Роза Камалетдинова, Лира Ямалиева, Бибинур Сабирова «Ак калфак»ның чишмә башында торуы белән горурлана. Бөтентатар конгрессы Башкарма комитетының идеяне күтәреп, оешманы үз канаты астына сыендыруын бәхеткә юрадык.

«Ак калфак»лылар, җиң сызганып, эшкә дә тотындык. Беренче коймак төерле була, дип юраулар юш килмәде: 1992 елның 15 декабрендә Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры сәхнәсендә узган конкурс-тамашаны рус телле Мәскәү газеталары да югары бәяләп, саллы мәкаләләр бирде. Чынлыкта, Бөтентатар конгрессы, «Сөембикә» журналы белән берлектә «Ак калфак оешмасы гамәлгә куйган «Гыйффәт туташ» – пакь җанлы кыз бала конкурсы олы, милли бәйрәмгә әйләнде. Ә әзерлек эшләре ел буе барды дисәк тә була. Ул елларда популярлашкан «Мисс мира» – «Дөнья гүзәле» тамашаларыннан ул нык аерыла – режиссерлар берәүне дә чишендермәде, бил, күкрәк, буй-сын, йөз матурлыгы түгел, ә бәлки бу бәйрәмдә катнашучы кызларыбызның рухи дөньясы, халкыбызның асыл сыйфатлары – кул эшләренә, милли ризыклар, аш-су әзерләүгә осталыклары, борынгыдан килә торган күркәм йолаларын, гореф-гадәтләрен, җыр, бәетләрен белүләре югары бәяләнде. Чибәрлек ягыннан да ким-хур булырлык түгел иде инсафлы-самими, зирәк, зәвыклы, тәвәккәл, фикерле кызларыбыз. Алар унбер кыз иде. Унбере дә соклангыч иде.

Кошлар пар канатлары белән күккә күтәрелгән кебек адәм баласы да Иман һәм Акыл канатында Кеше дигән биеклеккә күтәрелә. Чираттагы «Киленбикә» бәйгесендә – уллар-кызлар үстергән, кайнана-кайнатасы белән тату яшәгән уңганнар конкурсында катнашырга теләүчеләр без көткәннән дә күбрәк булып чыкты. Халык зур ул, шагыйрь ул, җырчы ул, гаҗәп тә талантлы ул, дип сокланырга гына калды. Тынгысыз җанлы, эзләнүчән баш мөхәрриребез Роза Рәхмәтулла кызы җитәкләгәнгәме, ул елларда «Ак калфак»ны Сөембикә» белән бербөтен итеп күзаллый идек. Чит илдән кайтамы, якындагы авылдан килеп төшәме, ярдәм өмет итепме, кылган эш-гамәлләребез өчен рәхмәт ирештерү нияте беләнме – халык редакциягә килә. Башкортстаннан Фәридә Кудашева, Дилә Булгакова, Халисә Мөдәррисова, Мәскәүдән Нәзифә Кадыйрова, Прагадан Фәрит Иделле, Фәридә Хәмид, Америка, Австралия кыйтгаларыннан – чит илләрдән әллә кемнәр – үзебезнең татарларыбыз кайтып төшәр иде. Һәркайсын сөенеп каршы алабыз, әңгәмә корабыз, хәлдән килгәнчә кунак итәбез. Милләтнең уянуы, берберсенә тартылуы, бергәлекнең кадерен белүе дип кабул иттек ошбу вазгыятьне. Үзебез дә гел йөреп тора идек. Төмәндә, Пермьнең Барда ягында, Сембердә, Түбән Кама, Чаллыда «Ак калфак»ның бүлекчәләре оешты. Казанда кызлар гимназиясе ачылды.

Вакыт үтә, еллар уза. Шәһәрләр урыныннан куба. Ә милли рух кала. Милли рух исән булса, татар яшәр. Яшәсен, дип яшибез.

Роза КАМАЛЕТДИНОВА





PRESSA.RU

– НӘКЪ КИНОЛАРДА КҮРСӘТКӘНЧӘ БУЛДЫ... НИКАХ ЙӨЗЕГЕ, ЧӘЧӘКЛӘР... «МИҢА КИЯҮГӘ ЧЫГАСЫҢМЫ?» – ДИ. АКЫЛЫМ БЕЛӘН: «НӘРСӘГӘ КИРӘК ИНДЕ БУ?» ДИМ, Ә ҮЗЕМ: «ӘЙЕ...» – ДИП ҖАВАП БИРӘМ...



Гөлнур САФИУЛЛИНА

«БӘХЕТЛЕ МИН...»

Тормышы нәкъ икегә шушы көнне бүленә инде Айна Зеттерлундның. Исеме ят кебек тоелса да, сезнең күбегезгә бу ханым таныш. Белмим, дияргә ашыкмагыз әле. Беренче тормышында аның фамилиясе Еремина булган дисәм? Җырчы кыз Вероника Ереминаны, әлбәттә, хәтерлисез бит. (Ал күлмәктән, эшләпәдән, кәрзин тотып, Вәсим Әхмәтшинның «Җиләккә дип барган идем» дигән җырын җырлый-җырлый сәхнәгә чыккан чая кызны, аның: «Эһе-һей!»ын ничек онытасың?!) Ә Әнүзә аның әнисе инде.

Тәмам бутадыммы? Айна – аңа абыйлары кушкан исем. (Айнагөлне шулай кыскартканнар). Якыннары аңа гомер буе шулай эндәшә. Танышканда ул үзе дә һәркемгә: «Мин – Айна», – ди. Әмма әтисе туу турында таныклык алырга баргач, авыл Советында барысын да үзләренчә хәл итәләр: «Андый исем булмый», – дип, «Әнүзә» дип язып кайтаралар.

Башкортстанның Караидел районы Седәш авылыннан Айна 15 яшьтә үк чыгып киткән. Гомеренең күп өлеше Татарстан белән

бәйле аның. Лениногорскида белем ала, Биектауда хезмәт юлын башлый. Кияүгә чыга. Юллар Чаллыга алып килә...

– Тынгысыз кеше мин, – ди ул. – Башта заводта «Бәллүр чишмә» ансамблен оештырдым, кызлар тугач, эшкә балалар бакчасына урнаштым, анда тәрбиячеләрдән ансамбль тупладым. Шәһәрдә беренче урыннар ала башладык. Күрделәр... Мэриягә, милли мәдәниятне үстерү буенча баш белгеч итеп мәдәният идарәсенә алдылар. Чаллы – күпмилләтле кала бит, 18 милләтнең үз җәмгыяте бар иде ул чакта. Шуларның барчасын бер сәхнәгә туплап, «Дуслык һәм туганлык – иң зур байлык» дигән фестиваль уздыра башладым. Бу фестиваль Чаллыда әле дә уза.

Әмма аны бөтен республикага «Шатлык» яшьләр үзәге таныта. Ул чакта Чаллыда вице-мэр булып эшләүче Йосыф Якубов: «Яңа гына яшьләр һәм спорт министрлыгы оешты, сиңа анда эшләү күңеллерәк булачак, күч, – ди. – Нинди теләгең бар, үтим», – дип тә өсти.

«Бар минем теләкләрем, – ди Айна. – Берәү түгел – өчәү!» Үзләре яшәгән комплексның яшүсмерләр клубында оештырган фольклор ансамблендә матур гына җырлаучылар бар. Казанда, Мәскәүдә фестивальләрдә чыгыш ясадылар, бер төркеме Болгариягә үк барып кайтты. Инде үз кызы – Вероникасы да сәхнәгә аяк басты менә. Гомер буе баянга җырлап йөрмәсләр бит?! Аранжировкалар ясарга кирәк, кыскасы, студия кирәк аларга! «Нәрсә соң ул «студия»? Нинди була? Татарстанда бармы ул?» – ди вице-мэр. «Юк Татарстанда андый студия. Безнеке беренче булачак!» – дип җавап бирә Айна. Анда нинди аппаратуралар булырга тиешлеген санап күрсәтә, күңеле исә ышанмый: кая инде, рөхсәт бирмәсләр, бигрәк кыйммәт бит...

Ә иртән бүлмәсендә телефон шалтырый: «Счет әзерләгез!» Кирәкле аппаратураларны алып кайтырга Мәскәүгә барырга аңа автобус һәм... ике автоматчы бирәләр. Кайчандыр йорт җиһазлары сатылган иске кибет бинасында исә ремонт башлана: яшьләр үзәген шунда ачарга карар итәләр. Анда иң элек студия бүлмәсе әзер була.

Инде – икенче теләк. «Балаларның өстендә барысы да үзебез теккән кием генә. Сәхнәгә биергә оекбаштан чыгалар бит. Килешми...» – ди Айна. «Монысын үтәү – иң җиңеле, эшлибез», – диләр аңа.

Өченчесе... «Каядыр чыгыш ясарга чакырылмаган көнебез сирәк. Сәхнә киемнәрен күтәреп йөреп ардык инде. Бәлки, кечкенә генә автобус алып булыр?» Айнаның бу соравына: «Аз гына сабыр итегез... Тагын бер генә ел», – диләр. Сүзләрендә торалар – бер елдан үзәкнең үз автобусы була.

Утыз алты иҗат төркеме оеша «Шатлык»та! Меңгә якын бала йөри! Студия булгач, җырчылар үсә башлый. Алып баручылар. Бию төркемнәре. Мода театрлары... Шәһәрдә нинди бәйрәм бар – һәрберсенең уртасында алар. Алай гынамы – бәйрәмнәрне үзләре дә уйлап чыгаралар. Шәһәрнең бөтен ресторанннарын, икмәк пешерү комбинатларын чакырып, алар катнашында урам тутырып «Уңыш бәйрәме» үткәрү дисеңме. Кул эшләре күргәзмәсе, яшь шагыйрьләр һәм композиторлар бәйгесе, иҗат кичәләре... Чаллыда хәзер дә һәр елны республика көненә туры китереп «Чәчәк бәйрәме» уздыруларын беләсез инде. Ә менә аның иң беренчесе «Шатлык» каршында үтүен, мөгаен, күпләр хәтерләмидер. Айна идеясе! «Үзәк янәшәсендә генә җир асты юлы бар. Анда гел чәчәкләр саталар. «Ә сез икебаналар ясыйсызмы? – дип сорыйм берсендә. – Әйдәгез, «Шатлык» янында чәчәкләр бәйрәме үткәрәбез. Сез чәчәкләрегезне тезегез, ә без җырларбыз, биербез», – дим. Ризалаштылар...» Аннан бу идеяне коммуналь-торак хуҗалыгы идарәсе башлыгы Геллер Яков Вениаминович күтәреп ала: «Безнең хуҗалыклар арасында ярыш итеп уздырыйк без аны. Кемнең ишегаллары, кемнең чәчәк бәйләмнәре иң матуры? Мәдәни программасы сездән булыр», – ди. Чәчәк бәйрәме шулай итеп мэрия янындагы мәйданга күчә.

«Шатлык»та яңалыклар гел туып тора! «Бэллидэнс» дигән сүз колагына чалынуга, Айна бер төркем кызларын Мәскәүгә, шәрык бию курсларына чыгарып җибәрә. Алар кайтуга, бу биюне өйрәнергә теләүчеләрдән чират тезелә. «Брейк-данс» та Чаллыга «Шатлык» аша тарала. Яшьләрнең урамдагы бер мәйданда хип-хоп биегәннәрен Мәскәүгә баргач Айна үзе күреп кайта.. Үзәктә эшләүче егетләрнең берсенә аны үзләрендә оештырырга тәкъдим итә. Тегесе кызыксынып китә.

«Ул миңа һәр җомга саен роза чәчәкләре бүләк итә. Инде җиде ел!»

Вероникaның җырлый башлавы үзе үк әллә күпме яңалык алып килә. Ул тамашачы каршына чыгуга, аның артыннан ук сәхнәгә биючеләр, шоу-балет яки мода театры килеп чыга. Күргән хәлме?! Шәһәрдәге иң беренче шоу-программа була ул!

Вероника... Әнисенең шатлыгы, горурлыгы һәм... йөрәк ярасы да бугай ул. Кечкенә кызы җырлый башлагач, Айна үзе, иҗаты турында бөтенләй оныта. Югыйсә җырлары инде радиоларда яңгырап, танылып килгән чагы була. (Сүз уңаеннан, Казанда узучы мөселман киносы фестивале хәзер дә ел саен Айна Ереминаның «Йә Ходаем» җыры белән ачыла һәм тәмамлана.)

Иң беренче катнашкан бәйгесе үк Вероникага уңыш алып килә. Озын бөдрә чәчле, күзләре янып торган, яңгыравык тавышлы 5 яшьлек кызчык жюрины да, залдагы тамашачыны да үзенә гашыйк итә. Такмаклар җырлый ул:

PRESSA.RU



Вероника-га сəхнəдəн китəргə туры килде. Хатын-кыз өчен гаилəдə бəхетле булу мөһимрəк...

татарчадан русчага да бик җиңел генə күчеп китə. (Теллəр өйрəнергə, гомумəн, сəлəтле булып чыга Вероника: соңрак ул үзенең концертларында 11 (!) телдə җырлый башлый: төрекчə, инглизчə, итальянча, япончa, гарəпчə...)

«Швед ирлəре башкалардан самимилеклəре белəн аерылып тора».

Бер-бер артлы халыкара бəйгелəргə чакырулар килə. Грециядə кызык кына хəл була. Вероника чыгыш ясагач, бер төркем əти-əнилəр Айнаны эзлəп табалар. Буйга яшьтəшлəреннəн калкурак күренгəн, сəхнəдə үзен иркен, ышанычлы тоткан, чын профессиональлəрчə чыгыш ясаган кызны олырак дип уйлаганнар икəн – документларын күрсəткəч кенə тынычланалар. «Укытучысы кем?» – дип кызыксыналар. «Мин – əнисе, аның белəн үзем шөгыльлəнəм», – ди Айна. Болгариядəге фестивальдə дə башка балаларның əти-əнилəре: «Нигə безнең белəн беррəттəн профессиональ җырчы да катнаша?» – дип тавыш чыгаралар. «Чын җырчы»га бу вакытта 13 яшь кенə булуын берсе дə күз алдына китерми.

Килəчəген Вероника үзе дə, əнисе дə бары тик сəхнə белəн генə бəйлəп карыйлар. Ə чынлыкта... чынлыкта барысы да башкача килеп чыга.

– Казанга укырга аны атаклы бер җырчыбыз чакырды. Исемен əйтмим... Кайта да елый Вероника: «Минем белəн шөгыльлəнүче юк, укытучы минем якка карамый да», – ди. Концертларга да куймыйлар. Тəмам аптырадык... Аннан карыйм, баланың техникасын боза башладылар. Диапазоны, тын алышы бик яхшы иде аның. «Кызым, тукта, алга таба укырсыңмы-юкмы, белмим, лəкин анда башка бармыйсың», – дидем. Ул өйдə калды...

«Инде нишлəргə?» – дип бəргəлəнгəн көннəрдə, Вероникага Израильдəн бер танышы шалтырата. «Мин синең мөмкинлеклəреңне дə, сиңа кем ярдəм итə алачагын да белəм, – ди ул. – Тик ул кеше Америкада яши».

– Шушындый талантларның да кадерен белмəгəч... – дип каршы ала аны Авадала Хан. Инглиз теленең америка диалектын өйрəнергə кирəк дип, башта ул Вероникага Нью-Джерси лингвистика һəм халыкара мөнəсəбəтлəр университетына укырга урнашырга ярдəм итə. Аннан эстрада артистлары əзерлəүче Манхэттен академиясенең атаклы укытучысы Тамара Кашур белəн очраштыра. (Селин Дион, Тони Брекстон, Кристина Агилераларны йолдыз ясаган белгеч бу!) Кат-кат тыңлый Кашур кызны һəм ахырда нəтиҗə ясый: «Ходай миңа, күрəсең, тагын бер йолдыз ачарга насыйп иткəн...»

Сəгатьлəре генə түгел, минутларына кадəр бүленгəн көннəр башлана: университетта уку, вокал буенча дəреслəр, эшкə – ябык клубта чыгышлар ясарга йөгерү... Əмма чибəр яшь җырчыга карата бөтенлəй башка төрле планнар корырга өлгергəн меценатка аның тəүлеклəр буе югалуы ошамый башлый. Юллар аерыла... Тик Верониканың язмышы барыбер Америка белəн бəйлəнгəн булып чыга. Ул анда мəхəббəтен очрата һəм бер елдан кире əйлəнеп кайта. Ə җырчы булам, дигəн хыялдан инде аерылырга туры килə.

– Вероника иреннəн бик уңды, алар бик матур яшилəр. Тормышы бик көйле, үз йортлары, – ди əнисе. – Хатын-кыз өчен гаилəдə бəхетле булу барысыннан да мөһимрəк бит...

Ике баласын ялгыз аякка бастырган, көн-төн эштə булган əнилəренең тормышы күз алдында – Вероника да, апасы Лариса да «беренче урында – гаилə бəхете» дип саныйлар бугай. Ларисасы да Швециягə шулай дип чыгып китə.

– Кинəт өйдə генə түгел, илдə ялгыз калдым да куйдым. Балалар еракта... Тəрəз янында елап басып торган аналарны аңлыйм мин. Үземə шул көн килде...

Ə аннан бер Яңа елда бөтенесе Стокгольмда Ларисаларда җыелырга булалар. Нью-Йорктан Вероника кайта. Чаллыдан əнилəре килə.

– Бəйрəмнəр узды. Телевизор карап утырам шулай. Кызлар икəү чыш-пыш нидер сөйлəшəлəр. Сүзне олысы башлады: «Əни, карале, синең белəн бер ир-ат дуслашмакчы», – ди. Танышулар сайтына теркəлеп, минем исемнəн берəү белəн хат язышып ята икəн болар. «Туйдырдыммыни сезне?!» – дим. «Юк, сине анда берүзеңне калдырасыбыз килми, безнең янда булыр идең», – дилəр. Аның сине күрəсе килə, дип, мине киендереп очрашуга чыгарып җибəрделəр. Тел белмим, дип аяк терəп каршы торам, ə алар: «Ул русча белəм дип язды», – дилəр.

Бардым. Сыңар чəчəк тотып басып тора бу. «Кайдан күргəнем бар минем бу кешене?» – дим. Шулкадəр таныш! Аннары аңлап алдым – əтигə охшаган лабаса ул! Русчасы «исəнмесез, хəллəрегез ничек» диюдəн узмады. Əмма сөйлəшəбез! Ул үзенчə сөйли, мин – үземчə: ничектер аңлашабыз... Аңа кадəр бер төш күргəн идем. Поездда барам икəн. Бер станциядə каршы якка баручы поезддагы ир-ат миңа нидер эндəште. Ишетмим, якынрак барыйм əле, дисəм, үз поездым кузгалып китте. «Борчылма, миңа

кайтырсың, өем моннан 15 минутта гына», – ди миңа теге ир-ат... Вокзалдан Ларисаларга кадәр электричка 15 минут бара, Еранның өенә исә каршы якка утырып китәсе. Һәм нәкъ 15 минут барасы!

Февраль аенда Чаллыга кайтып киттем. Еран белән саубуллашып тормадым. Нигәдер кирәксенмәдем... «Әниең миңа нигә үпкәләде икән? Нәрсәне ошатмады?» – дип Ларисага әллә ничә шалтыраткан, «Татарстанга ничек барасы?», – дип юлларны белешкән. «Сезгә килергә җыенам», – дип миңа да хәбәр итте. Килеп кергәнче ышанмадым... Ә аннан, «яңа тормыш башлау миңа нигә кирәк соң?» дип уйласам да, күзләремә карап җавап көткән кешегә: «Риза», – дигәнемне сизми дә калдым...

Дөрес эшлимме, дигән уйлар бик озак тынгы бирмәде әле. Мондагы бар дөньямны ташлап китәргә кирәк: дусларны, танышларны, туганнарны. Телне белмим диярлек – өйрәнә алырмынмы? Күнегеп булырмы? Икенче яктан – анда кызым, киявем, оныгым, анда мин ялгыз түгел. Директор вазыйфасын 1995 елдан бирле башкарам, бик арган идем инде. Кичке Сабантуйда аңымны җуеп егылгач, «туктарга кирәк, җитәр» дидем.

Стокгольмга килүгә, курсларга язылдым. Сигез ай эчендә швед теле буенча сигез баскыч үтәргә кирәк иде. Үттем! Швед телендә шигырьләр язып шаккаттырдым әле үзләрен. Еран да бик тырышты: русча әллә никадәр сүз өйрәнде. Тел белгәч, безнең тормыш җиңеләйде...

«Бөтен бәхетем – тормышымның көзенә калган икән», – ди Айна ханым. Психотерапевт булып эшләүче ире аның һәр теләген үтәргә әзер! Айнаның оныгы Рөстәм аның өчен дә якын: кечерәк чакта һәр ялны ул аларда уздырган. Айнасының татарлары да якын...

«Китсәм – тыныч кына яшим», диюе нәкъ ике елга җиткән Айна ханымның. Аннан: «Швециядә бердәнбер татар без генә түгелдер», – дип милләттәшләрен эзли



башлаган. Һәм, әлбәттә, тапкан. Башта җырчы Гөлүзә Зыятдинованы, аның аша калганнарны: Ләбибә апа, Земфира, Камилә, Зәйтүнә, Венера, Эльвираны... «Кызлар, безгә килегез, җырлар өйрәнербез», – дип аларны үзләренә чакырган. Һәркайсы өчен җан рәхәте булган ул очрашулар... Ригада узган беренче Европа Сабантуена Швециядән 58 кеше җыелып барганнар. Чыгыш ясар өчен җырлар өйрәнгәннәр, Айна ханым бию куйган, махсус шигырь язган. Берлинда узган икенче Европа Сабан туена оештыручылар Айна Зеттерлундны инде режиссер итеп чакырганнар. Аурапа татарлары альянсы утырышы (Лондон), Татар мәдәнияте көннәре (Венгрия), «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы утырышы (Казан), Европа татарларының өченче Сабантуе (Вильнюс)... Аның оештыру сәләте һәркайда кирәк. Көзгә «Европа гүзәле» бәйгесе уздырырга ниятлиләр, аның да режиссеры Айна ханым булачак дип торалар. «Монда яшәвем бу кадәр дә кызыклы, вакыйгаларга бай булыр дип көтмәгән идем, – ди ул. – Иремә рәхмәт. Юл чыгымнарын ул күтәрә. «Бу бит синең тормышың», – ди. Яз көне абыем авырып китте дә аның янына Уралга барып кайттым. Вильнюс Сабан туеннан соң исә мине әнә Нью-Йоркта кызым Вероника көтә».

«Европа Сабантуенда чыгыш ясар өчен сигез кызга сигез татар костюмы тектем».

Еран Зеттерлундның татар хатыны аның дуслары өчен дә күптән үз кешегә әйләнгән инде. Айна татар ашлары пешергән көнне ул аларның һәркайсына хәбәр сала: «Килегез!» Өчпочмак ашарга, кош теленнән авыз итәргә, токмачлы аш белән сыйланырга... Кыстыбыйның ни икәнен дә беләләр, ә бәлеш дисәң, егылып китәләр!

Башкаларның хатыннары нарат җиләген, мүк җиләген кибеттән сатып алганда, Айнасының аларны урманнан чиләк-чиләк үзе җыеп кайтуы, кыш буе ашарлык итеп катырып куюы, урманда үсүче алмалардан как ясавы, сок чыгаруы, гөмбә җыюы белән горурлана Еран.

Бәхетлемен, дуслар, бәхетле мин,
Язмышыма мең-мең рәхмәтле!

Айна Зеттерлундның бер шигырендә шундый юллар бар. Аңлашыладыр, соңгы вакытта туган бәхетле шигырьләренең берсеннән.

PRESSA.RU

Милләттәшебез Зөлфирә ТРЕГУЛОВА – сәнгать дөньясында танылган, абруйлы белгеч. Бик аз гына аралашкан арада без аның турында күбрәк белергә, ул яшәгән дөньяга төрле күзлектән карарга тырыштык. Журналист язган сурәт, бәлки, эскиз дәрәҗәсендә генә килеп чыккандыр. Ни хәл итсәң, мәшһүр картиналар өчен дә элгәре эскизлар ясала. Безнеке – төрле жанрда, төрле стильдә...

Ләйсән
ЮНЫСОВА



ЯЗЫЛЫП БЕТМӘГӘН ПОРТРЕТ

«Шаһзадә Аккош» Казанга килде! «Гасыр даһие» дип исемләнгән күргәзмә кысаларында Казан эрмитажында тамашачыларга тәкъдим ителгән «Царевна-лебедь»» картинасы рәссам Михаил Врубельнең иң мәшһүр картиналары исәбендә йөри. Шуңа күрә бу картинаның Казанга килүе Татарстанның сәнгати елъязмасында истәлекле вакыйга сыман кабул ителде. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиеваның илнең иң мәшһүр музейлары белән багланышлар урнаштыру җәһәтеннән туган аралашулары Татарстан Президенты ярдәмчесе Наталья Фишман инициативасы белән дәвам итте. Бар дөньядан яңа технология, үсеш юлларын барлап, аларны республикага китертү юлларын эзләүче Илбашыбыз да бу эшкә теләктәшлек күрсәтте. Бүтәнчә була да алмый. Чөнки әлеге проект дөньяның иң югары стандартларына таянып эшләнде, һәм ул Республикага музей эшчәнлегенә мөнәсәбәтле яңа эш ысулларын да алып килде. Бәлки нәкъ менә шушы нәрсә әлеге күргәзмәне уникаль итәдер дә. Третьяков галереясы директоры Зөлфирә Трегулова күргәзмә ачылышына Казанга килгәч, бу күргәзмәнең Россия киңлекләрендәге беренче төбәк проекты булуын гына искәртте, һәм аның Мәскәү, Санкт-Петербург кына түгел, ә бәлки дөнья стандартлары дәрәҗәсендә оештырылуын билгеләп үтте. Зөлфирә ханым эшне оештырудагы бу яңалыкның республиканың калган музейлары – ә аларның хәзинәләре «җанлы» экспонатларга аеруча бай! – эшчәнлегендә дә чагылмый калмасына өметләнүен дә белдерде.

Безгә – гади тамашачыларга – бу технологияләрне чамалап алу җиңел булмас – бер-берсен баета торган төсләр һәм нурлар балкышында яктылыкның күп мәгънәле хасиятен дә без, бәлки, тоеп бетерә алмыйбыздыр. Әмма профессионаллар командасының биниһая олы хезмәтенең хикмәте дә шунда – тамашачы залга килеп керүгә үк XX гасыр башы атмосферасына чумсын, тарихи вакыйгаларга да, җәмгыятьнең яшәү рәвешендә генә түгел, бәлки сәнгатьтә, хәтта модада да, революцион саналган үзгәрешләргә бай ул заманның рухын тойсын өчен һәр деталь җентекләп уйлаган, дөрес итеп оештырылган яктыртуның һәр әсәрне «уйнатып» җибәрүе, экспозициянең гармониялелеген тәэмин итә икәнлеге бәхәссез. Тамашачы Казан эрмитажы күргәзмәсендә Третьяков галереясыннан килгән 50 картина белән бергә Казан рәсем сәнгате музееннан китерелгән 20 картина белән хозурлана. Төрле жанрларда һәм стильләрдә, төрле сәнгать чаралары ярдәмендә иҗат ителгән булсалар да, бу картиналар бердәм рух, бердәм мәсләк белән өртелгән. Үзәктә торган картина, әлбәттә, «Шаһзадә Аккош». Ә безнең өчен күргәзмәнең үзәк фигурасы – Зөлфирә Трегулова үзе.

Фото: Евгений Алексеев / Третьяков галереясы

Модерн

Без иң әүвәле аны эшлекле, җитди, тәвәккәл, матбугат басмалары арасыннан «Коммерсантъ» газетасын гына сайлап укый торган ханым итеп күрдек. Аның вакыты юк – үзе өчен яңа булган чираттагы шәһәрдә күргәзмә ачуга ук аның, тиз-тиз генә кофе эчеп алып, шалтыратуларга, электрон хатларга җавап биреп, хәбәрләргә күз ташлап, һәртөрле сорауларга җәһәт кенә җавап биреп, тормышның тыгыз ритмыннан тайпылмыйча эшен дәвам итәсе бар. Ул әйләнешкә кереп киткән кыланчык сүзләр белән сөйләшкәнне яратмый. «Концепция» димәс, «фикер» дияр. Киемне үзебезнең осталарныкын гына кияр. Сәнгатькә килгәндә, – «безнекеләргә җитми!» дияр. Журналистларның провокацион соравы әзер: «Мәшһүр «Кара квадрат» чыннан да бөек әсәрме соң ул? Әллә надан булып күренергә теләмәүдән генә пьедесталга куелган әсәрме?» Зөлфирә ханым аздан гына ярсып китмичә кала. Әмма шунда ук үзен кулга алып, безгә – дилетантларга – «патшаның һич тә шәрә патша булмавын», ягъни Каземир Малевичның бу әсәре даһи әсәр булып, сәнгать дөньясында Рафаэль Сантиның «Сикстин мадоннасы» белән бер рәткә куела торган әсәр икәнлеген төшендерә.

Күргәзмәләрнең һәркайсы да бертигез дәрәҗәдә кызыксыну уята алмый.

Профессионал шул Зөлфирә Исмәгыйль кызы! Дөньякүләм танылган музейга директор итеп савыты буш кешене куймаслар! Алай гына да түгел – Зөлфирә Трегулова үз урынында! Хисләремне, аңа мөнәсәбәтемне өндәү билгеләре белән көчәйтеп куйдым куюын, әмма аны ачып бетерә алмадык. Нindирәк кеше ул, ни белән яши? Беренче чиратта – эш белән! Авангард стилендә!

Неореализм

Сәнгатькә чират тору? Бүгенге көндәме? Әйе, мөмкин хәл бу! Чөнки «акчага корылган», стресска төрелгән «җансыз» заманда да рухи азыкка ихтыяҗ бетмәгән!

БИОГРАФИК БЕЛЕШМӘ

- 1955 елда Ригада кинематографистлар гаиләсендә дөньяга килә.
- 1977 елда Мәскәү университетының сәнгать белеме бүлеген тәмамлый.
- 1993–1994 елларда Нью-Йоркта стажировка үтә.
- 1998–2000 елларда А. С. Пушкин музеенда бүлек мөдире.
- 2002–2013 елларда «Мәскәү Кремле» музей-тыюлыгы генераль директорының урынбасары булып эшли.
- 2015 елның 10 февраленнән Дәүләт Третьяков галереясының генераль директоры.
- Ул күпсанлы халыкара күргәзмәләр кураторы сыйфатында Берлин, Бильбао, Венеция, Нью-Йорк, Лондон маршрутларында йөреп кайта.
- Күпсанлы бүләкләре арасында чит илдә бирелгәннәре дә бар.

PRESSA.RU

Данлыклы галереяга эләгү өчен тезелеп киткән озын-озын чиратларда чит илләрдән килгән туристлар гына түгел, бәлки үзебезнекеләр дә байтак. Төрле катлам вәкилләре бар анда – финанс ягыннан төрле мөмкинлектәге кешеләр. Хәтта теге яки бу экспозицияне уздыруда ярдәм итеп, исемнәрен танытырга омтылган меценатлар чираты да бар әле. Әйе, дәүләт ярдәме сизелеп торган заманда да сәнгать шундый хәйриячеләргә таяна. Илкүләм алганда, шөкер, иганәчеләр байтак икән. Бу изге эштә безнең үзебезнең данлы тарихыбыз бар! Һәм Европа, Америка илләрендә чәчәк атучы аерым бер катлам мәнфәгатьләрендә эшләп торучы хосусый галереялар бу тарихта зур урын алмый. Безнең бәхеткә күрә, илебездә сәясәт бер – сәнгать халыкка хезмәт итәргә тиеш! Музейлар арасындагы хезмәттәшлекнең, меценатларны ярдәмгә чакыруның максаты да – халык белән сәнгать арасын якынайту өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдалану, мәдәни байлыкны лаеклы итеп яшәтү, дөньяга күрсәтү, күргәзмәләрне дөньякүләм дәрәҗәдә оештыру. Ә бит картиналарны бер илдән икенче илгә алып бару өчен генә дә гаять күп акча кирәк! Химаячеләр җәлеп итәргә тырышу кадәресе – үзе бер сәнгать. Монда югары профессиональ әзерлек кирәк. Нәкъ менә шушы картинаны күргәзмәгә кую, аны китертү яки сатып алу өчен акча түләгән кеше шулкадәр зур чыгымнарның асылын, максатын һәм дә ки үзе капиталын нәрсәгә салганын аңларга тели – һәм шуны аңлата белү сәнгать белгеченнән үзе бер осталык, белем таләп итә.

Сәнгатькә ярдәм итү элек-электән мәртәбәле шөгыль саналган лабаса.

Халык шулкадәр зур чыгымнар тотып әзерләп, экспозицияләргә «төреп» бирелгән сәнгатьне кабул итәргә әзерме соң? Кирәксенәме ул? Югары мәдәният кыйммәтләре фәкать үтә интеллектуаллар һәм кесәләре калын кешеләр өчен генә ләззәт алу чыганагы булып калмыймы икән? Киң катламның кызыксынуын уяту, халыкның «агылып» музейга баруын тәэмин итү өчен дә музей хезмәткәрләре армый-талмый хезмәт куя. Әйтик, Валентин Серов картинасы куелган күргәзмәне көнгә 2,5 мең кеше карады. Кешеләр, яңгыр дими, җил дими, чиратта тордылар. Залларның мөмкинлеге булса, бу сан тагын да зуррак булыр иде. Димәк...

Акционизм

Әйе, хәрәкәт кирәк! Дөньякүләм танылган шедеврлар яки даһи дип аталган исемнәр кешеләрне күбрәк җәлеп итә, әлбәттә. Ә бит музей фондларында саклanган картиналарның күбесе игътибарга лаек! Гасырлар узган саен бәясе арта гына бара торган сәнгать әсәрләрен – кыйммәтле хәзинәне саклауны тәэмин итү генә җитми әле. Аларны халык хозурына тәкъдим итә, күрсәтә белергә, махсус акцияләр үткәрергә дә кирәк. Бу эштә дә тик тормыйлар! Третьяков галереясының Мәскәү елгасына караган тарафтан да ишекләре ачылды. Кызыклы, затлы сувенирлар сатылучы музей кибете дә эшләп тора янәшәдә. Ишегалды ягында музыка фестивале үткәрелә... Мультимедиа чаралары да хәрәкәткә китерелде. Тамашачыны компьютерыннан, социаль челтәрләреннән аерып, музейга китерү өчен алар ярдәмгә килә. Арзанлы гына, әмма үтемле ролик «сәнгатьтән ерак торабыз» дигән кешеләрне дә кузгатып, музейга алып килә ала икән! Мәсәлән, видеода «терелтелгән» «Персик тоткан кыз» картинасының тизеры ярты миллион чамасы кешене җәлеп итте. Шуларның кимендә меңе музейга килде. (12 яшьлек Верочка Мамонтованың садәлеге, нәфислеге күңелне таң җиле кебек сафландырып алуы хак бит инде, әйеме?).

Галереяга интернет мәйданында гына да виртуаль экскурсияләр ясап алырга мөмкин – бар илләрдәгечә, андый мөмкинлекләр монда да тудырылган – әмма музейга килеп, картинаны үз күзләрең белән күрүгә җитәме соң?! Гасырлар катламын кичеп әллә ничә буын кешеләрне сокландырган картиналар белән хозурлану, шул заман рухын, кичерешләренең тәмен татып, картинага кереп калган кешеләр язмышы белән яшәп алу... – көндәлек мәшәкатьләреннән арынып, мәңгелек каршында туктап алу кебек бит бу. Тормышыбыз стресслар, ыгы-зыгы белән тыгызланган саен бу мизгелләр кадерлерәк тә әле. Моны тансыклаучылар да күбәя бара. Әйтик, Иван Айвазовский картинасы каршында, диңгезнең бниһая кодрәтен, ярсуын, мәһабәт иркенлеген, шашкын бәйсезлеген тоеп, тынсыз калуны ни белән чагыштырасы? (Ә бит Иван Айвазовскийның тамырында да татар каны аккан: әнисе Миңлегөл – кырымтатар кызы, әтисе әрмән кешесе). Хәер, һәр әсәрне һәркем үзенчә тоя, Диңгез белән һәр кешенең үз әңгәмәсе. Һәр кешенең күңелендә үз дулкыны, үз давылы! Әйе, мондый «Һава алыштырулар» һәркемгә кирәктер.

Әлбәттә, мондый мәшһүр музей җитәкчесенең һәр әсәр янында нечкәреп торырга вакыты юк. Аңа инде күбрәк финанс-хуҗалык мәсьәләләрен хәл итәргә, һәр тиенне санап торган килеш тә галереяны гөрләтергә кирәк. Ләкин шулай да директорның йөрәк түрендәге төп урынны теге яки бу күргәзмәне ничегрәк корырга, хәзинәне табынга ничек «тәмле итеп кую» мәсьәләсе биләп тора. Күргәзмәнең идеясен ачыклау, экспонатлар сайлап алу, килешүләр төзү, үз дигәнеңә ирешү юлларын табу өчен дөньяда булып тора торган мәдәни һәм сәнгати яңалыклардан хәбәрдар булу гына аз, бәлки, иҗатчы да, дипломат та, хисапчы да булырга кирәк. Зөлфирә Трегулованың бу өлкәдә тәҗрибәсе бик бай – аның куратор сыйфатындагы иң беренче проекты ук – Вашингтондагы Смитсон институты белән бергә оештырылган «Мәскәү – хәзинәләр һәм традицияләр» дигән күргәзмә Изге ниятле уеннар кысаларында Сиэтл шәһәрендә 920 мең кешене җәлеп иткән.

Классицизм

Хатын-кыз нинди булырга тиеш? Идеал кем образында – «Шарга баскан кыз»ның һава сыман җиңел гәүдәсендәме, әллә «Билгесез ханым»ның серле карашындамы? Юк, юк! Хатын-кыз акыллы булырга тиеш! Һәм әле тагын чыдам да (бар йөкне үзеңә алып, аны «тартып» бару дигән сүз түгел әле бу!). Ул барысына да түзәргә сәләтле. Рус хатын-кызлары образларында болар барысы да чагыла. Әмма ләкин Иван Крамскойның «Билгесез ханым»ы – өлге түгел! Ачык коляскада, вуальдән Аничков күперендә сурәтләнгән ханым һич тә югары даирәдән түгелдер. Лев Толстойның Анна Каренинасын кем генә күрә алды микән аңарда?! Трегулова өчен хатын-кыз идеалы «Сикстин мадоннасы» сурәтендә икән.

Безнең мадоннаның – Зөлфирә Трегулованың юка иңнәрендә нинди авырлыклар күтәргәнен белмибез, әмма аның бу сынаулардан җиңеп чыга алганлыгы шик уятмый. Дөньяның һәм илнең зур-зур галереяларын җитәкләгән сирәк ханымнарның берсе беренче карашка гына җиңел адымнар белән болытлар өстендә йөзгәндәй, ихтирамлы карашларда коенып, атлап бара сыман. Мондый профессиональ уңыш һәм дәрәҗә җиңел генә бирелмәс. Әмма ул яулаган үрләр аңа тыенкы бер көч бирүче, рухи нурын, эчке матурлыгының яктылыгын балкыта торган фон, җирлек булып кына күренә. Бу үрләрне без дә, рәссам Рафаэль Санти сыман, пәрдә артына яшереп торыйк.

Импрессионизм

Төрле төсмерләр белән балкып алучы төсләрнең акварель җиңеллеге хатын-кыз сыны рәвешен ала. Ихтимал, бу хатын-кыз кичләрен ялгыз гына каршылый торгандыр. Әмма көннәре эш-мәшәкатьләргә күмелеп уза, аралашу, хәрәкәт, алга омтылыш тулы алар. Шәхси тормыш хакындагы сораулар нәфис томанда җавапсыз эленеп кала. Аның каруы, гаиләсе, балалары турындагылары салават күперендәге төсләр балкышына, җете төсләргә манылган. Алар – шатлык һәм горурлык чыганагы. Әни кешене тулаем биләп алган мавыгуны балалар аңлыймы, уртаклашамы? Әлбәттә, ул аларга да йоккан. Шулай булмаса, бер кызы Мәскәү университетының сәнгать белеме факультетын сайламас иде. Аерым яшиләр икән. Шуңа күрә әни кешедә иртәнге һәм кичке ашлар кайгысы юк. Кафе-рестораннар барында үзе өчен генә вакытын әрәм итеп тормый. Димәк, икенче җан ризыгына – китапларга вакыт күбрәк кала. Әлбәттә, ул укырга ярата. Рәсем ясый торгандыр дип уйлап та карамагыз. Көне буе бөекләр иҗаты арасында йөргәннән соң, батырчылык итеп, кем генә кулына кылкаләм алыр иде икән? Әлбәттә, сәяхәт итәргә ярата.

Абстракт экспрессионизм

Зөлфирә Трегулова милли йөзне һәм милли сәнгатьне саклау тарафдары. Этнография темасын «изүче» һөнәрчелекне өнәп бетерми ул. Үзен «дөнья кешесе» дип таныган бу шәхесне нindидер милли тамырларга бәйләп куярга тырышу да үзен акламас иде. Балтыйк буенда туып-үскән, бала вакытта Ленинградка килеп йөргән (Эрмитажда беренче тапкыр 7 яшендә булган ул). Хәзер инде Мәскәүдә яши. Аның тормыш офыклары дүрт тарафка да караган. Әмма... төрки канлы әбибабайларның милли ризыклары да хәтер күзәнәкләренә кереп калган. Ул хәтердә тагын бик тә кадерле булып уелып калган сүзләр дә бар. Аерым сүзләр генә шул... Аның каруы, латыш, инглиз телләрендә иркен сөйләшә. Немец, француз, итальян телләрен дә кирәге чыккан кимәлдә белә. Җыйнаклык, өйгә кергәндә аяк киемен салу кадәресе дә татар әни өйрәткән әдәп. Зөлфирә Исмәгыйль кызы Трегулова портретындагы милли штрихлар шулардан артмый. Әлегә...

Меңләгән шедевр каршында сокланып туктап калган профессионал өчен рәссамнардан иң кадерле исем бармы икән? Бар! Ул – Серов...

Әмма Казан... Казан аның йөрәгендә күмелгән милли орлыкларга шытым элдерде бугай. Һәрхәлдә, Казанда ул «минем кызларым Казанга килергә тиеш», дигән фикерне күңелендә ныгытып куйды. Әйдәгез, без бу портретны, үзебезнең милли өслүбтә, тәмамланмаган килеш калдырыйк.

ҮЗЕ ТУРЫНДА ҮЗЕ

■ 1938 елда минем әниемә паспорт биргән чагында Терегулова урынына Трегулова дип язып куйганнар. Ярый әле Сәйдә Хәсән кызын Зинаида Ивановна итми калганнар. Монысы өчен дә рәхмәт.

■ Мин зыялы гаиләдә туганмын. Алар инде мәрхүмнәр. Әтием сугыш кичкән кеше иде. Фронт операторы сыйфатында Потсдам конференциясен төшергән ул.

■ Мин бик дөрес гаиләдә үстем. Нindидер язылмаган кануннарга буйсына идек без. Гаделлек, хакыйкать кануннарына. Алла сүзеннән дә өстен йөри торган кануннар иде бу.

■ Мин мәктәптән кайтып, әниемә Павлик Морозов турында сөйләгәч, әнием миңа иртәнге дүрткә кадәр безнең гаиләбез тарихын сөйләгән иде. 1929 елда репрессияләнгән сигез балалы бабам язмышын шул чагында беренче мәртәбә ишеттем. Әбиемнең балаларын качырып кына Урта Азиягә алып китүен, аның төннәрен авызындагы алтын тешләрен сындырып утыруын ишетеп тетрәндем. Сындырмас иде – балалары ашарга сорый. Минем әнием бәхетенә, Сталинның мәшһүр мәкаләсе дөнья күрә. «Бала атасы өчен җавап тотмый» дигән сүзләр канунга әйләнгәч кенә әниемә – төпчек балага югары уку йортына юл ачыла. Ә бит әниемнең өч абыйсы Бөек Ватан сугышында ятып калган...

■ Балаларымның әтиләре ягыннан бабалары, немец шпионы саналып, Лубянка төрмәсендә атылган. Менә шулай. Мин атаанама ифрат рәхмәтлемен. Алар мине әледән-әле Ленинградка йөртеп, зәвыгымны тәрбияли алганнар.

PRESSA.RU



Бу дөньяга моңга уралып килгән, бар төнен шигырьгә салган, ак болыт булып елмайган, җил булып пышылдаган сабый күңелле, өрфия җанлы Әлфия бит ул! Аһәңле, нәзакәтле шигърияте белән укучылар күңелен яулаган Әлфия Ситдыйкова! Актанышның Күҗәкәсендә туган, Чаллыда яшәп иҗат итә. «Йөрәгемә яфрак сыена», «Җанда кабынган учак», «Назга сусау», «Хәтер җебе» китапларыннан хисләре шигырь булып, моң булып түгелә.

Каләмдәшебезне түгәрәк гомер бәйрәме белән котлыйбыз!
Иҗат уңышлары телибез!

Әлфия СИТДЫЙКОВА

МОҢ ТҮГЕЛӘ...

* * *

Учымда төн. Ак кәгазьгә
Тама илһам тамчысы.
Бөтен җанны айкап ала –
И бу иҗат ачысы.

Бар төнемне, кулдан килсә,
Салыр идем шигырьгә,
Илһам уты янып бетеп
Әйләнгәнче күмергә.

* * *

Тиле күңел әй түгелде
Кардай ап-ак кәгазьгә.
Үз туксаны туксан аның,
Карамый һич вәгазьгә.

Шигырь булып түгелә дә
Күтәрелә җыр булып.
И өрфия күңелкәем,
Син гүя ап-ак болыт!

Әйт әле

Син минем дөньямның ишеген
Кыймыйча шакыдың сак кына.
Җаным да, тәнем дә төренде
Шул чакта тылсымлы ялкынга.

Йоклаган өметне уяттың,
Күшеккән җаныма ут капты.
Кулымнан тоттың да җыр булып
Күңелгә югалган моң кайтты.

Өр-яңа көй булып яңгырый,
Кадерлем, җиһанда исемең.
Әйт әле, ни уйлап шакыдың
Син минем дөньямның ишеген?

* * *

Үлчәп булмый микъдарларда
Яратуның серле көчен.
Мин сөюдән яралганмын,
Сөелер һәм сөяр өчен.
Үлчәп булмый чакрымнарда
Озынлыгын гомерләрнең.
Яши-яши аңлыйсың ул
Мизгелләрнең кадерләрен.
Үлчәп булмый бәхетләрне
Бизмәннәргә салып һич тә.
Минем бәхет миндә яши,
Үз җанымда булган көчтә.

Тынлык тавышы

Тынлыкны тыңлыйм да таң калам,
Шундый тын: вакытмы тукталган?
Табигать, бар Җиһан, Кешелек
Башлана икән бер ноктадан.

Мең төрле уй минем башымда,
Йокысыз төн яна кочакта.
Йомгакка уралган уйларны
Сүтәм дә ягам мин учакка.

Йолдызлар чакыра үзенә,
Нур сибеп, яктыртып җиһанны.
Тын калып тыңлыймын тынлыкны,
Ябынып серле күк-юрганны.

Моңлы язмыш

Мин дөньяга килгән чагымда ук
Килгәнмендер моңга уралып.
Моңлы язмыш тәкъдир тарафыннан
Куелгандыр алдан юралып.
Сандугачлар моңы сеңгән талдан
Әткәй үргән миңа бишекне.
Ак теләкләр тели-тели, әнкәй
Дөньялыкка ачкан ишекне.
Ялан тәпи атлап киткәч җирдән,
Бәбкә үлән биргән моңнарын.
Иркен ялан кочагында аунап,
Җанга салдым моңын кылганның.
Боргаланып аккан инешнең дә
Йөрәк тойды челтер тавышын.
Мәңгелеккә җуймый саклар өчен
Сеңдергәнмен барлык сагышын
Авылымның һәрбер урамының,
Миңа ачык һәрбер ишеген
Хәтер сандыгында барлый-барлый
Тибрәткәнгә күңел бишегем.
Моңнар белән тулы минем язмыш,
Моң түгелә һәрбер шигырьгә.
Әле ярый моңсыз булып яшәү
Язылмаган минем гомергә.

Бер җылы сүз

Күңел – сабый. Сөю-назга мохтаҗ,
Олыгаеп инде килсә дә.
Бер җылы сүз җитә күтәрергә
Көчең җитмәс йөкне җилкәдә.
Бер җылы сүз канат куя иңгә,
Тылсым өреп гүя яшәртә.
Бар дөньяны якты нурга күмеп,
Йөрәккә дәрт өстәп яшәтә.

* * *

Җиде диңгез, җиде тауны кичтем,
Табалмадым тансык сөю илен.
Җәй кулыннан алып булалмады
Шаулап чәчәк аткан бәхет гөлен.

Җиде диңгез сагыш суын эчтем,
Җиде тауның ваттым кыяларын.

Кыялардай челпәрәмә килде
Яшьлегемдә корган хыялларым.

Җиде диңгез дулкыннары юды
Йөрәгемнең тирән яраларын.
Җилләр сипте ак бәс чәчләремә
Һәм урлады күзем караларын.

Җиде ятлар ишетмәде зарым...

* * *

Чык та төшеп өлгермәгән әле
Балачагым баскан эзләргә.
Йомшак кулы белән болын җиле
Песи баласыдай сырпаланып,
Иркәләнеп сарыла тезләргә.

Шул ук кояш балкый күк йөзендә,
Нурын сирпеп алсу гөлләргә.
Зәңгәр томан булып урала да,
Язмыш булып кабат юрала да,
Сагыш сеңә үткән көннәргә.

Ялантәпи басып, әле яңа
Үткән идем яшел чирәмнән.
Көмеш пәрәвезләр кай арада
Соңгы җиле булып җылы җәйнең
Күбәләктәй оча тирәмнән.

Гомер үткән, көзгә кереп барам...
Чык тамчысы минем күзләрдә.
Балачакның ал кояшы,
Төсле күбәләкле ямьле җәе
Озата бара алтын көзләргә.

* * *

Хыял дәшкән якка – читкә киттек,
Читтә сүттек гомер йомгагын.
Җан сусаган чакта, дәрман беткәч,
Гел авылга кайта юлларым.

Кендек җебен кулга тоткан килеш,
Гамьнәр җыеп йөрәк түренә,
Менә-төшә күпме еллар аккан,
Кызарынган офык күренә.

Авыл тарта әле кендеге дә
Төзәлмәгән газиз баласын.
...Үги итмәс: соңгы тукталышны
Белә шунда кайтып табасын...



Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетында аңа татар халкы каршындагы фидакарь хезмәте өчен Рәхмәт хаты тапшырылды. Бәләбәйдә узган «Илһам чишмәләре» бәйгесендә әлеге татар егете Гран-прига лаек булган иде. Башкортстанда яшәп иҗат итүче Рабит Фәтхине тарихчы, шагыйрь, татар язмышы турындагы публицистик язмалары буенча яхшы беләләр. Аның шигырьләре турында: «үз тәме, үз суты, үз әрнүләре бар; алар милли гамь белән сугарылган», – дип язалар.

Рабит ФӘТХИ

БЕР ЙОЛДЫЗ УЛ...

* * *

Сөюләрне челпәрәмә итеп
Әллә кемнәр керде арага.
Күпме еллар шуннан хыялландым
Күзләреңә кабат карарга.

Менә тагын син янымда минем,
Сүнгән күзләремә җан өрдең.
Күкрәгемә сыймый йөрәк тибә,
Бәхетемнән кабат исердем.

Сине уйлап күпме хыялландым,
Үкенечләр өчен кайгырдым...
Май аеның җылы бер көнендә
Яшьлегемә кабат кайтардың.

Фәрештә

Күңел төшкән вакытларда
Җан җирдә аунап ята.
Шул чакларда бер фәрештә
Хәлгә кереп юата.

Хәтеремә килеп төшә
Өзелеп сөйгән кешем.
Бары аны уйлап кына
Табамын яшәү көчен.

Минем өчен бер йолдыз ул,
Күктән генә назлаган.
Фәрештә һәм кешеләргә
Кавышулар язмаган...

Яңгыр

Күк гөмбәзе тишелгәндәй
Яңгырлар коеп-коя.
Дөньяны болыт басса да,
Күңелем сафлык тоя.

Яннарыңа ашкынамын,
Беләмен холыкларың.
Мин килүгә таратсаңчы
Күңелем болытларын.

Безнең гомер

Син көткәндә мин килмәдем.
Мин килгәндә син көтмәдең.

Барысы да ялгыш булды...
Бер-беребезне яратсак та,
«Син» дип, «мин» дип җан атсак та,
Әллә нинди язмыш булды...

Син сөйгәнне мин белмәдем,
Назларыңа күмелмәдем.
Күрдем бары күзләреңнән
Сагышлы яшь түгелгәнен.

Безне сөю табыштырды,
Саф мәхәббәт кавыштырды...
Тик шулай да...
Бөтен гомер ялгыш узды...
Гомер тоташ сагыш булды.

«Кем гаепле?» – дип сорамыйм,
Икебез дә гөнаһлыдыр...
Сөю кадерен белмәгәнгә
Син дә, мин дә моң-аһлыдыр.

Ул моң-зарлар бетмәстер дә...
Мәңге калыр күңелләрдә...
Син көткәндә мин килмәдем...
Син көтмәдең мин килгәндә...

PRESSA.RU



Кәрим КАРА

БЕРӘҮГӘ БЕРӘҮ КИРӘК

(Хикәя)

«Берәүгә берәү кирәк». Кирәк икән шул... Кирәк!..

Киң караватында әкрен генә сөйләгән телевизорга текәлеп утырган Зөлфия кат-кат кабатлый бу сүзләрне. Сәгать инде төнге өченче. Тәрәзә артындагы дөм караңгылык, әйтерсең, бүлмәгә үтеп керергә, Зөлфиянең аңын томаларга тели. Бәлки шуннан да яхшысы юктыр аның өчен: онытылырга, онытырга, бернәрсә дә белмәскә-күрмәскә. Тән газаплары да, җан газаплары да юк ди тегендә, яшәү аръягында...

Караватка терәлеп торган коляскада кыштырдаган тавыш хатынны айнытып җибәрә. Әллә уянырга итәме Тәслимәсе? Шуышып килеп, ул зәңгәр атлас юрганга төренеп тәмле йоклаган сабыена күз сала. Борылып кына яткан, ахрысы. Тыныч булды аның кызы, ничек саласың – шулай йоклый, иртәнге алтылар тирәсендә генә тавыш бирә: тамагы кибеп китә торгандыр. Шешәдәге сөтне чупылдатып имеп куя да тагын онытыла, рәхмәт төшкере. Тыныч булуы белән әтисенә охшагандыр инде. Юк, юк, үзенә генә охшаган кызы, Зөлфиянеке генә ул. Кайдадыр олаккан ир кисәге белән нинди уртаклыгы булсын аның? Мендәре янына килеп ул тагын күзләрен телевизорга текәде. Нәрсә карап утыра иде соң әле ул? Әнә теге алып баручы илдә барган төзелешләр турында сөйлиме соң. Ил кайгысымы Зөлфиядә, нинди төзелеш ди ул, булганы дөбердәп җимерелеп бара аның. Шул җимерекләр астында калырлармы бердәнбере белән, исән кала алырлармы. Нәрсә эшләргә икән?.. Ах, эшләүче табылган монда. Син, акыллым, бернәрсә дә эшли алмыйсың ич, нәрсә булса булыр дип көтәсе генә кала.

Җайсыз кузгалып, телефонын идәнгә төшереп җибәрде. Тын алырга куркып коляскага текәлде. Уянмады бугай, бигрәкләр дә ботаклы булып китте соңгы араларда үзе. Кичә әнә яраткан чынаягын төшереп ватты. Әллә уйлары таркауландыра, әллә көче-хәле бетте беләкләренең. Йокысызлыктан да килә торгандыр. Атна инде рәтле-башлы йоклый алганы юк, утыра менә шулай тартмага текәлеп, кулына берәр китап алган була, алдаштыра, янәсе, үз-үзен. Утны сүндереп ятуы була, шундук юкка чыга йокымсыраулар, бетмәс-төкәнмәс уйлар йомгагы тәгәри, әйди үз артыннан, үкендергән үткәннәр йөрәккәен әрнетә, билгесез киләчәктән салкын тирләре бәреп чыга, курку биләп ала.

Иртәгә балалар кухнясына бара торган көн. Анысын ничек хәл итәргә? Верага шалтыратырга кирәк булыр. Чатанлап булса да барып кайта ул, озаграк йөри, көтеп изаланасың. Әйбәт кыз үзе, ярдәм итәргә генә тора. Ә гаиләсендә артык кашык инде менә, гел кыерсытырга гына торалар. Аннан башка тагын дүрт малай да бар әле. Әти-әнисе якындагы өйдә ишегалларын җыештырып йөри. Акчаны алалар да одеколонга тыгып та бетерәләр. Күп вакыт өйдә сыңар икмәк сыныгы да булмый. Вераны кўралмыйлар. Малайлар – безгә тиешлене ашый дип, әти-әнисе – акчасын бирми дип. Ничек бирмәсен, ашаганнары гел Вераның пенсия акчасыннан, малайларга да, арзанрак булса да, кием-салым алырга тырышып ята әле. Ә бит Вера җиткән кыз, матур киенәсе дә, иннек-кершән ягып йөрисе дә килә. Көн саен егетләр янынннан да үтә ул. Гарип булса ни, сез әллә гарип кызлар егетләр турында хыялланмый дип уйлыйсызмы?

Шул җитмәгәнлек бераз бозган инде аның холкын. Зөлфиягә кунакка килсә, үзе хуҗабикә булып, беренче эш итеп чәй куеп җибәрә, плитә өстендәге бар кәстрүлләрне тикшереп чыга, аннан суыткычтан эзләнергә тотына. Өйдәгеләрдән зарлана-зарлана, бар булган ризыкны сыптырып чыгып китә. Бертуктаусыз ашап торса да, талчыбык төсле нечкә үзе. Көн дә эләкмидер шул кунак булулар. Акчага да комарлыгы бар, бер сум күрсә дә күзләре янып чыга, әҗәткә сорый башлый, әмма кире ала алмыйсың инде аннан ул бурычларын.

Күпме утырырга болай, йокларга кирәк. Карават өстендә таралып яткан китапларны янындагы тумбочкага тутырганнан соң, Зөлфия бүлмәсенә күз йөгертеп чыга. Уф, бар почмакларда үрмәкүч оялары, идән тулы чүп-чар, тегендә-монда бәргәләнгән әйберләр. Шамиле белән бер дигән шкаф та эшләп куйганнар иде дә соң, аны урнаштырыр өчен тагын кемгәдер ялынырга кирәк бит әле. Кемгә кем кирәк бүгенге көндә? Хәер, аралашкан кешеләре дә үзе кебегрәк – ярты кешеләр. Ялгыз башы икенчерәк иде әле, сәламәтлеге дә зарланырлык булмады. Кайдан тапты үз башына ул Шамилне. Аңамы инде ир хатыны булып, бала багып яшәргә... Истә чакта Верага дигән акчаны аерып куярга кирәк. Әз бирсәң, хәзер авызы турсая. Җәлләмәс иде Зөлфия, үзе дә бит шул пенсия акчасын кысып-кымтып яши. Шамил бар чагында ике кешенеке ярыйсы була иде әле. Уф, тагын шул килеп керә уйларга. Онып инде син аны, кызыкай. Бер киселгән икмәк кире ябышмый. Син кирәк түгел аңа, кызы да кирәкми. Берәр күңеллерәк нәрсә турында уйла. Мәсәлән, Яңа ел бәйрәмнәре турында. Их, кайчан җитә инде ул көннәр! Гадәттә, аларны бәйрәмгә кадәр үк бәләкәй автобусларда төрле чараларга йөртә башлыйлар, концертларга чакыралар, колясkaларын чыршы янына ук терәп диярлек куялар. Ылыс исе башларны әйләндерә, күңелле музыка йөрәкне җилкендерә. Тирәякта матур киенгән шат йөзле кешеләр биеп әйләнә, ахирәтләре нидер сөйләп кинәнә – бергә булуларына шатланып туя алмыйлар. Ярата андый бәйрәмнәрне Зөлфия. Бәйрәм кәефе өчен генә түгел, нәкъ әнә шундый көннәрдә дүрт саны төгәл булган, тазалыклары бөркелеп торган гап-гади кешеләр, шул исәптән, акча капчыгы булган бизнесменнар бу җирдә гарип-гораба кешеләр дә барлыгын исләренә төшерәләр. Елына бер тапкыр гына булса да күңелләре нечкәреп, игелекләре артып, шул тормыш тарафыннан кыерсытылган бәндәләргә әзме-күпме ярдәм итәргә тотыналар. Андый көннәрдә Зөлфиянең бүлмәсе бүләкләр белән тула, тәмле җиләк-җимеш, апельсин, мандарин исләре борынны кытыклый, шампан шәраблары идәндә тезелеп утыра. Өчәр литр сыешлы савытлардагы көнбагыш мае, зур-зур каплы затлы чәйләр, төрле ашамлыклар шактый озакка җитә әле, Зөлфиянең тиеннәрен янда калдыра. Бик тә юмартлары кеше ышанмастай бүләкләр дә ясап куялар. Әнә теге грузин абый аларның җитәкчеләре белән килеп кергәч, кып-кызыл тартмадан өрфия ак күлмәк алып, Зөлфиянең алдына салган иде. Кайдан башына килгән диген! Әйтерсең, Зөлфия андый күлмәкләр кия ала?! Кигән очракта да, кечкенә гәүдәле Зөлфиянең артыннан сөйрәлер иде ул. Шул мизгелләр исенә төшкәндә, барыбер күңел җылынып китә. Шамил белән икәүләп көлешә-көлешә сыйпап карыйлар иде ул затлы әйберне. Хәзер алып карый да алмый инде. Шкафның иң өске катына пөхтәләп төреп салынган күлмәк, бары Шамиле генә песи җитезлеге белән үрмәләп иң өскә кадәр менә ала. Уф, тагын Шамил... Йокларга кирәк, йокларга!.. Иртәгә бит көне буе Тәслимәсе кырында бөтереләсе бар аның. Акча дигән иде бит әле, акча, акча...

Актарына торгач, калын матрас астыннан акча янчыгын тартып чыгарды. Кызыл янчык таушала төшкән булса да, иң кадерле әйбер өйдә. Кызыл төстәгесе кирәк акча янчыгының диләр бит, янәсе әнә шул кәгазь кисәкләренең дә ниндидер сиземләве бар, имеш, нәкъ кызыл төскә тартылалар икән. Бу турыда Зөлфиянең кайдадыр укыганы бар иде, шуңа бар күңеле белән ышанып, гел кызыл төстәге янчыклар алдырта. Тик акчалар гына никтер бик тартылып бармый янчыгына, әллә төсен аермыйлар. Аның керер дәүләте ташка бастырылган төсле: ай саен бер үк пенсия акчасы.

Кадерләп, тигезләп салынган йөзлекләрне, иллелекләрне, унарлыкларны бүлгәләп тезеп, тагын бер кат санап чыкты Зөлфия. Төгәл җиде йөз илле сум, ә ай ахырына кадәр тагын унөч көн бар әле. Илле сум гына бирсәң, азсына инде ул Верка, тагын авызын турсайта. Ике тукталыш үттем, чиратта тордым дип, арттырып сөйләр. Верамы соң инде ике тукталышны автобуста үтә торган кеше? Титаклап йөгереп бара ул араны, аның бит бер як янбаш буыны гына тыңламый. Билетка түләдем дип күз дә йоммый алдашачак. Сүз көрәштереп булмый, тагын кирәге чыгачак. Бер йөзлек аңа китәчәк дигән сүз. Бала памперслары да ифрат кыйммәт тора икән, атна саен бер капны буяп куя Тәслимәсе. Йә ярар, үзенең тамагын бераз кысар, барыбер бала имезәсе юк. Шамиле китте дә, хәзер сөт төш-

PRESSA.RU

ми күкрәкләренә. Ярый кызы-алтыны тавыш куптармады, хөкүмәт сөтенә өйрәнде дә куйды. Ашауга артык исе китеп тормый Зөлфиянең, көннәр буе бер кабымлык ризыксыз йөрергә мөмкин. Кайчакларда мәҗбүр итеп кенә өстәл артына утыра, көч керсен буыннарга дип тырыша. Бер чынаяк чәй белән ике кисәк сохари – гадәти ризыгы аның.

Җан биргәнгә юнь бирер, дип үзен тынычландырып, ул сул якта торган урындыкны үзенә табарак тартып китерде. Бар эшкә оста күрше Василий дәдәсе аның аякларына кечкенә подшипниклар беркетеп биргән иде. Иләмсез коляскага утырып бүлмәдән бүлмәгә ничек йөрмәк кирәк? Нидер аласы була, газ плитәсендә ашарга пешерәсе, керләр уасы – әзмени хатын-кыз эше? Тәслимәсен ничек багар иде ул җайсыз коляскага утырып? Ә бу урындыкта ул теләгән почмагына тәгәри генә. Тырышып-тырмашып эшләрен төгәлләгәч, ниһаять, урыны өстенә килеп ятты, йокларга өмет итеп күзләрен чытырдатып йомды. Барыбер йоклап китә алмады, тәмам арып күзләрен ачты: тәрәзә артындагы дөм караңгылык, әйтерсең, бар фигыленә үтеп кереп бара иде. Ирексездән, яшьләре бәреп чыкты, авыр ыңгырашып, мендәренә капланды. Япа-ялгызы бит ул бу дөньяда. Ничекләр яшәргә тиеш соң ул алга таба? Әллә, могҗиза булып, ярдәм кулын сузучы берәр изге бәндә табылырмы? Кемгә кирәк инде Зөлфия җиде айлык кызы белән? Кемнең кемдә ни эше бар хәзер? Башкаларның исәпсез-хисапсыз туганнары, дуслары, чутлап бетереп булмастай байлык-дәрәҗәләре, данлы нәселләре. Ә Зөлфиянең кеме бар да, кем ул үзе башкалардан ярдәм-өмет итәрлек? Кем син, Зөлфия?..

* * *

Зөлфия Әлмәттәге эшчеләр бистәсендә дөньяга килде. «Зәп-зәңгәр күзле, шалкандай таза идең бәләкәй чагыңда», – дип искә ала иде мәрхүмә әнисе. Тәпи киткәч тә, абыйлары белән урамда чабып йөргәндә кирпеч өеменә абынып егылган. Анысын Зөлфия үзе хәтерләми, якыннары сөйләүләре буенча гына белә. Эштән кайткан әти-әнисе хәрәкәтсез яткан кызларын күреп шакката. Ике абыйсын каешлап, сорау алырга тотыналар. Малайлар нәрсә, йөгереп килдек, Зөлфия кирпечләр өстендә ята иде, торгызырга азапландык, тормады, апкайтып караватка салдык, дип, күз яшьләренә төелеп сөйләп бирәләр. Иртән иртүк әтисе кызын больницага алып китә. Төрлечә тикшерәләр табиблар, бүлмәдән бүлмәгә йөртәләр, рентген, тагын ниндидер аппаратлар ярдәмендә карыйлар. Күренеп торган үзгәрешләр тапмыйлар, төрлесе төрлечә сөйли, уртак фикергә килә алмыйлар. Нәрсәләр генә сөйләмәсеннәр, кызыкайның аяклары хәрәкәтсез кала. Кара кайгыга калган әти-әнисе, кап-кап дарулар алып, кызларын күтәреп кайтып китәләр.

Шул вакытлардан белә башламадымы икән үзен Зөлфия? Ул чаклар аның хәтерендә ак халатлы кешеләр арасында яшәү булып сакланып калган. Елның күп вакытын ул төрле хастаханәләрдә үткәрә иде. Табиблар шәфкать туташлары да йөзгә чибәр, озын алтын чәчле, шат күңелле кызчыкны үз күрәләр, өйләреннән тәм-том салып киләләр, сөеп-яратып кына торалар. Башка төрле тормышны күз алдына китерә алмый иде Зөлфия, бары көненә әллә ничә тапкыр кадаган уколлар, куелган системалар, ачы дарулар газапка сала иде аны. Аякларының хәрәкәтләнгәнен ул бөтенләй хәтерләми, йөреп китүнең нинди булганын күз алдына китерә алмый, әмма үзе белән бергә ятучыларның тып-тып йөгерүләренә көнләшеп карый иде. Әнә ахирәтләре терелеп кайтып китә бит, ул да бердәнбер көнне караватыннан сикереп төшеп, үз өенә – абыйлары, әтисе-әнисе янына кайтып китәр әле.

Кызның аңлашылмаган катлаулы чире турында кайбер врачлар диссертацияләр яздылар, халыкара симпозиумнарда чыгыш ясадылар, фәнни журналларда озын-озын мәкаләләр бастырдылар. Тик Зөлфиянең сәламәтлегендә алга китеш сизелмәде. Ясалган операцияләрнең саны дистәгә якынлашканда, бер табиб күзгә күренерлек борылыш ясады. Зөлфия, кечкенә култык таякларына таянгалап булса да, атлап китте. Шатлыкларының чиге булмаган ата-ана кызларын тизрәк алып кайтырга ашыкты. Медицина өлкәсендә чәчләре чаларган карт хирург аларны ашыкмаска үгетләп карады. Кызыгызны йөгереп йөрер хәлгә китерәчәкмен, дип антлар итте. Әмма башлары әйләнгән әти-әни ишетмәде карт табибның сүзен, болай булгач, йөреп китә инде Зөлфия, дип инандылар.

Чынлап та, берничә ел эчендә алга китеш сизелде: өй эчендә тотынгалап булса да йөри иде Зөлфия, урамда өч тәгәрмәчле балалар велосипедында да җилдерә. Шулай да мәктәп яшенә кергәч, укытучылар аны өйгә килеп укыттылар. Бер яктан, мәктәпкә кадәр ерак иде; икенче яктан, үз-үзен карарлык буламыни гарип бала? Әмма укырга бик өлгер булды ул, яхшы укыды. Кыз бала булгач, өйдә дә кул арасына керде, бәрәңге әрчеп пешерергә куйды, мүкәләп йөреп идәннәрне сөрткәләде. Ни әйтсәң дә, балачак вакыты – күз белән каш арасы – сизелми дә үтә, үзенең башкалардан аерылып торганын артык тоймады да шикелле ул. Яшьтәшләре арасына кереп, урамда булды, хәленнән килгәнчә уйнады-көлде, кемнеңдер үзен кыерсыткан чакларын да хәтерләми шикелле. И ул чактагы уеннар, ахирәтләре белән таганда атынулар, эскәмиягә тезелешеп утырып серләшүләр...

Яшүсмерлек чорына кергәндә, үзенең язмыш тарафыннан кимсетелгән икәнен белә-аңлый башлагач, кызыкай читләште иптәшләреннән. Һәрвакыт аңа жәлләп яисә мыскыллап карыйлар төсле тоела башлады, гарьләнде, үз эченә бикләнде, юк кына сәбәптән дә үксергә тотынды, өйдәгеләрне күралмас булды. Шундый булганына әти-әнисен, туганнарын гаепле санады, сүз кушкан кешеләргә энәләрен тырпайтты. Кичә урамда бергәләп уйнаган малайларга бүген егетләр кыяфәте керде, култык таякларын сөйрәп йөргән сансыз кызга читтән генә карадылар. Йомрыланып киткән ахирәтләре дә күбрәк чүпрәкләр



Рәсем: Наталья Васильева

турында сөйләшеп, бизәнә-төзәнә башлады, клублар, танцылар белән кызыксынды. Шау-шулы, музыка яңгыраган, мәхәббәт-сөю хисләре уяткан очрашуларга аягын сөйрәп титаклаган ахирәтен ияртеп бармас бит инде башында акылы булган кыз бала? Нинди егет күз салсын шундый парга, кем биюгә чакырсын? Элеккеге дуслары белән бәйләп тоткан җепләр шулай бер-бер артлы шартлап өзелә барды. Авыр, бик тә авыр иде ул чакларда Зөлфиягә. Нигә мин шундый? Нигә миңа гына бирелгән бу газаплар? Әнә шулай тыпырчынган йөрәге бераз урынына утырды. Акылы белән үзенә бирелгән сынауларны берничек тә үзгәртергә мөмкин түгел икәнен аңлады, әмма шул килеш тә яшиләр ич кешеләр, миңа да яңбаштан яшәргә өйрәнергә кирәк дигән нәтиҗәгә килде. Акыллы кыз иде Зөлфия, күңеле дә изгелектә иде, Тәңре тазалыкны әзрәк бүлгән икән, аның монда бер гаебе дә юк бит, өйдәгеләр дә аңа гел яхшылык теләп, әти-әнисе аны абыйларыннан ныграк та ярата әле. Күп вакытын өйдә үткәргәч, хәленнән килгәнчә бәйләмен дә бәйләде, чигүен дә чикте, әнисенең иске «Зингер» тегү машинасында тегәргә остарып китте.

Үзенә тиң ахирәт тә тапты ул. Күрше урамда яшәгән Кәримәнең дә артриттан соң аяк-куллары тыңламас булып калган икән, култык таякларына таянып, эзләп тапты шуны, дуслашып киттеләр. Яңа ахирәте пешеренергә бик оста булып чыкты. Ике кыз, төрле ашамлыклар әзерләп, плитә янында мәш килделәр.

Җиткән кыз – матурмы-ямьсезме ул, акыллымы-җүләрме, ябыкмы-юанмы, сәламәтме-гарипме – серле табигать кануннарына буйсынып, егетләр турында, егет белән кыз мөнәсәбәтләре турында хыяллана башлый. Ничек була икән ул ярату? Кочаклашу дигәннәре нәрсә була икән? Абау, иреннәргә иреннәрне терәп үбешәләр дә икән әле! Ничек инде шул мәхәббәтсез сиңа кагыла, әле бер юрган астында да йоклый, диләр... Тагын әллә нәрсәләр уйлап бетерәләр. Ярыймы, ярамыймы – мондый уйлар бер кыз баланы да урап үткәне юк әле. Шулар җилкендерә, дулкынландыра гүзәл затларның дулап типкән йөрәген.

Кыш җиткәч, көтмәгәндә-уйламаганда Зөлфия дә килеп эләкте шул могҗизалы җәтмәгә. Кышкы көннәрдә кая гына бара инде ул, шуңа күрә күп вакытын ялгызы өйдә үткәрә торган иде. Кайчакларда, бераз күңел күтәрү өчен, телефон аша башына килгән теләсә нинди номерны җыеп, таныш булмаган кешеләрне шаяртырга ярата. Ниндидер исемнәр әйткән була, төрле тузга язмаган сораулар бирә, телефонны алган кемдер гаҗиз кала кызның сөйләүләреннән. Соңыннан Зөлфия, ул сөйләшүләрне исенә төшереп, рәхәтләнеп көлеп куана. Бервакыт телефонны, тавышы буенча чамалаганда, егет кеше алды. Зөлфиянең җүләр сорауларына ачуланмады, киресенчә, аның уенына кушылып китте, төрле кызыклар сөйләп күңелен ачты. Шулай озак кына сөйләштеләр. Кызның иртәгә дә шалтыратуына вәгъдәсен алгач кына трубканы куйды егет. Сөйләшә-сөйләшә, уртак фикерләре барлыгын аңладылар, нәрсәләр турындадыр кызып-кызып бәхәсләштеләр, бер-берсе турында көннән-көн күбрәк белделәр. Егетнең исеме Заһит икән, озак вакытлар иркенләп сөйләшә алуының да сере ачылды: янгын сүндерүче булып кизүдә тора икән ул. Телефон аша сөйләшүләр

PRESSA.RU

Зөлфияне үзгәртте дә куйды. Өс-башына игътибарлырак була башлады, башкалар күрмәгәндә, көзгедән озаклап үзенең йөз сызыкларын тикшерде, бизәнергә-төзәнергә хирысланып китте. Берәр сәбәп чыгып, Заһит белән сөйләшми торсалар, тәмам чиргә сабышты. Хыялында егетнең йөзен төсмерләргә тырышты, ягымлы тавышын уйлап, хисләргә бирелде.

Яз башланганда Заһит һәр сөйләшкән саен очрашыйк дип ялынды. Син миңа ошыйсың, интектермә, зинһар, сыңар күз белән генә булса да күрим, дип очрашу таләп итте. Төрле сәбәпләр табып, очрашу мизгелләрен озаккарак сузды кызыкай. Моңа кадәр үзара барысы турында да сөйләшеп беткән булсалар да, Зөлфия ниндидер эчке сиземләү белән үзенең зәгыйфьлеге хакында Заһитка әйтергә кыймаган иде. Әйе, озын кыш буена бер-берсенә берегеп бетте алар, якын кешеләргә әверелделәр. Әмма егет аны шундый халәттә күрсә нәрсә дияр? Шунысыннан бигрәк тә курка иде Зөлфия.

Төрле яклап уйлаганнан соң, очрашуга барырга булды. Иптәш кызы Кәримәне дә үзе белән алды. Күпкә алдан килеп, парктагы эскәмиягә утырдылар, култык таякларын куе сирень куаклары арасына яшерделәр. Читтән караганда, башкалардан һич тә аерылып тормыйлар. Зөлфия ахирәтенең чирдән таяк юанлыгы калган аякларын каплар өчен озын итәк киярgә мәҗбүр итте, ә үзенең аяклары аның ни җитте кызларныкыннан күпкә матуррак та иде, тик менә кузгатып кына булмый аларны... Билгеләнгән вакыт җиткәч, егет килде. Шаярып-көлеп, кызлар янына утырды, нәрсәләрдер сөйләгән булды. Шундук сизде Зөлфия, ошатты аны Заһит, гел аңа гына карап торды. Ошатмаслыкмыни? Таралып төшкән калын алтынсу чәчләр, куе керфекләр, фирүзәгә тиң зәңгәр күзләр, чиядәй янып торган иреннәр. Гәүдәсенең өске өлеше бик килешле иде аның: кабарып торган күкрәкләр, кысып буылган нечкә бил, кигән киеме дә ярыйсы гына... Егет кызларны йөреп килергә әйдәкли башлады, кафега чакырды, егетлеген күрсәтеп, чибәркәйләрне сыйларга иде исәбе. Менә шунысыннан Зөлфиянең коты очты да инде: яныннан титаклап барырмы култык таяклары белән? Зөлфиянең ай-ваена карамыйча, Заһит аны тартып торгызмакчы булды, кыз асфальтка көлтә төсле авып төште. Агарынып калган егет, нәрсә булганын аңлап җиткермәстән, һаман Зөлфияне тарткалап, аякларына бастырмакчы булды. Шунда иптәш кызы Кәримә арага керде:

– Тимә аңа, йөри алмый ул. Әнә агач арасыннан култык таякларын алып бир!

Аптырашта калган Заһит куаклар арасына кереп китте, Зөлфия тотына-таяна урынына утырды. Чыкты кулларына таяклар тотып Заһит, кызлар ягына карамаска тырышып, аларны эскәмия читенә сөяп куйды. Һәм... йөгерә-атлый китеп тә югалды. Яшьләренә буылган Зөлфия шул чакта ант итте: башка бер егеткә дә күтәрелеп карамаска, кияүгә чыкмаска. Хәер, кем алсын инде бер зәгыйфьне үзенә кәләш итеп...

* * *

Зур шәһәрләрдә, гадәттә, табигать тарафыннан үгисетелгән затлар, гарипләр, оешмалар оештырып, бер-берсенә хәлдән килгәнчә ярдәм итеп, бербөтен булып яшәргә омтылалар. Зөлфия, бәхетенә, әнә шунда үз тиңдәшләрен барып тапты. Ниһаять, күңеле урынына утырды. Уй-хыяллары бер иде аларның, аралашулары җиңел иде, бар яклап та әйбәт иде инде бу урында кызыкайкага. Көннәренең күп өлешен ул оешмага бүлеп бирелгән кысан гына бинада үткәрә башлады. Чирләр, дарулар, дәваханәләр турында гына түгел иде сөйләгәннәре, зарланып яшь түкмәделәр, кайнап торган тормыш белән яшәделәр. Бер иске генә «УАЗ» беркетелгән иде аларга. Һич тик тормады машина. Әле җыелышып табигать кочагына чыктылар, кино-театрларга бардылар, төрле кул эшләре әзерләп, балалар йортларына бүләкләр илттеләр, җырладылар-биеделәр, концертлар куйдылар хәтта. Зөлфиянең уйламаган яктан сәләте ачылды: бик килештереп рәсемнәр төшерергә остарып китте ул. Хәтта оешманың гербы да аның куллары белән ясалды: яшел яфраклы сынган нечкә генә агач кәүсәсен саклап торган терәк! Барысы да бик ошатты рәсемен. Безнең язмышны чагылдыра, диештеләр. Хәер, арада талантлылар күп иде: кайсысы шигырь яза, кайсысы өздереп җырлый. Әнә шулай өч еллап вакыт узып китте. Бу чорда Зөлфия язмышында авыр сынаулар да булды. Пенсия яшенә дә җитәлмичә, бер-бер артлы әтисе белән әнисе үлеп китте. Гомер буе агулы цехта эшләү кыскарткандыр инде гомерләрен. Ярый, иптәшләре Зөлфиягә терәк булдылар, хәлләреннән килгән кадәр ярдәм иттеләр, ялгызын калдырмадылар. Бу вакытта бер абыйсы, гаилә корып, ерак Сахалин утравына барып урнашкан иде. Икенче абыйсы: «Армиядә калырга булдым», – дип хат язды. Шулай итеп, Зөлфия ялан кебек фатирда ялгызы торып калды. Бирешмәде, үз тормышын үзе көтәргә өйрәнде, теләсә нинди эшне эшләргә җайлаша иде ул. Кайчандыр биргән антына тугры калган булса, тормышы тыныч кына бер көйгә агар иде дә бит...

Көтмәгәндә-уйламаганда аларның кечкенә коллективында яңа кеше пәйда булды. Тубыктан аягы киселгән, Зөлфиядән дүрт-биш яшькә яшьрәк, шомырттай кара күзле Шамил иде ул. Егет бик дуамал иде, аякларым юк дип тормады, тубык башына күннән тегелгән бияләйләр кидереп, коридорларны бер итеп чабып йөрде. Теленә шайтан төкергән иде үзенең, кайдан уйлап чыгарып тора! Аны тыңлый-тыңлый, тәгәрәшеп көләләр барысы да. Зөлфия аны энекәше төсле кабул итте: тегендә чаптырды, монда йөгертте, кырык төрле йомыш тапты – һич эшсез тотмады. Әнә шул Шамил, ай үтмәде, «миңа кияүгә чык», – дип, Зөлфиягә бәйләнә башлады. «Яратам, синнән башка яши алмыйм», – дип үзәгенә үтте. Зөлфия көлеп кенә карады аның кыланмышларына, барысын уенга борды, артык бәйләнә башласа, кычкырткалап та туктатты. Аның яшендә Зөлфиянең башында да җил уйный иде, сөйләр сөйләр дә туктар әле дип уйлады. Ә егет өзмәде дә куймады.

Әлбәттә, тирә-яктагылар да сизде эшнең нидә икәнен. Бер көнне җитәкчеләре Галия Гафуровна Зөлфияне аерып алып калды. Алдына кайнар чәй куйды, өстәлгә печеньелар таратты. Шуннан үзе дә Зөлфия янына килеп утырып, авыр сулады.

– Синең Шамил турындагы уйларыңны беләсем килгән иде, – дип, ерактан уратып башлады ул сүзне.

– Нәрсәсен беләсе, бер тел бистәсе инде шунда, – диде Зөлфия ваемсыз гына.

– Алай димә, Зөлфия, ул – ир кеше, ә без – хатын-кызлар. Раббыбыз безне бу дөньяга парлы-парлы яшәсеннәр өчен яраткан, – дип, иплән кенә һаман үзенекен каерды апасы.

– Мин кияүгә чыкмыйм, берүземә дә бик әйбәт әле. Әнә сез дә бар гомерегезне ялгыз яшәгәнсез, – дип өздереп әйтте кыз.

– Шуңа үкенәм мин, Зөлфиякәем. Миңа да тәкъдим ясады берәү, ә мин, исәр, кире каккан булдым. Яшьлек юләрлеге инде... Беләсеңме, хатын-кыз бәхете – гаиләдә. Әгәр сиңа Раббыбыз андый мөмкинлек бирә икән, ике куллап ябыш. Шамил начар егет түгел, синең өчен утка керергә әзер. Соңыннан рәхмәтләр укырсың әле...

Галия Гафуровнаның сүзләре кызыкайны уятып җибәргәндәй булды. Чынлап та, Шамил бик-бик якын бит аңа, ул турыда уйларга гына курка. Гарип, имеш, ул! Кешегә калган көне юк ич әле. Гарип кешеләрнең бәхетле булырга хаклары юкмы әллә? Шулай үз-үзе белән бәхәсләшеп, атна буе иләс-миләс йөрде дә «әйе» диде Шамилгә. Тегенең ничек шатланганын күрсәгез иде!

Бик күңелле туй үткәрделәр. Шамилнең әтиләре инвалидларга яраклаштырып эшләнгән машина бүләк итте яшьләргә, башка бүләкләр дә күп булды. Барысы да тиң-тигез тормыш, бәхет теләде. Бик матур яшәп китте алар Зөлфия фатирында. Чынлап та, хуҗалыкчан ир булып чыкты Шамиле. Коридорга бер дигән шкаф эшләп куйды, күгәненнән ычкынып барган ишекне яңартты, балконга тәрәзәләр куйды. Дөресрәге, икәүләп эшләделәр. Уйлавын Зөлфия уйлады, бар акыллы киңәшләр аннан булды, иренә кулыннан килгән кадәр ярдәм итте.

Башта алар бала булмас дип нык курыкканнар иде. Ходайның рәхмәте, нәкъ вакытында авырга калды Зөлфия. Тугыз айдан тупырдап торган кыз күтәреп кайтты. Дөресен әйтсәк, үзе күтәрмәде, әти-әниләре булышты, рәхмәт төшкерләре. Нинди генә булмасын, киленнәрен яраттылар алар.

Икесе бер кешегә тормаган ир белән хатынга бала караулары ничегрәк булганын күз алдына китерә аласызмы? Юешләнгән юрганын алыштыру да зур мәшәкать иде алар өчен. Юарга алынсалар, шабыр тиргә төшәләр: берсе тубыкланып баланы тота, икенчесе урындыкка басып су коя – галәмәт инде менә. Ничек итсәләр иттеләр, үстерделәр сабыйларын.

Халыкта сүз бар: кар башына кар җитә, кыз башына кыз җитә. Зөлфиянең иң якын ахирәте Сәрвиназ ешлады аларга. Борылган саен килде, ярдәм итәм дип ышандырды, җае килгән саен Шамилгә карап мәгънәле елмайды. Сукыр да булган икән Зөлфия! Сәрвиназ аннан күпкә яшьрәк иде, зәгыйфьлеге дә күзгә ташланып тормый, бары бераз аягын сөйрәп йөри, йөзе дә курчакныкы төсле. Килгән саен аңа машинада каядыр барырга кирәк булды: аптекадан дару аласы, табибка күренәсе, ерак ательедан күлмәген алып кайтасы. Шамилен үзе куалаплар җибәрде Зөлфия: бар, үзебезнең кешегә ярдәм ит, янәсе. Яшь әнинең хәлен белергә килүчеләр бу йөрүләрнең яхшыга түгеллеген аңлатырга тырышып карадылар. Зөлфия көлеп кул гына селтәде, Шамиле аны гына ярата, кызы өчен дә үләргә тора лабаса...

Ә менә атна элек Шамил кайдадыр йөреп кайтты да, шугалап йөреп, үз киемнәрен чемоданга тутырырга тотынды. «Мин үз эзләгәнемне таптым, Сәрвиназ белән кушылырга булдык», – дип аңлатты гаҗәпләнеп карап торган Зөлфиягә. Сүз дә әйтә алмый артыннан карап калды Зөлфия. Ул көнне ярсып-ярсып елап, икесенең утта януларын теләде. Икенче көнне, Шамил җирләр тырнап ялынса да, кире кертмәскә булып бетте. Ә ире өченче көнне дә кайтмады, суга төшкәндәй гаип булды. Менә шул чакта кара кайгыга калды инде Зөлфия. Ничек яшәргә тиеш соң инде ул, тәнендә күбәләк булып талпынган җанын саклап, җиде айлык баласын аралап. Ничек яшәргә?..

Йокымсырап киткән Зөлфияне ишек каккан тавыш уятып җибәрде. Кем дип тә уйларга белмәгән хатын, кабаланып, кофтасын иңенә япты, подшипникларны зырылдатып, ишеккә ашыкты. Йөрәге чыгардай булып типте. Ни булса да булыр дип келәне ычкындырды, анда... Шамил басып тора иде...

«Үә-ә-үә-ә» – дигән тавышка ныклап уянып китте ул. Тәслимәсе сөт сорап уянган икән. Сәгать алтыга якынлашкандыр инде. Сөт җылытып, баланы тынычландырып, әллә күпме вакыт үтте. Тагын урынына ятып утны сүндергәч, ул тагын бәхетле төшен исенә төшерде. Төш кенә икән... Менә бу иге-чиге булмаган Җир шарында яшәгән булалар кешеләр, һәрвакыт нидән дә булса канәгать түгел үзләре: өйләре бар килеш, зуррагы турында хыялланалар, миллион акчасы булганның икенчесен эзләп үтә гомере, томау төшсә дә – зык күтаралар. «Бәхетсез мин!» – дип зар елыйлар. Кызык була инде адәм баласы. Зөлфия, ике дә уйлап тормый, алар бәхеткә санаган әйберләрдән баш тартыр иде. Керфеге дә селкенмәс иде, валлаһи. Зәгыйфьлегенә дә разый булыр иде. Бары Шамиле янында булсын иде аның. Икәү бергәләп, кулга-кул тотынышып каршыласыннар иде язмыш авырлыкларын, бергә шатлансыннар, бергә сагышлансыннар иде. Кызларын дүрт саны төгәл, акыллы, тәүфыйклы бала итеп үстерсеннәр иде. Шул чакта бу җирдә Зөлфиядән дә бәхетлерәк бер кеше дә булмас. Менә хәзер уяу чакта ишекне каксыннар иде. Зөлфия ачып җибәргәндә анда киң елмаеп Шамиле басып торсын иде. Һәм аны киң күкрәгенә кысып әйтсен иде:

– Сез миңа кирәк! Кызым-алтыным кирәк... син кирәк миңа, Зөлфиям!..


PRESSA.RU

Мәтрүшкәләр

Мәтрүшкәләр,
кипкән мәтрүшкәләр,
Ераклардан әнкәм җибәргән.
Мәтрүшкәләр,
кипкән мәтрүшкәләр
Туган кырларымда тибрәлгән.

Тирән сагынудан уйчанланган
Күз карашым сезгә төбәлгән:
Әйтегезче миңа, мәтрүшкәләр,
Ни әйтергә әнкәм теләгән?

Мәтрүшкәләр мине уяттылар,
Сискәндереп гамьсез төннәрдә.
«Мәтрүшкәләр кебек кибәрсез сез,
Өзелсәгез туган җирләрдән...»



Эльмира ЗАКИРОВА

ӘЙТЕГЕЗЧЕ, МӘТРҮШКӘЛӘР

«Ераклардан әнкәм җибәргән», «Туган кырларымда тибрәлгән», «Тирән сагынудан уйчанланган»... Күңелнең әллә кай кылларына кагылып, сагышландыра, җирсетә торган юллар. Исегезгә төштеме? «Мәтрүшкәләр» җыры! «Фәридә-Алсу» дуэты ничек йөрәкләргә үткәзеп җырлый аны! Күз алдында һаман бер картина: урман аланы зәңгәр чәчәкләргә күмелгән, аларның хуш исеннән җанда әйтеп аңлаталмаслык рәхәт бер моң сыза. Үзеңне туган җирнең газиз бер баласы итеп тоясың...

Илдар абый Юзеев, әлбәттә инде, үзенең туган якларын – Яңавылның Ямадысын, әнисе – нечкә күңелле, мандолинада уйный, үзе җырлый торган укытучы Шәкүрә апаны, ул җыеп җибәргән мәтрүшкәләрне сагынып, әнә шундый шигырь юллары иҗат иткәндер. Ә ул шигырь ничек җырга әйләнгән икән?

Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевның улы, язучы һәм режиссер Салават Юзеев балачак хатирәсен искә төшерә:

– Миңа 10-12 яшьләр тирәсе булгандыр. Бүгенгедәй күз алдымда: Волгоградская урамындагы фатирыбызга берзаман Аяз Гыйләҗев белән аның бертуган энесе Алмаз килеп керделәр. Кулларын-

да – гармун. Ниндидер зур шатлыклары бар кебек. Аяз абыйлар бездән ерак тормыйлар, аларның өе Восстание урамында иде. Берәр бәйрәм булса, әти белән әни аларга бара, йә Аяз абый белән Нәкыя апа үзләре безгә килә. Бу юлы Алмаз абый белән килгәннәр менә. Керә-керешкә, Аяз абый әтигә дәште: «Илдар, синең «Мәтрүшкәләр» шигыреңә минем энекәш көй язган! Әйдә, тыңлап кара әле!» – ди. Алмаз абый үзе уйнап, үзе җырлый. Әти, башын кыңгыр салып, уйчанланып, бөтен барлыгы белән җыр тыңлый. Күренеп тора – ул бик канәгать. Мин әле ул җырның яхшымы-түгелме икәнен дә аңларлык яшьтә түгел идем бугай. Еллар узгач кына, «Мәтрүшкәләр»нең никадәр тирән мәгънәгә ия булганын аңладым...

Салават Юзеев әнә шулай оеткы салып җибәрде истәлекләргә. Сорау арты сорау туа башлады. Җыр турында тагын кемнәр ниләр сөйләр? Шагыйрь үзе дә, көйнең авторы да арабызда юк инде. Аяз абый да юк... Чү! Аяз Гыйләҗевның хатыны Нәкыя апа булыша ала бит миңа.

– Аязлар бик музыкаль гаиләдә үсә. Әтисе Мирсәет, әнисе Мөгаттәрә – укытучылар. Кайнанамның шигъри җанлы булуын Югары Багражлар гына түгел, бөтен Сарман, Зәй ягындагылар яхшы хәтерли. Ә мин аның җырлавын, мандолинада уйнавын да беләм. Уллары Азат, Аяз, Алмаз да җырлыйлар, баянда уйныйлар иде. Бервакыт Аязның туган көненә Илдар, Шәүкәт, Альберт (Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Альберт Яхин – *Э. З.*) хромка күтәреп килделәр. Әле дә исән ул... Төпчекләре Алмаз и җырлап та куя иде инде! Ул медицина институтында укыган елларында ук көйләр яза башлады. «Музыкаль белемең дә булса, Сәйдәшевләр кебек композитор чыгар иде синнән, Алмаз!» – дип гел әйтә идем. Хатыны Энҗе дә шулай ди. Алмаз Бигеш больницасында табиб булып эшләде, хатыны Энҗе мәктәптә рус теле һәм әдәбиятыннан укытты. Алар шулкадәр пар килгәннәр иде, яратышып, бик матур яшәделәр! Энҗене яратудан көй чыга, дия иде Алмаз. Ул баянда да, мандолинада да, гитарада да уйный... «Мәтрүшкәләр» яңгырый башласа, гел Энҗегә шалтыратам: «Радионы куй тизрәк! Алмаз җырын җырлыйлар!» – дим. Килендәшем белән икәүләп тыңлыйбыз, икәүләп елыйбыз... – дип сөйли Нәкыя апа.

Аның истәлекләреннән җырга тагын бер ачкыч табыла. Энҗе апа! Менә кем ул җырны йөрәк түрендә йөртәдер! Нәкыя ападан килендәшенең телефон номерын сорап алып, Бигешкә шалтыратам.

...Алабуга пединститутында укып йөргән еллары, авылларына эшкә килгән табиб егет Алмаз, аның белән танышулары, өйләнешүләре, үскәч, әтиләре юлын сайлаячак акыллы кызлары Әлфия белән Резеда, мәктәпкә килгән язучы халкын ничек өйләрендә кунак итүләре турында матур истәлекләр сөйли-сөйли, Энҗе ханым җай гына «Мәтрүшкәләр»гә күчә.

– Алмаз чып-чын табигать баласы иде! Эштән кайта да: «Энҗе, әйдә урманнан әйләнеп кайтабыз!», «Җыен, Зәй буена төшәбез!», «Болын тулы чәчәк – киттек!» – дип, мине ашыктыра башлый. Үзем дә сәяхәтләргә маһир кеше – ялт кына җыенып чыгып утырам. «Син дә нәкъ минем кебек. Каян шулкадәр туры килгәнбез!» – дип куана Алмазым. Аның күңелендә яңа җыр туа. Җиләккә дә, гөмбәгә дә, чикләвеккә дә барабыз. Салкын тигәндә шифасы бар дип, сары, зәңгәр, шәмәхә мәтрүшкәләр җыябыз. Алмаз, әнә, 99 чиргә дәва дип сөйли мәтрүшкәне. Ул белмәгән чәчәк, үлән юктыр! Мәтрүшкә, дигәннән, кайсыбызның гына әнисе балачакта безне мәтрүшкәле чәйләр белән дәваламаган да, үсеп җитеп, укырга киткәч, күчтәнәчләр янына мәтрүшкәләрен дә салып җибәрмәгән. Минем әни дә, Алмазның әнисе дә... Илдар Юзеев шул турыда шигырь дә язган. Шагыйрь күңелендәгене Алмаз үзенеке кебек кабул итеп, ул шигырьне көйгә салды. «Мәтрүшкәләр»нең тәэсир көче бермә-бер артты. Җырны иң беренче булып Миңгол Галиев башкарды. Ул бик тиз популярлашып китте. Сәхнәдә дә, табын янында да, дуслар очрашкач та җырлыйлар шуны.

Бер көнне Алмаз белән Илдарның телефоннан сөйләшүе колакка керә. «Парин, җырны Дәминов бик сорый бит», – ди Юзеев. Алмаз каршы төшә: «Юк инде, аның тавышына туры килми ул. Миңгол матур җырлый», – ди.

Мәтрүшкәләр, дигәннән, Алмаз бакчабызда да үстерде аларны. Тау ягы урманыннан махсус казып алып кайткан иде. Күршеләргә дә тараттык. Ул мәтрүшкәләр күзне иркәләп, зәңгәр моң булып сагындырып, тирә-якка хуш ис аңкытып әле дә булса бакча түребездә утыралар.



Алмаз Гыйләҗев *(баян белән)* һәм хатыны Энҗе *(алда)* дуслары белән Бигеш урманында. 1972 ел.

PRESSA.RU



Фото: Ксения Богданова

«ӨЙДӘГЕ ЭШ – ЭШМЕНИ?!»



Лилия ГӘРӘЕВА

КҮПЛӘРЕБЕЗНЕҢ ИРЛӘР АВЫЗЫННАН ШУШЫ СҮЗЛӘРНЕ (ШУШЫ УК БУЛМАСА ДА, МӘГЪНӘСЕ ОХШАШ) ИШЕТКӘНЕ БАРДЫР.

Ашарга пешерү дә эш түгел – учак ягып, утын салып торасы юк бит, кер юу да – машинаның төймәсенә генә басасы. Балаларны карау – күңел ачу гына, тик уйнап утыр шунда үзләре белән.

Әмма... Көннәрдән бер көнне бу «рәхәтлекләр» ирнең берүзенә генә өелеп калса?.. Тормыш бит, хатын-кызның каядыр командировкага чыгып китәсе булырга мөмкин, укырга керсә, сессияләргә йөрисе, кунакка барасы...

Әйдәгез, шулай күзаллыйк әле: сезгә атна-ун көнгә каядыр барырга кирәк, өйне һәм балаларны ирдән башка калдырыр кеше юк. Тормышны ирегезгә ышанып калдырыр идегезме? Өйдән тыныч күңел белән чыгып китә аласызмы? Сез һәр көнне башкарган эшләрне ирегез үзе белеп эшли алачакмы? Ашарга пешерү, савыт-саба юу, балаларның берсен – мәктәпкә, икенчесен балалар бакчасына озату, каршы алу, дәресләрен әзерләшү, юындыру, тырнакларын кисү, сыер саву, катык оету, камыр кую, урын-җирне алыштыру, гөлләрне күчереп утырту, кыяр-помидор тозлау, варенье кайнату... Озын исемлек бу – очсыз-кырыйсыз!

Йә, ирегезгә өйне ышанып чыгып китә аласызмыюкмы?

Шушы сорау белән җырчыларга, артистларга (өйне күбрәк калдырып йөрүчеләр шулар инде) һәм «ВКонтакте» челтәре аша «Сөембикә» журналы укучыларына мөрәҗәгать иткән идек. Кызыклы гына җаваплар алдык.



Ләйсән Мәхмүтова, Татарстанның атказаган артисты:

Безнекеләр минсез дә тормышны бик әйбәт алып бара. Балаларга әтиләре белән генә калу хәтта ошый да (ачуланучылар азрак була бит). Әтиләре дә, син югында бөтен кушканны тыңлый болар, син кайткач кына тыңламый башлыйлар ди. Керләрен дә үзләре юып куя. Кул белән (машинаның рәтен тапмыйлар, ахрысы)! Ашарларына да пешерәләр. Улыбыз Йосыф мин өйдә булганда да көн саен нәрсәдер уйлап чыгара, йә токмач кыздыра, йә коймак, йә тәбә. Кайвакыт ачуланып та куям, ризык әрәм итеп йөрисең шунда дип. Югыйсә молодец бит инде, юкка ачуланам!

Кайтышка шулай да берәр төрле «сюрприз» булмый калмый. Балалар кечкенә чакта андый «сюрприз»лар гел була торган иде. Стеналарны да буяп куярга мөмкиннәр, табак-савытлар да күп кырылды. Алай да мин гастрольләрдән кайтышка үзләренчә өйләрне җыештырып, тәмле әйбер пешереп куялар. Шулай булгач, рәхәтләнеп чыгып китә алам гастрольләргә.



Алсу Фазлыева, җырчы:

Мин каядыр китсәм, ирем Азат та, улларым да ач булмаячак, анысы өчен җаным тыныч. Азат әле миңа караганда да тәмлерәк һәм яхшырак итеп пешереп ашатачак балаларны. Аларга төрле тәм-томнар алачак. Әмма өйдәге тәртип мин киткән көнне үк бетәчәк. Әле мин өйдә булып, ирем кухняда берәр нәрсә пешерсә, артыннан җыештырып бетерерлек булмый. Җыештыру дигән нәрсә никтер кулларыннан килми. Алай да гел шалтыратып, аларны контрольдә тотмый булдыра алмыйм. «Тордыгызмы, ашадыгызмы, киендегезме, нәрсә кидегез?..»

Әле менә яңарак кына шушы темага клип та төшердек. Алла боерса, бик тиздән тамашачыга тәкъдим итәрбез. Күп гаиләләр үзләрен таныр анда.

Ә инде өйдә көткән «сюрприз»ларга килгәндә, шиңгән гөлләр, туп-тулы чүп чиләге, раковинага өелгән савыт-саба... Мин аларына көенмим дә, нишлисең, ир-атның чисталыкка исе китми инде аның. Исән-сау торгач, калганы белән килешәсең.



Эльмира Исрафилова, журналист:

Иремне өйдә ялгызын калдырып китәргә курыкмыйм. Үз-үзен карарлык хәлдә, ашарга да пешерә белә. Пешермәсә, берәр җиргә барып ашый. Өйне бераз «батырып» инде, анысын гына җыештырып булыр, куркыныч түгел. Менә баланы ышанып калдырырга батырчылык итә алырмын микән? Бер дә башка чарам булмаса гына инде... Карый алмый дип әйтмим, карар. Ашатыр да, уйнатыр да... Юындырмас, йоклатмас та димим, аларын да булдырачак. Әмма боларның берсен дә минем кебек җиренә җиткереп эшли алмас шикелле. Улым үзебезнең татар ашларын ярата, ирем аларны пешерә белми. Юындырганда колакларын юарга оныта. Андый җитешсезлекләр күп инде... Инструкция язып мәшәкатьләнмәм, иремнең аны укып чыгуы бик икеле. Берәр нәрсә кирәк булса, телефон бар бит. Ә шулай да бала белән ялгыз калса, ирем үзе өчен бик күп ачышлар ясар иде. Атнага җиде көн, тәүлек буе бала белән булуның никадәр күңелле дә, мәшәкатьле дә икәнен һәм никадәр ардырганлыгын да белер иде ул.



Мәрьям Миңнеголова (Азнакай районы, Мәндәй авылы):

Хәзер инде, Алла боерса, бергә яши башлаганыбызга көзгә 25 ел була, мин рәхәтләнеп ышанып әйтәм: тормыш иптәшемне өйдә берүзен тыныч күңел белән калдыра алам. Ни дисәң дә, беренчедән, ачка интекмәячәк, аш пешереп ашый белә, бәрәңгене генә кыздыра ала. Камыр ашларын пешерерме – белмим инде, шулай да мин хастаханәдә яткан вакытта балалар белән бәлеш пешереп ашаганнар иде. Балаларны бәләкәй чакларында бик яхшы карады, сүз әйтерлек түгел. Ничә еллар әни (иремнең әнисе) урын өстендә ятты. Андый авыру кешене тәрбияләү яшь баланы караганнан да авыррак: күтәреп мунчага алып барды, мин юындырып бирә идем, ә ул тырнакларын кисеп, чәчләрен дә тарады.

Урын-җирләрне җәеп, җыештырып куя белә (мин өйдә булмаган чакта инде монысы). Бакча эшләренең күбрәген ул эшли, күчереп утыртуны бергә башкарабыз. Эшне җиренә җиткерә торган кеше ул, ашык-пошыкны яратмый, иплэп кенә, әкрен генә үзе эшләсә эшли, кеше яллаган юк. Балаларны мәктәпкә болай да ул озата иде, минем эшем белән алар мәктәпкә киткәнче кайтып җитеп булмый иде.

PRESSA.RU



Миләүшә Мусина (Чаллы):

Тынычлап, ышанып чыгып китә алам. Кызыма 5,5 ай вакытта аппендицит белән 10 көн хастаханәдә яттым. Ирем баланы имезергә дә алып килде, яхшылап карады да. Мин савыгып чыкканчы, бәләкәчне токмач ашы ашарга да өйрәтеп куйган иде. Хәзер кызым да зур (11 яшь), ашарга пешерә белә. Савыт юv. өй җыештыруны әйтеп тә тормыйм...



Алсу Хәбибуллина (Казан):

Икенче бала белән йөклелек шактый кыен узды. Баштан ук берничә тапкыр саклануда ятарга, ә йөклелекнең соңгы ике аен бала табу йортында үткәрергә туры килде. Ә өйдә 2,5 яшьлек бала! Аны карарга, ашатырга, уйнатырга, урамга алып чыгарга кирәк. Берәү булса, баланы әби-бабай янына илтер иде. Иремә мең рәхмәт! Балада стресс булмасын, әнисе өйдә юклыкны сизмәсен дип бик тырышты. Эшеннән ял алды. Паркларда йөрделәр, циркка бардылар, өйне дә тәртиптә тотты, тамак ягын да кайгыртты. Күңелем тыныч иде, Аллага шөкер.

Болары хатын-кызларыбыз фикере булды. Бу җәһәттән ир-егетләребез үзләре ничек уйлый икән соң? Өйдәге бөтен эш, балалар мәшәкате аларга өелеп каласы бит. Курыкмыйлармы? Нинди эшләрне эшли алырлар, кайсыларына «тешләре үтмәс»? Әллә соң хатыннары инструкция язып калдырамы?



Алмаз Миргаязов, «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең радиолар белән эшләү юнәлеше җитәкчесе:

Хатыным Флүзәнең бик озаклап өйдән китеп торган чагын хәтерләмим дә үзе... Аның төп вазыйфалары, нормаль татар хатын-кызыныкы кебек үк, өйне карау, кибеткә йөрү, каралтыны тәртиптә тоту, ә иң мөһиме – балаларны тәрбияләү, мәктәп-бакчаларга йөртү, алып кайту, ашату, киендерү һәм башкалар. Тик теоретик рәвештә фикер йөртергә була... Ул озакка берәр кая китсә, бик күп проблемалар килеп туачак. Беренчедән, балаларның нинди режим белән, нинди ризык ашаганын белмим. Һәрхәлдә, үзем генә калган вакытларда, мин тәкъдим иткән ризыклардан алар, гадәттә, борын чөерәләр һәм «яшерен шкаф»тагы баллы тәм-томнарга бармак белән төртеп күрсәтә башлыйлар. Нәтиҗәдә, диван, караваt, кәнәфи, идән конфет, печенье, чокопай-барни калдыклары белән тула. Флүзә кайткач, бөтенебезгә дә эләгә... Икенчедән, аларның нинди очракка нинди кием-салым кияргә тиешлеген күз алдыма да китерә алмыйм, анда ниндидер катлаулы формулалар бар бугай: кием төсен калынлыгына тапкырлап, урамдагы һава температурасына бүләргә, тагын нәрсәләрдер эшләргә кирәк... Башлык белән бияләй – аерым тема. 16 еллык әти стажы дәвамында әле бер тапкыр да балага дөрес башлык йә бияләй кидергәнем юк, гел ялгышам! Өченчедән, штаттан тыш чаралар, түгәрәкләр, спорт мәктәпләре расписаниесен язып калдырырга була, билгеле. Тик ул расписание буенча йөргәндә тагын 1 нче һәм 2 нче пунктлар белән авырлыклар килеп чыгачак... Чөнки фигуралы шуу мәктәбе өчен генә дә берничә кием формасы бар икән. Хәлбуки, аларны да бер сумкага төяп барып, ситуация буенча киендерергә була.

Хатыннан башка да эшли ала торган эшләр түбәндәгеләр. Беренчесе: кәефкә карап, йомырка тәбәсеннән алып бәлешкә кадәр пешереп ашау, балаларга кукуруз шарчыклары-йолдызчыкларын сөт белән болгатып, йә булмаса, ботка пешереп ашату. Икенчесе: балаларны мунчада йә душта юындыру. Өченчесе: идән юу, кер үтүкләү, бакчада маташу – чүп утау, су сибү.

Хатынны көтәчәк эшләр дә бар: бакчада әйбер утырту, балаларны «юньле әйбер» ашарга мәҗбүр итү, тырнакларын кисү, кызыбызның чәчен үрү, кер юу машинасының кнопкалары белән идарә итү.



Зөлфәт Зиннуров, шоумен:

Озакка булмаса да, калгалаганым бар. Инструкциясез булмый. Ничек инде хатынның кыйммәтле күрсәтмәләреннән башка булсын! Язып та калдыра, әйтеп тә. Хәзер җайлы инде, һәрберебездә телефон, ватсап. Берәр җиргә җыена башлап, баланы киендерәсе булса, сайлаган киемнәрне фотога төшерәм дә, шушыларны-шушыларны кидерсәм ярыймы, дип сорыйм. Шулай киенеп чыгып китәбез. Кызымның чәчләрен әнисе кебек матур үрә белмәсәм дә, резинка белән җыеп куя беләм. Гөлләрне дә онытмыйм, гел сулар сибеп кенә торам, бигрәк тә хатын кайтыр алдыннан мул итеп сибеп куям, тилмерткәнсең сусыз, димәсен. Ә болай, дөресен генә әйткәндә, командировкаларга ешрак минем үземә китәргә туры килә. Озаккарак китсәм, ике бала белән үзенә генә авыр булыр дип, хатынымны әниләренә кунакка илтеп куям. Аңа да җайлы, миңа да тыныч.

Менә әле дә бәләкәе белән өйдә ялгызым гына идем. Хатынның барып кайтасы җире булды. Уянмаса гына ярар иде дип, куркып утырам инде.



Марсель Мәхмүтов, артист:

Хатыным – яшьләр театры артисты, гастрольләргә еш китәргә туры килә аңа. Әле менә яңарак кына 10 көн йөреп кайттылар. Китәр алдыннан 5-6 көнлек итеп ашарга әзерләп калдыра. Кызым белән шуны ашап торабыз да, ул беткәч, хәләл кафега йөрибез. Чөнки йомырка тәбәсеннән кала бер генә ризык та пешерә белмим. Ашарга пешерү минем өчен дөньядагы иң авыр эш. Бирелмәгән ул миңа. Безнең әти дә шундый кеше иде. Аның беркайчан да безгә ашарга пешергәне булмады, дисәм, бер тапкыр булган икән. Йомырка тәбәсе иде ул. Ә менә башка өй эшләрен бик яратып башкарам. Мәсәлән, савыт-саба юу – минем өчен үзенә күрә бер медитация. Хәтта хатыным өйдә булганда да үзем сорап алып юам мин аны. Кер үтүкләргә дә яратам, үземә тынычлык табам ул эштән.



ГАЗТДИНОВА Алсу

Казан (Идел буе) федераль университеты

Кияүдә түгел

Магистрант

Тормыш шигаре: «Тормышта теләсә нинди үзгәреш бары алга, яхшыга илтә»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Салаватсыз август булмый

Бу елым истәлекле вакыйгаларга, иҗат кешеләре белән очрашуларга бай булды. Август аенда да күңел белән көткән шундый вакыйга бар – Салават Фәтхетдинов концертына җыенабыз. Гаиләбез белән Салават абыйның август концертларына йөрүебезгә инде 20 елдан артык, үзенә күрә традиция! Мәгънәле, моңлы җырлар, яңа җырлар ишетер өчен барам. Бу концертлар гади концерт кына түгел, татар өчен милли бәйрәмгә әйләнә. Өлкән остазларын хөрмәтле белгәне өчен Салават абыйга ихтирамым аеруча зур.

Бургерлар да хәләл иттән

Үзебезнең эшмәкәрләрнең хәләл ризыкны күбрәк җитештерә башлавына шатланам. Казанда яшьләр ярата торган бургерларны хәләл иттән пешерүче сәүдә нокталары күбәйде. Мәсәлән, Кызыл Позиция, Габдулла Тукай урамнарында урнашкан кайбер гриль-барлар бургерларга «Сөембикә манарасы», «Чәкчәк» дигән исемнәр дә биргәннәр. Тирә-юньдәге офисларда эшләүчеләр дә төшке ашка бирегә йөриләр. Хәләл азык-төлек белән кызыксынучылар артуына куанам.


Ихласлыкка еллар киртә түгел

Принцесса Диана турында төшерелгән «Диана, наша мать: Её жизнь и её наследие» исемле яңа документаль фильм дөнья күрде. Кайчандыр ул: «Бөекбритания патшабикәсе булудан бигрәк, кешеләрнең йөрәкләрендә патшабикә булыр идем», – дигән булган. Андый дәрәҗә мирас буларак бирелми, аны казанып кына була. Хәйриячелек белән шөгыльләнү Дианага шушы дәрәҗәгә ирешергә ярдәм иткән. Каршылыклы шәхес дип саналса да, Диана үз илендә генә түгел, бөтен дөньяда «Йөрәкләр патшабикәсе» булып күңелләрдә калган. Кешеләрнең ихлас мәхәббәтен яулау – сирәк затларга тия торган бәхеттер.

сөендерде









көендерде

сөендерде









көендерде

сөендерде







көендерде

Җавапсыз мәхәббәт

Иҗади планнарым шактый, башкарып чыгарга көч җитәрме дип шикләнәм. Өйдәге песиебез соңгы арада миңа әйләнеп тә карамый, гел урамга ашкына. Нәрсә булган дисәм, бу беркатлы җанның урамдагы кошларга күзе төшкән икән! Тегеләр дә тиле гашыйкны үртәп, урыннан-урынга күчеп, сайрый-сайрый башын әйләндерәләр. Мескен песи кайсы якка карарга белми, көннәрен бакчада үткәрә, мин: «И-и-и, юләр, кошлар җәй көне генә сайрый, көз җитүгә үзеңне ташлап китәчәк. Барыбер бездән якынрак кешең юк!..» – дип акыл сатам. Ә песи, борылмыйча гына, ачу белән йонлач койрыгын болгый.

Шартнамәле шартларда

Бер карасаң, тормыштан зарланырга урын юк кебек. Ләкин шатланыр сәбәп тә күренми: татар мәктәбен ябу шаукымы инде университетка кадәр килеп җитте – нинди бай тарихлы татар филологиясе бүлегенә ясин чыктылар! Бу сынауларны узу мәҗбүри идеме? Республикабыз белән Россия арасындагы Шартнамәнең озайтылмавы, бу мәсьәләдә халыкның битарафлыгы һәм бигрәк тә яшьләрнең бу Шартнамә хакында белмәүләре көендерә. Шартнамәнең асылын белмичә, әһәмиятен аңламыйча, авыз күтәреп, интернетта теләсә нәрсә язып утырырга гына булдыралар. Шул гамәлләре белән дә начарлык эшләүләрен – үзләре утырган ботакны үзләре кисүләрен аңламыйлар.

Җанга тигән чир яман

Дөньяда сугышлар, дәвага бирешми торган сырхаулар, табигать афәтләре ешаеп китте. Аларга өстәлеп җәмгыятьнең үз авырулары да пәйда булды. Мәсәлән, җәмгыятьтә «бөеклек» чире азганнан-аза бара (аның «минминлек» дигән төре дә бар). Нәтиҗәсе күз алдында: бар да өстен булырга, хакимлек итәргә тели, ләкин үзләре үсеп түгел – бүтәннәрне түбәнсетү хисабына. ...Кешелек тарихында бер чирнең дә яхшылыкка илткәне юк әле.

PRESSA.RU



УРТА АЗИЯ



Гөлүсә ЗАКИРОВА

ТАҖИКСТАНДА ДИҢГЕЗ ЮК. ЕЛ БУЕ ЗАРЫГЫП КӨТКӘН ЯЛЫҢНЫ ДИҢГЕЗ ЯРЫНДА УЗДЫРАСЫ КИЛӘ БИТ ИНДЕ...

Әмма хәрбигә кияүгә чыгып, офицер ире белән башта Новосибирскига, аннан Таҗикстанга киткән Әдилә дустым кунакка чакыргач, ике дә уйламый, кызым белән икебезгә Дүшәмбегә чаклы самолет билетлары юнәттем.

Илбашы «озатып йөрде»

Таҗикларның үз милләтләрен олылаулары таң калдыра. Бу нәрсә очкыч аэропортка төшкәндә үк сизелә. Сине Гиннесслар китабына кергән дөньядагы иң зур флагшток каршы ала. 165 метр биеклектәге бу таҗик дәүләт әләме 2014 елга кадәр дөньядагы иң биек флагштоклардан санала. Очкыч хәзер менә канатлары белән шул әләмгә кагылып китә бит инде дип, иллюминаторга баккан арада, җиргә төшеп кунганыңны сизми дә каласың. Элеккеге союздаш мәмләкәтнең таможнясыннан зарланучылар күп булса да, читенлек тоймадым. Хатын-кызларны чиратсыз да уздыралар әле. Миграция кануннарын да ипләп аңлаталар: өч көн дәвамында теркәлү узмасаң, 20-22 мең сум штраф чәпәячәкләр, ди. Алга узып булса да әйтим, кире кайтканда биштәрләрнең нормадан артканын күреп, бер бүлмәгә үтәргә тәкъдим иттеләр. Алар шыпырт кына сораган суммага таможня аша «яшел коридор» да тәкъдим ителә иде...

Ярый, хуш, батты кояш... Дүшәмбедә безне Таҗикстан Президенты Эмомали Рахмон «каршы алды», һәм кая гына барсак та, «озатып йөрде»... Әкият сата, дисезме? Аэропорттан чыгуга ук биш катлы йорт диварына элеп куелган мөхтәрәм президентның фотосын күр дә, һәр тыкрык саен милләт атасы сурәтенә бак та – аннан аңларсыз кунаклар хәлен...

Дүшәмбе урамнарында офисларга ашыккан милли киемле ханымнарны аз күрмәдем. Ачык төстәге күлмәкләргә ялтыравык җепләр белән чигелгән булыр, камзуллары да бизәкле, чәчәкле-чуклы. Чәч өстеннән, чегәннәр кебек, күлмәк төсендәге шарф бәйләгәннәр. Колакларында асылмалы бижутерия ялт-йолт килә, аякларында арты ачык, башы ябык бизәкле чүәкләр. Тагын бер нәрсәгә игътибар иттем: башкалада сәүдә йортларында да, паркларда да, базарда да бик актуаль ике һөнәр ияләре эшли: чәчтараш һәм каш ясаучылар. Ир-атлар чәч алдыра, сакал-мыек төзәтә, хатын-кызлар каш ясата, йолкыта, буята – әлеге һөнәр ияләренә бу илдә мәңге кытлык булмаячак. Таҗик хатыннары, безнең чәчләргә карап, кызганып, ай-вай килделәр инде. Үзләрендә, кыз балаларны бала чакта өч тапкыр пеләш итеп кыралар икән дә шуның белән шул – чәч кистерү рөхсәт ителми. Кияүгә чыккач, ире рөхсәт итсә генә... Һай, ничек тәрбияли алар чәчләрен, бер көнне кара әнис мае сөртәләр, икенче көнне җитен мае, өченче көнне тагын әллә ниләр... Алар даруханәләрдә дә сатыла, базарда да...

Тәңре тауның йөзек кашы

Таҗикстандагы Искәндәр күл – дөньядагы иң матур урыннардан санала. Дүшәмбе шәһәреннән ул 200 чакрымда. Кар түбәле Фан тауларында – Зарафшан белән Гиссар сыртлары кисешкән урында. Бу юлның газабы шунда: таулардан сил һәм кар ташкыннары гел төшеп тора. Аларны чистартырга кирәк. Быел язын кырыклап машина, әнә шуларга юлыгып һәлак булган. Бормалы



тау юлларыннан әле күтәрелгәндә, әле төшкәндә колаклар тона. Аннан караңгылыкка чумасың – алда берничә чакрымга сузылган тоннель. Төн уртасында куе томанга эләккән кебек. Бераз баргач, сүрән яктылыкка күз ияләшә төшә, машинага тузан тула. Анзоб тоннелен узып, күпмедер баргач, биш чакрымга сузылган Шаһристон тоннеленә керәсең. Машина йөртүчеләр аны үзара «негр арты» дип тә йөртә. Биш чакрым буена өннәрең алынып барсын да... Менә шундый ул Фан таулары!

Олы кеше хөрмәттә монда. Аның сүзен һәркем, хәтта гаярь бизнесмен ир-атлар да карусыз үти.


Искәндәр күл Александр Македонский хөрмәтенә шул исемне йөртә икән. Риваятьләр әллә никадәр. Имештер, ул Һинд походы вакытында үзенә бирелергә теләмәгән Согдиана каласына тап була. Бөек гаскәр башлыгы, елга агымын үзгәртеп, ирек яраткан тау халкын суга батырырга фәрман бирә. Ә шул урында күл барлыкка килә... Яки менә монысы: Македонскийның Буцефал дигән яраткан аты күлдән салкын су эчеп авырый. Авыртудан гасабиланган хайван тау кыясыннан аска томырыла... Гаскәр юлын дәвам итә. Хәзер төн урталарында күл өстендә кара атның шәүләсен күрүчеләр дә бар ди...

Күлнең мәйданы – 3,5 квадрат чакрым, ә тирәнлеге 72 метр. Үзен тау кыялары әйләндереп алган. Иң биеге – Кырык Шайтан тавы. Кыяларының кызгылт, көрән төсләре күлнең фирүзә төсе белән кушылып, сихри матурлык хасил итә. Суы салкын. Җирле кешеләрнең: «Бездә салмыш урыс туристлары гына коена», – дигәннәренә үртәлүгә карамастан, чумып алырга да исәп бар иде, су якын китермәде: аякны көзән җыера. Кисәк кенә су төбенә

PRESSA.RU



Искәндәр күлнең матурлыгын әйтеп тә, тасвирлап та булмый. Аны Фан тауларының горурлыгы, диләр. Диңгез өстеннән 2068 метр биеклектәге бу тауны Тәңре тауның йөзек кашы дип тә йөртәләр.





киткән балыкчылар һәм кыю туристлар хәлен чамаларга мөмкин.

Без базадагы Советлар Союзы вакытыннан калган йортны арендага алдык. Моңа аптырыйсы түгел. Таҗикларның аны төзекләндерергә әллә хәлләреннән килми, әллә теләкләре юк. «Әле менә электр чыбыкларын алмаштырырга никадәр сомон тоттык, акча юк», – дип сөйләнеп торды турбаза директоры Хәсән әфәнде. Базада тыныч. Җылы сулы душ бүлмәсенә дә разый булдык. Ашарга пешерү өчен кухня дигән корылма бар. Арендага казан, мангалише җайланмаларны алып торып була. Астына утыннар салып, учакта пешерәсең. Бәхтияр белән аның хатыны Зәмирә пылау, шурпа, шашлыкларны җиренә җиткереп әзерләп бирделәр. Үзебез белән дасторхан алган идек. Эскәтерне җиргә җәеп утырдык та рәхәтләнеп сыйландык.

Борылышларда юл читендәге үк упкын-дәрьяларга күз ташласаң, йөрәк үкчәгә төшкәндәй була.

Хәсән өч чакрымнар ераклыкта гына шарлавык барлыгы турында сөйләде. Киттек. Искәндәр-дәрья буйлап тау сукмагыннан атлыйсы. Дәрья суы да фирүзә төстә, шаулы. Салкынлыгы сулышка бәрә. Инде шәфәкъ кызыллыгына әйләнә барган кояш җылысында барыбер рәхәт. Юлыбызда тау сырганаклары, барбарис, кыргый чия, гөлҗимеш куаклары очрап торды. Кыр күркәләре дә йөри икән. Дәрья шавы колакны ярып ишетелә башлагач, тиешле урынга килеп җитүебезне төшендек. 50 метр биеклектән ургылган шарлавыкны Фан Ниагарасы дип тә йөртәләр. Шарлавык өстендә гап-гади арматурадан әвәләп, зур ташларга бәйләп куелган күзәтү мәйданчыгына килеп чыгасың. Анда кереп басу да зур сынау аша үтүгә тиң. Килгәч, керми китеп булмый бит. Гаҗәеп кичерешләр биләп ала.

Иртән Елан күленә кузгалдык. Анысына исемне туристлар кушкан, күлдә еланнар күргәннәр дә, шулай атаганнар, имеш. Серим елгасы тарлавыгында урнашкан ул. Безнең күзгә күлдәге ботаклар да, яфраклар да елан булып күренде инде. Ә күлдән өстәрәк, текә кыялы елга тарлавыгында тагын бер шарлавык, тагын җиде күл... Анда баруы мең бәла, тик бу кадәр матурлыкны күрер өчен аркасына биштәр аскан туристлар дөньяның төрле кыйтгаларыннан да килә бит әле. Кыюраклары тагын бер хикмәтле урынга да барырга тәвәккәлли. Тау мәгарәсендә әллә ничә йөз ел дәвамында куллары догага кушырылган бер суфи утыра, ди. Бәлки һавасы шундыйдыр – бу суфи үлеп тә шул халәтендә саклана алырлыктыр. Анда бик сирәкләр генә якын килә ала дип сөйләделәр. Якын килгәннәр упкынга егыла, имеш...

Балчык үзән

Гиссар үзәнлеге – Фан тауларының нәкъ кересе: биредә биек таулар, калкулык һәм ермаклар балчыктан әвәләнгән диярсең. Шул үзәнлектә Гиссар кирмәне дә үзле балчыктан ясалган сарай кебек күренә. Ул 2500 ел элек төзелгән. Таҗикстанның кул белән кагылырлык башка тарихи һәйкәлләре юк та шикелле. Төп капкасы XVI йөздә үк корылган. Ә аның янәшәсендә 700 еллык ике «манара» – чинар утыра: әйтерсең лә, ике тау сыртыннан ике гасырның ишекләре ачылган... Туристлар юк диярлек. Әгәр сирәк-мирәк кенә күренгән машиналарны туктатсаң, XIX гасырда дип тә алданырга мөмкин. 20 сомон биргәч, рус телендә экскурсия үткәрүче дә табылды. Шунысын да әйтеп узыйм әле: Гиссарда таҗиклар үзенчәлеклерәк. Кирмәнне карап чыгу өчен үз халкыннан ике сомон, синнән биш сомон ала. Әгәр таҗикча бер сүз кыстырсаң, өч сомонны кире кайтара. Атта йөрергә дип биш сомонга утырта, 20 сомонга төшерә...



Элгәре туйга 500 ләп кеше чакырсалар, хәзерге законнар буенча, 150 дән күп булырга тиеш түгел.

Гиссар мавзолеендагы суфи Хуҗа Мөхәммәд Хайвоки каберен зиярәт кылырга дөньяның ерак-ерак төбәкләреннән, хаҗ кылырга килгән сыман агылалар икән.



Экскурсия үткәрүче егет безне тарихи кибет бинасына да алып керде: менә бу чалмага – йөз, бу чигүле көрпәчәгә 70 ел, ди. Ә нигә сатасыз соң мондый тарихи экспонатларны, дибез. Җавап бер: «Акча юк. Музейны төзекләндерергә акча кирәк...»

Тарихи музей иске мәдрәсә бинасына урнашкан. Шунда ук яңа мәдрәсә, Таш мәчет, Кәрван-сарай, «Сангин» мәчете, Мәхдүм Әгъзам мавзолее урнашкан. Мәхдүм Әгъзам – исем түгел, «бөек әфәнде» дигәнне аңлата (шул исемдәге бер мавзолей Сәмәркand шәһәрендә дә бар, анда «Дахбедия» мәктәбенә нигез салучы суфи җирләнгән).

Төш җитәрәк Гиссар кирмәненә җан керде. Баскычларга кызыл келәмнәр җәйделәр, чәчәкләр һәм челтәрләрдән күчмә загс атрибутлары ясап куйдылар, өч-дүрт егет милли уен коралларында уйный башлады. Өч машинадан торган туй кортежы күренде. Нәкъ менә өч кенә булырга тиеш, артыграк булса, җирле законнар буенча штраф чәпиләр, дип аңлаттылар. Кияү дигәне безнең кияүләрдән берни белән дә аерылмый: кара костюм, ак яка. Кәләш тә ак күлмәктән. Әмма аермасы шул: ул керфекләрен күтәреп карарга тиеш түгел. Елмаерга да ярамый. Аннан соң... бичаракайның башында яулык өстенә яулык өелгән. Кәләш өч адым атлый да, өч тапкыр башын ия, берәр апасы башына яулык куя. Янә өч адым атлый – янә яулык ябалар. Кая барасын ул чамаламый да бугай, аны кулыннан тотып кына йөртәләр. Кәләшне, нигездә, кияүнең әти-әнисе сайлый. Алар туй көнендә генә күрешә, ди. Дөрес, Гиссар кирмәнендә тамаша кылган бер сәгать эчендә генә дә без төрле-төрле туйлар, кәләшләр күрдек. Әмма җирле халык гореф-гадәтләрне санларга тырыша. Ризык дигәнен дә төрләндерергә ярамый, икенчегә ике төрлене генә тәкъдим итәргә була, ягъни мәсәлән. Моны тикшереп йөрүче махсус кешеләр дә бар.

Туй кортежына дүртенче машина булып ияреп, без дә кайтырга кузгалдык. Кайтыр юлыбыз Широра дигән авыл аша иде. Рәшәткә белән тотып алынган булуы аптыраштa калдырды. Баксаң, ул каберлек икән. Таҗикстанда табигать бәла-казалары әледән-әле булып тора. Йә җир тетри (без барганда да ике тапкыр тетрәде, аңламый да калдык – суыткыч ишеге ачылып ябылды, һәм люстралар ярты минутлап зыңлап торды), йә таудан сил ташкыны кузгала. Узган гасырның 80 нче еллар урталарында биредә дә фаҗига була: тулы бер авыл сил ташкыны астында кала. Такси йөртүче абый бу вакыйгалар шаһиты булган. Безгә менә ниләр сөйләде: «Экскаваторда эшләгән чагым иде, шундый хәл булды, дип, кышлакны силдән чистартырга куштылар. Бардык. Тимер чүмеч белән бер-ике казыдыммы-юкмы – күздән яшьләр килә, кичә генә тере булган кешеләрнең мәетләре чыга башлады... Шуннан җитәкчелек бу авылны казымаска, ә туганнар каберлеге итеп рәшәткә тотарга боерды... Ә-ә... әйтергә онытып торам икән. Бу авыл нигә Широра дип атала, дисезме? Бердәнбер исән калган бала исеме ул. Аны туганнары алып китте, үсеп җиткәндер инде сабый. Ә бу тәтенсез авылны аның исеме белән атадылар. Менә шундый хәлләр...»

Бирнәне кыз тууга ук әзерли башлыйлар, ә улларына бәләкәйдән ук калым җыялар.

Кунак хакы

Таҗиклар дигәннән, бездә Равшан белән Жамшут образлары гына берегеп калган шикелле. Аларның күбесе Россиядә төзелешләрдә гастарбайтер, гаражларда автослесарь булып эшли, ишегалларын җыештыра, маршрут автобуслары йөртә. Яшәү урыннары: иске тулай тораклар, подваллар, ташландык йортлар... Ә үз илендә бу халык ничек яши микән?

PRESSA.RU



■ Пылауны ишегалдында учак ягып пешерделәр. Урамда, берничә йортка берәүдер инде, тандыр-мич тырпаеп тора. Аның стеналарына ябыштырып, фатир (безнеңчә ләвәш буладыр), көлчә (кечерәк ләвәшләр) һәм ит, помидор, сыр, тәмләткечләр кушылган самбусалар пешерәләр.

Кунакка хөрмәт зур, соңгы ризыкларын да табынга куярга мөмкиннәр.

Бәхтияр автобус йөртә. Мөмкинлеге булганда Россиягә килеп эшли дә, булган бар акчасын гаиләсенә юллап бара икән. Дүшәмбедә дә маршруткада эшли. Төп йорт янәшәсенә үзенә дә бер йорт төзегән. Хатыны Зәмирә тегә, балалар карый. Аның килендәше мәктәптә рус теле укыта икән. Шуңа күрә аралашу җайлы гына барды. Ике якның да әниләре рус телен белә – совет заманы кешеләре! Урта Азиядә кунакчыллык культ дәрәҗәсендә. Килен тиешле кешеләр йөгереп йөрде, балаларны уйнатты. Табын дигәне идәндә. Мамык тутырылган көрпәчәләргә утырасы. Аякны сузып утырырга, ятарга ярамый, әдәпсезлек билгесе санала.

Дүшәмбедә Лола дустыбыз гаиләсендә дә кунакта булдык. Лола Дүшәмбе дәүләт институтында фарсы телен укыта. Өч улы бар. Күп катлы йортта – фатирда яшиләр. Ире шулай ук автобус йөртә. Тумышы белән Кулябтан, авылдан ул. Әти-әнисенең өч гектар җире бар, шунда әстерхан чикләвеге, инҗир, шәфталу агачлары үсеп утыра. Җиләк үстерәләр, яшелчәләр... Без кунакка килгәндә, әнисе дә кызының хәлен белергә килгән иде. «Үзебез үстергәне балаларга җитә, кеше яллап эшләткән юк, яшем барса да, һаман шул бакчабызда мәш киләбез», – дип сөйләде ул безгә. Балалары язмышы өчен әни кешенең йөрәге өзелә икән. Ник дигәндә, илдә ипотекаише программалар юк, бюджетта эшләгән, балалар үстергән кешегә фатир сатып алу һич тә мөмкин нәрсә түгел (югыйсә ул вуз укытучысы бит!). Күп катлы йортларда су булмаган көннәр дә шактый ди.

Фатир алу гына түгел, авырып китү дә бик авыр хәл Таҗикстанда. Чат саен даруханәләр булуга карамастан, хастаханәләр бер дә мактанырлык түгел. Лола сөйләде: күкрәк баласы белән әле яңа гына хастаханәдән чыккан, башта бер төрле авырудан, аннан икенчесеннән дәвалаганнар. Аннан әни кеше үзе дә өзлеккән. Ә хастаханәләрдә бездәге кебек шартлар юк, ашатулар да каралмаган. Хәтта бала табучы хатыннарга су да бирүче юк. Акча түләп, түләүле палатага салсаң, бәлки... Туганнары ашатырга тиеш. Шуңа күрә хастаханә тирәләрендә пакетлар күтәренеп йөргән кешеләр шактый күренде. Төрмәгә утыруның да «файдасы» юк: Таҗикстанда тоткыннарны да ашатмыйлар. Барысы да туганнар җилкәсендә.

Сүз ахырында

Дүшәмбенең колач җитмәслек чинарлар үскән күләгәле урамнарын, тәмләткеч, җимеш, чәй, тозлы эремчек – корт шарчыклары, ләвәшләр тау-тау өелгән базарларын, милли парктагы түбәсенә дәүләт гербы төшерелгән музеен, адым саен дәүләт лидерлары сыннары һәм сурәтләрен сагынып искә алырга гына калды. Күңелеңне бөтереп ала торган сихер бар димме бу илдә? Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

КЫЗЫК



■ Фатирларында утырыр һәм ятып йоклар өчен көрпәчәләр өелгән. Диван да, өстәл, урындыклар да юк. Аш бүлмәсенә кечерәк кенә микродулкынлы мич сыман духовка һәм бер казан сыярлык электр миче алып куйганнар. Чәй дигәне зур электр чәйнектә кайный. Анысы гел кайнап тора – бик уңайлы, диләр.
Лола безне курутоб белән сыйлады. Анысы монда бик популяр ризык икән. Агач табакка катлы камырдан үзе пешергән фатир (ләвәш) сындыргалап сала да, өстенә кыяр, помидор, суган турап куя (яшелчәләрнең суын сыгып саласы). Шулар өстенә яшел үләннәр, сарымсак, тоз, борыч ише тәмләткечләр кушкан катык сала. Кышын майда суган кыздырып та кушалар икән. Үзенчәлекле ризык. Шуны бармакларың белән алып ашыйсың... Лоланың уллары комган һәм табак тотып тора – кулың юарга ваннага кадәр барып торасы да юк...



Надия
ШӘЙХЕТДИНОВА

ӘБИЕМ ҺӘМ ӘНИЕМНЕКЕННӘН МИНЕМ САНДЫК КЕЧЕРӘК. ӘММА ФАТИРЫБЫЗ ӨЧ БҮЛМӘЛЕ БУЛСА ДА, ТЫНЫЧ КЫНА БЕР УРЫНДА «УТЫРА» АЛМЫЙ. САНДЫККАЕМ, СҮЗ ДӘ ЮК, УРЫНЫҢ ТҮР БАШЫНДА СИНЕҢ. БИГРӘК ТӘ КҮПМЕ КҮРГӘН ШАТЛЫК-МИХНӘТЛӘРЕҢНӘН СОҢ. ТИК...

САНДЫК КЫЙССАСЫ

«Әни, бу сандыкны минем бүлмәдән алсагыз иде инде! Подъездга булса да чыгарып куегыз!» – диде улым, эштән кайтып керүемә. Беренче генә әйтүе түгел, әмма сизәм, бу юлы коры вәгъдәләр белән генә котылып булмас, ахрысы...

Сандык, сандык! Күпме хатирәләр, истәлекләр сиңа бәйле... Дәү әни, ерак әбиләрем сандык белән кияүгә чыккан, әле нинди сандыклар иде алар! Кечкенә генә йозаклары чылтырый башлауга йөгереп килеп янына тезләнәбез. Капкачы ачылу белән аннан тәмле булып алма, җимеш, хушбуй, сабын исе өйгә тарала... Бергә яшәгәнлектән, дәү әни сандыгы тирәсендә еш урала идек. Безне кибеткә җибәрәсе булса, шул сандыктан акча янчыгы чыга, чәй эчәргә утыра башласак, хөрмә-җимеше алына, йә әр-яңа кызыл эчле галошыннан бөдрә башлы сабый рәсеме төшкән хуш исле сабынын алып, ләгән-комган тирәсенә куя...

Әнинең сандыгы бераз кечерәк иде. Шәһәргә күченгәч тә ул аны үзеннән калдырмады, бер бүлмәле фатирда да урын табылды. Сиксәненче елларда сандык белән кияүгә чыгу ул кадәр үк модада түгел иде түгелен. Ә мин сандыксыз кияүгә чыгуны күз алдыма да китерә алмадым. Туйда ул сандыкны кияү буласы кешегә ничек итеп ике бәясенә сатканнарын күрсәгез?! Эче тулы бүләк, өй кирәк-яраклары иде кайнана бусагасын атлап кергәндә. Ә анда тагын ике сандык булып чыкты, бу йорт кызлары сандыкларын алып китеп тормаганнар. Шунлыктан, минекенә урын верандада булды. Әйбәт иде урыны. Тик бервакыт авылга кунакка кайтып килгән тутам:



– Кыз, ишеттеңме, синең сандыгың анда кияүгә киткән! – дигәч, телсез калдым. Бактың исә, туганыбызның кызын да сандык белән кияүгә бирәселәре килгән. Кайнанам үзенекен тәкъдим иткән итүен, тик кая ул, калайлары ялтырап торган зәңгәр буяулы, агач исләре дә таралып өлгермәгән яңа сандык булганда... «Сандыгыңны китерерләр», – диде кайнанам, үзен гаепле санагандай, без кунакка кайткач. Икенче елны да шул сүз булды. «Быел сандыгымны күрми китмим», – дидем иремә. Кайнанам да борчыла. Беркөн иртән торышка верандада җиңелчә генә ыгы-зыгы сизәм. Чыксам, сандык чистарталар! Йа Раббым, калайлары каралган, ялтыравыгының эзе дә калмаган, буявы уңган... Ә эче, рәхмәт төшкере, шул килеш – сапсары такталары, әйтерсең лә, менә кабат очраштык, дип көлеп тора. Әллә кызганудан, әллә шатлыктан тулган күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып, ишегалдына атладым. Кайнанам: «Утынлыкта торган, аннан телевизор астына кертеп куйганнар куюын», – дип, мине юаткандай сөйләнә калды. Сандыгым кайтуга барыбер бик шат идем! Ул елны да алып китеп булмады үзен. Инде бүтән тотынучы булмас дип, тыныч күңел белән калдырып киттем. Янәдән ялга, озакка булмагач хәбәр итми генә кайтып төштек. Верандага атлау белән күзләрем... сандыгымны тапмады. Ә бусагада безне күргән кайнанам дулкынланып китте. «Бөтен җирне тычкан басты, мәлгуньнәр! Ике капчык онны, инде анда кирәлмәсләр, дип, шунда тутырып куйган идем...» Онлы сандыгым келәттә утыра иде. Ул көн он бушатып, сандык чистартып үтте.

– Алып кит инде бу сандыгыңны, – ди әни, ялваргандай. Бу юлы да утырып калды әле ул. Яңадан килен төшәсе юк, мин бишенчесе, аннан, сандык белән килгәне дә мин генә бит әле, үз кадереңне үзең белмәсәң! – дидем дә сандыгымны алгы өйгә, түр башына кертеп куйдым. Шактый еллар үткәч, яшәү урыныбызны башкалага алыштырдык. Күченеп килгәндә, юл уңаенда, сандыкны да үзебез белән алдык. Инде, дус-туганнар елмаеп караса да, безнең белән яңа фатирга да күченде ул. Эче тулы байлык: яңасы дисеңме; әни-әбиемнәрнең ядкарьләре булып калган ашъяулык белән кызыл башлы сөлгеме, ефәк шәл, күкрәкчә, аннан әнинең үз куллары белән чиккән, авыл яшьләре театр уйнаганда алып торгалаган канатлы алъяпкычы... Кызымның тәпи йөреп киткәч тә кигән учка сыеп бетәрдәй әрфия күлмәге, улымның башлыгы... һәркайсы – үзе бер хатирә. Уйласаң уелып китәрлек!

– ...Әни, дим, аласыңмы сандыгыңны? Залга, сезнең якка кертеп куям, алайса... – диде улым, уйларымны йомгаклагандай. Тагын ниләр генә күрәсе бар икән сандыккаемның?!

PRESSA.RU

16+

ХАТЫН – ИҢ ЯХШЫ ДУС



Нияз ӘХМӘДУЛЛИН, «Татарстан» журналының баш мөхәррир урынбасары. Өйләнгән; Гаилә стажы – 17 ел. Ике бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Иң беренче тәэсир, мөгаен, аның атлап баруын күргәч тә туадыр. Хатын-кызның холкы, кәефе – барысы да аның атлавында чагыла: йә ул кояшка күмелгән шатлыклы җыр, йә ул юлында очраган барлык киртәләрне җимереп ташларга әзер булган ташкын яки инде авыр аякларын көчкә сөйрәп атлаучы күңелсез бер картина... Зифа буй-сын, нәзакәтлелек – ир-атның күзе, һичшиксез, менә шуларны күреп ала. Аннан соң гына хатын-кызның күзенә, йөзенә, чәчләренә игътибар итә. Кешенең күзләрен, чәчен генә яратып та, аның башка җирләре ошамаска һич мөмкин түгел бит. Матурлык турында, гомумән, сүз бармый әле монда, чөнки ул төшенчә бик күп кырлы, һәм аңа һәркемнең бәясе үзенчә. Еш кына шулай да була бит: ерактан ул хатын-кыз сиңа әллә кем булып күренә, аңа ничек якынаерга белми аптырыйсың. Ә соңыннан үкенәсең: якын килмәсәң, урап узсаң, хәерлерәк буласы булган икән... Беренче тәэсирдән соң тагын шул мөһим: ягымлымы, сөйкемлеме ул? Безнең бүгенге ыгы-зыгылы заманда бик еш очрый торган сыйфат түгел бу.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Дебет белән кредитны туры китерә алмавындыр. Акчаны бик җиңел һәм артык уйламыйча туздыруы өчен хатын-кызны гаепләргә кирәкми. Әмма шул ук вакытта моны эшләргә ир-ат аңа юл куярга тиеш түгел. Хатын-кызга бөтен нәрсәне уйлап, исәпләп бетермәсә дә ярый. Монысы ир-атка калсын.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Җавапның нинди буласы билгеле инде – хыянәт. Бер-береңә ышану, таяна алу – болар гаиләнең генә түгел, дуслыкның да, туганлык мөнәсәбәтләренең дә нигезендә ята. Без җәмгыять идеалларга кытлык кичергән чорда яшибез. Шуңа күрә дә бүгенге көндә үзенә бик сак мөнәсәбәтне таләп итүче кыйммәтләрнең берсе гаилә дибез. Калган бөтен нәрсә дә узгынчы...

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Минемчә, ике төрле генә бүленеш аз булыр. Бу ике категория арасында әллә никадәр нюанслар табарга мөмкин. Ә бит әле үзләре алдан йөрергә ярата торган, көчле холыклы, уңышка ирешү юлын сайлаган хатын-кызлар да бар. Нинидер кысаларга кертергә тырышу меңгә тапкырланырга сәләтле хатын-кыз затларының бай дөньясын ярлыландыра сыман. Мин үзем өйдә уңайлы, җайлы, тыныч халәт тудырырга сәләтле игътибарлы хатын иренең хезмәттәге үсешенә беренче ярдәмче була инде ул дип уйлыйм. Әмма хатын-кыз йорт куяны булып кына калмаска тиеш. Үзен тулаем гаиләсенә багышлаган хатын-кызның нинидер матур сыйфатлары югалыр иде. Көнкүреш ул корбаннар алырга ярата. Алтын урталыкны таба белү мөһим. Нәкъ менә шул «алтынны» табу – ир кешенең бурычы.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә, дус була ала. Күпләр өчен хатынның һәм дусның бер үк кеше булуы табигый, минемчә. Чишелешен эзләп, башыңда кат-кат әйләндергән бик мөһим сорауларны кайчакта хатының белән уртаклашырга мөмкин. Алай гына да түгел, хәтта кирәк! Нинидер киңәш алу максатыннан да түгел. Уйларыңны кычкырып әйтеп карарга кирәк чаклар була. Мондый вакытта иң кулае – хатын белән сөйләшү. Син уйлап-уйлап та башың җитмәгән, гел көтмәгән бер киңәш биреп тә куярга мөмкин әле ул сиңа! Нинидер карар кабул иткәндә хатынның ролен күрсәткән бер мәзәк искә төште әле. Бер җитәкчене аннан өстәрәк торган икенче җитәкче чакыра да аңа яңа җаваплы эш – югарырак кәнәфи тәкъдим итә. «Уйларга бер көн бирегез, хатыным белән киңәшләшим», – ди монысы. Икенче көнне хуҗасының бүлмәсенә керә дә: «Мин риза, хатыным да бу карарымны хуплады», – ди. Әмма босcның төн чыкканчы карары үзгәргән булып чыга: «Мин дә хатыным белән киңәш-

ләштем, ул сине бу урынга билгеләүгә каршы булып чыкты әле, шулай булгач, гаепләмә», – ди.

Шаяру инде, әлбәттә. Әмма дөрес тотып алынган бит! Бар нәрсәдә дә чама булырга тиеш шул... Дуслык турында сөйләшә идек бит әле. Хатыннан да яхшырак дусны табу авыр инде ул. Уртак хобби, уртак кызыксынулар, дөньяга бертөрле карашлар... Бер үк нәрсәләрне – яхшы, бер үк нәрсәләрне начар дип кабул итүләр. Безнең заманда сәяси карашлар да туры килсә, икең дә бер партиядә торса, бер үк депутатларга тавыш бирсә, бигрәк тә әйбәт инде. Нык, идеологик яктан коралланган дуслык була ул чагында. Шаяртам, билгеле...

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Бик яхшы хәтерлим! Булачак тормыш иптәшем белән без инде берничә ел очрашып йөрдек, һәм минем тарафтан булган бу тәкъдим берничек тә көтелмәгән түгел иде: аны бер көнне әйтәсем көн кебек ачык иде бит. Әмма ни генә булса да, ул сүзләрне әйткән мизгелдә без икебез дә бик дулкынландык. Тиздән яңа тормыш башланачак, моңарчы белмәгән, күрмәгән, татымаган тормыш... Үз өстемә нинди зур җаваплылык алуымны мин ул чакта ахыргача аңлаганмындыр дип уйламыйм. Соңрак, балалар тугач кына килде бугай әле ул хис. Аннан инде шулай тиеш дип кабул ителә башлады... Өйләнешәбез дигән карар кабул итүгә киләчәк ничектер ачыкланды, тәгаенләнде: тормыш билгеле бер эзгә төште.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Белмим, минем үзем белән алай булмады. Башка кешене (хәтта кайчак үзеңне дә!) тәмам аңлар өчен күпмедер вакыт кирәк... Хәзер кайчакта гаҗәпләнеп җәмәгатем холкындагы кайбер сыйфатларга игътибар итеп куям: нәкъ минем әни бит! Лариса гел шундый булгандыр инде ул, мин генә моңарчы күрмәгәнмендер... Тормыш юлдашы сайлаганда ир-ат нәрсәләргә таяна дигән сорау шуңа да минем өчен әлегәчә җавапсыз кала.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Ул бу очракта тагын да күбрәк эшләргә, моңа кадәр башкарган эшен тагын да яхшырак башкарырга тиеш була. Тагын нинди юл кала инде аңа?! Ир-атны кимсетерлек, түбәнсетерлек берни дә юк монда. Бүгенге тормыш элеккеге калыпларга берничек тә сыймый инде хәзер. Берни эшләп булмый, цивилизациянең үсешенә каршы төшү мәгънәсезлек. Бу очракта, иң мөһиме: гаиләне саклап калу; ә акчаны кем һәм күпме таба дигән сорау берничек тә беренче урында тормый.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Әйбәт карыйм, белгертсеннәр. Әгәр шундый кыю, тәвәккәл хатын-кызлар күбрәк булса, ялгыз ир-атлар азрак булыр иде. Ул ялгызлар арасында эчеп юлдан язган, кешелеген югалткан яки беркайчан өйләнмәскә тәүбә иткән буйдаклар гына түгел бит. Кыюсызлыгын җиңеп, хатын-кызга сүз куша алмаган, аралашуда ниндидер кыенлыклар кичергән менә дигән егетләр дә бар. Хатын-кызлар, әнә шундый ир-егетләрне безнең арадан күреп, танып ала белегез һәм беренче адымны үзегез ясаудан тартынмагыз!

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Хатын-кызлар өчен җавап бирү авыр инде ул... Әмма үзем күргәннәрдән, үзем күзәткәннәрдән чыгып шуны әйтә алам: аларны бик күп нәрсә җәлеп итәргә мөмкин. Хәтта без күз алдына да китермәгән нәрсәләр! Кайчакта чынлап торып гаҗәпләнәсең: бер кашык су белән йотарлык чибәр, өстәвенә, ир-атлар көнләшерлек акыллы ханым янәшәсеннән ниндидер бер «фрик» атлый: ирененә, кашында, борынында пирсинг, башыннан аягына кадәр татуировка ясалган, кигән киемнәрен әйтмим дә... Андыйларда да нәрсәдер табалар бит! Әмма барыбер ир-атның уен-көлке яратуын, үткен, тапкыр, ышанычлы булуын алар күпкә югарырак бәяли. Хәер, бу сыйфатлар кем күңеленә хуш килмәс?!

11 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Ир-ат хатын-кыздан да курыкса, аннары ни була инде? Гүзәл затларның иң чибәрләре безнең илдә диләр – шулар янәшәсендә яшибез бит әле, үлмибез... Ә җитди итеп әйткәндә, болай: янында гаҗәеп чибәр хатын-кыз булганда ир-атның үз-үзенә таләбе күпкә югары күтәрелә. Ул үзен җаваплырак хис итә. Ир моны махсус эшләми – үзеннән-үзе шулай килеп чыга. Яхшы яхшыга гына тартылачак дип саный ул, шуңа да булганыннан акыллырак, әйбәтрәк күренергә тырыша. Һәм тагын ялгыша! Хатын-кызның логикасы бернинди кысаларга да сыймый, бернинди кануннарга да буйсынмый: чынлыкта, тормышта яхшының начарга тартылган очраклар да бихисап.

12 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар, сезнеңчә, бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– «Хатын-кызны алдалый алмыйсың, ул йөрәге белән дә күрә», – ди «Место встречи изменить нельзя» фильмының бер герое. Минемчә, хатын-кыз логикасы шушыңа нигезләнгән дә инде: уйлаганда иң беренче чиратка ул хисләрне куя. Ә без, ир-атлар, күбрәк акылга таянабыз. Әмма иң кызыгы шунда: «акыл белән уйлыйбыз» дип мактансак та, безне төп башына утырту җиңелрәк. Беркатлыракмы соң без, хәйләне белмибезме?

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан... Бу хәл белән ничек көрәшәсез?

– Берничек тә көрәшмим, чөнки көрәшергә сәбәп юк: кая гына барырга җыенсак та, хатыным миннән алданрак әзерләнеп бетә. Һәм һәрвакыт миңа ашыгырга туры килә. Үземне дә әкрен кеше дия алмыйм, әмма ул миңа караганда да оешканрак.

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә...

– Ларисаның миңа биргән ниндидер бүләгенең ошамаганын, шуның аркасында кәефем төшкәнен хәтерләмим. Әйберне сайлый белә ул. Шуңа күрә дә сюрпризлары һәрчакта да сөендерә.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU



ПАЛЬМА МАЕ

Аны ни белән ашыйлар? Файдалымы бу май, зыянлымы? Россия кибетләрендә сатыла торган сөт ризыкларының 30 процenttан артыграгы – составында пальма мае булган фальсификат. Андый ризыкны сатып алыргамы инде, юкмы? Ризыкка пальма мае кушу бик табышлы. Чөнки ул җитештерү чыгымнарын бик нык арзанайта, ризыкны саклау вакытын озынайта һәм без еш кына бу бит чып-чын атланмай тәме дип алдана торган тәм бирә. Чынында, сатып алучы бер нәрсәдә генә ота: пальма мае кушылган ризыклар арзанрак була. Намуслы җитештерүчеләр хөкүмәткә пальма мае кушучыларны бу хакта ризыкны төргән кәгазьдәме, башка савыттамы «пальма мае кушылган» дип язарга мәҗбүр итәргә кирәк дип мөрәҗәгать иттеләр. Андый төр продуктны Россиядә сатуга чыгармаска кирәк диючеләр дә бар. Тик өстән карар күренми әлегә. Шуңа күрә җитештерүчеләр әүвәлгечә үзләре җитештергән товарга пальма мае кушылганлыгын яшерә бирәләр.

Пальма мае нәрсәгә кушыла?

Пальма мае хуш исле булганга күрә ризыкларның тәмен яхшырта. Җитештерүчеләр өчен бу бик әйбәт инде. Бердән, ризыкның кыяфәте матур күренә; икенчедән, товарның үзкыйммәте арзанрак була. Россиягә кайткан пальма мае күбәйгән саен, аларның табышы да арта бара. Нәтиҗәдә, демократик бәяләрдән сатыла торган сөт ризыкларының чын сөт белән берниндн уртаклыгы да юк булып чыга.

Пальма маен, нигездә, сөттәге майга альтернатива рәвешендә кулланалар. Ул бигрәк тә маргаринда, атланмай дип тәкъдим ителә торган майларда, сырларда, каймакта, эремчектә, туңдырмада, йогыртларда, куертылган сөттә һәм коры сөтләрдә күп була. Әле тагын ризыкның кыяфәтен күркәм итү, саклау вакытын озынайту өчен аны пирожныйларга, тортларга, рулетларга, кексларга, крекерларга, шоколад конфетларга, хәтта шоколадның үзенә дә кушалар. Пальма мае чипслар, фри бәрәңге, гамбургерлар, чизбургерлар әзерләгәндә дә кулланыла.

Пальма маеның зыяны нидә?

2005 елда ук әле Бөтендөнья сәламәтлекне саклау оешмасы пальма маен куллануны кимергә тәкъдим иткән иде. Йөрәк һәм кан тамырлары авыруларын киметүне максат иткән тәкъдим иде бу. Пальма мае кушылган ризыклар бигрәк тә кече яшьтәге балалар өчен зыянлы. Еш кикерү, эч кату, эч бору күренешләренең пальма мае кушылган ризыклар ашаудан килеп чыгуы да исбатланган.

Соңгы вакытта пальма маен акларга тырышалар. Имеш, аның искиткеч файдалы үзлекләре бар. Бик кыйммәт йөри торган кызыл төстәге пальма мае чыннан да файдалы. Евросоюз илләрендә фәкать шул кызыл майны гына кулланалар. Безнең илдә кулланылышта булган пальма мае исә Европа илләрендә техник май сыйфатында, детальләрне майлау өчен генә файдаланыла икән. Андый пальма мае организм өчен дөрестән дә бик зыянлы.

Пальма маен пальманың майлы төрләренең җимешеннән сыгалар. Анда холестеринны күтәрә торган һәм кан тамырларына ябышып кала торган май кислоталары 50 процентка кадәр җитә. Пальма маеның төп өлешен тәшкил итә торган пальмитин кислотасы кан тамырларында төерләр хасил итә һәм шунлыктан атеросклероз, инфаркт, инсультише чирләр килеп чыга.

Лупа сатып алыгыз

Кибеткә кергәч, ашык-пошык товар сатып алмагыз. Башта төргәктәге язуларны игътибар белән укып чыгыгыз, аннан продуктның составын өйрәнегез. Күп кенә җитештерүчеләр аны бик вак хәреф белән яза. Шуңа күрә кибеткә лупа алып барыгыз. Шул чагында организмга зыян сала торган зарарлы продуктлар сатып алмассыз. Бәясе артык арзан тоелган продуктларны да алмагыз. Чын сөт-каймактан әзерләнгән ризыклар арзан була алмый. Чөнки бер килограмм чын атланмай чыксын өчен 20 литр сөт аертырга кирәк. Димәк, андый ризыкның үзкыйммәте дә югарырак булыр.

Сез моны беләсезме?

■ Индонезиядә, Таиландта, Һиндстанда, Нигериядә пальма мае аеруча күп җитештерелә һәм бүтән илләргә сатыла. Май пальмалары үстерү, нефть скважинасына ия булуга караганда, отышлырак санала. Бу бизнес бик рентабельле.

■ Сыйфатлы атланмайның кәгазенә ГОСТ Р 52069-2008 номеры язылган булыр. Игътибар итегез: байтак кына маргариннар һәм спредлар да ГОСТ буенча әзерләнә. Әмма аларның санлы билгеләмәләре бүтәнчә. Әгәр дә чын май сатып алырга теләсәгез, кәгазьдән ГОСТ номерларын эзләп табыгыз.

ДӨРЕС МАЙНЫ НИЧЕК ТАНЫП БУЛА?

■ Майның төсен, тәмен, кыяфәтен чамалап карагыз. Яхшы сыйфатлы атланмай бертигез тыгызлыкта, саргылт төстә булыр, аннан сөт исе килеп торыр, тәме чын май тәме булыр. Андый май авызда тәмам эреп бетәр, телдә дә, аңкауда да ябышып калмас.

■ Майны бүлмә температурасында калдырып торыгыз. Ялган май «тирләп» чыгар.

■ Майны табада эретеп карагыз. Чын атланмай шунда ук чыжлый башлар, аның өстендә күбек хасил булыр, тәмле хуш ис бөленеп чыгар. Ә пальма мае фәкать эреп – агып китәр.

■ Бер кисәк майны кайнар суга салыгыз. Сөт продукты өстә йөзеп йөрер-йөрер дә үтә күренмәле тапка әйләнер. Катнашма булганы куе, тыгыз утырым хасил итәр. Әгәр аннан соң суны болгатсаң, май эреп юкка чыгачак, ә маргарин вак кисәкләргә таркалып бетәчәк.

■ Май брикетын туңдыргычта тотып алыгыз. Туңган атланмайны кисеп алып булмас. Ул кисәк-кисәк булып кыелып кителер. Ә катнашманы рәхәтләнеп ипигә ягарга мөмкин.

PRESSA.RU

ЗӘМИРӘДӘН КУНАК СЫЕ



Зәмирә РӘҖӘПОВАны күпләр телевидениедә эшләгән чагыннан ук беләдер. «Мәдәният дөньясында», «Җырлыйк әле», «Татар моңы», «Җомга көн кич белән» – ул иҗат иткән тапшыруларның берничәсе генә әле болар. Бүген Зәмирә ханым Халыклар дуслыгы йортында режиссер, бәйрәм кичәләрен оештыручы булып эшли, Аяз белән Данилнең газиз әнисе, ире Максимның сөеклесе, дуслары өчен уңган хуҗабикә... Хуҗабикә дигәннән, тәмле ризыклар пешергәндә җаным ял итә, пешерергә бик яратам, ди ул үзе дә. Мастер-класста пешереп күрсәткән бу пирожныйларны аннан хәтта заказга пешереп бирүләрен дә сорыйлар икән. «Кунаклар киләсе булса, торт алмыйм, шушы ризыкны пешерәм. Авыз иткән кеше, кәгазь-ручка сорап алып, рецептын язмый калмый», – ди Зәмирә. Дөрестән дә, авызда эреп китә, бик тиз әзерләнә аның профитрольләре. Пешереп, сез дә сыйланыгыз әле!



Кирәк:

(камыр өчен)
- 1,5 стакан су;
- 150 г атланмай;
- 1,5 стакан он;
- 5 йомырка;
- бер чеметем генә тоз.

(крем өчен)
- 500 г кибет каймагы (20% майлылыктагысы);
- 250 г «Маскарпоне» сыры;
- 1 стакан шикәр комы.

Эш барышы:

■ Чүмечкә су салып, кайнатырга куябыз. Су кайнап чыккач, бүлмә температурасында йомшарган атланмайны салабыз. Май эреп беткәч, чүмечне уттан алып, бер чеметем генә тоз сирпибез.

■ Онны 2-3 тапкыр иләктән иләп (бу бик мөһим, югыйсә ризыгыбыз күперенке булмый), азлап-азлап кына чүмечтәге сыеклыкка салабыз, төерләре калмаслык итеп, яхшылап туглыйбыз.

■ Камыр бераз суынгач, бер-бер артлы йомыркаларны сытабыз. Сыткан берен яхшылап болгатабыз. Үзле, төерләрсез, йомшак камыр булырга тиеш.

■ Әзер камырны кондитер капчыгына бушатып (моның өчен катык яки сөттән бушаган полиэтилен каплар да бик кулай, бер почмагын чеметеп кенә кыеклап кисеп аласы гына бар), пергамент кәгазь җәелгән табага кечкенә чүмәләчекләр итеп кысып чыгарабыз. Араларын бушрак калдырырга кирәк.

■ Профитрольләрне ярты сәгатькә 150-180 градус кызулыктагы мичкә тыгабыз. Алар күпереп менгәнче, мич ишеген ачмый торырга кирәк. Өсте кызаргач, әзер була.

■ Алар пешә торсын, без крем әзерләп алыйк. Тирән эчле савытка каймак белән шикәр комын салып, шикәр комы эреп беткәнче туглыйбыз.

■ Аннары сырны салып, туглауны дәвам итәбез. Кремда вак төерчекләр калмаслык булсын.

■ Бераз гына суына төшкән профитрольләрнең бер ягыннан кашык белән ачып (аларның эче куыш, «авызы» тиз ачыла), эченә крем тутырабыз.

■ Пирожныйларны зур тәлинкәгә өеп, өстеннән калган кремны сибәбез, матурлык өчен какао порошогы бөркибез.

Ашларыгыз тәмле, көннәрегез ямьле булсын!

PRESSA.RU

Без, татар хатын-кызлары, гөлләр яратабыз. Татарлар яшәгән йортны тәрәзә төбендәге шау чәчәкле гөлләрдән танып аласың. Матур гөлләрне күчереп утыртырга матур чүлмәкләр дә кирәк. Хәзер кулдан эшләнгән әйберләр затлы санала бит. Нигә әле ул чүлмәкләрне дә үзебезгә ясап карамаска. Үзебез теләгән зурлыкта, үзебез теләгән төстә итеп! Моның өчен әллә ни зур чыгым да, көч тә таләп ителми. Кирәкле бар әйбер дә кул астында гына.





Мастер-классны Лилия ГӘРӘЕВА үткәрә

БЕЗ ҮЗЕБЕЗ ЧҮЛМӘКЧЕ

Кирәк:

- цемент (М400 яки М500 маркалысы яхшырак);
- иләнгән вак ком (1 өлеш цементка 3 өлеш ком алына).
- су;
- тиз кибә торган һәм калын катлам итеп ягарга мөмкин шпатлевка;
- төрле төстәге акрил буяулар (ак буяуга төс кушып, төсләрне үзегезгә ясарга да мөмкин, без шулай иттек);
- акрил лак;
- кечкенә пумалалар;
- кечкенә шпатель;
- ике савыт – аның берсе булачак чүлмәк зурлыгында, икенчесе аннан кечерәк. Савытлар пластиктан яки калын катыргыдан булса әйбәт. Чүлмәк кипкәч, аларны кисеп алырга туры киләчәк;
- машина мае.





Эш барышы:

■ өстәлгә клеенка җәеп, эш урыны әзерлибез. Үз йортың белән яшәсәң, чүлмәкне урамда эшләү әйбәтрәк, билгеле. Кулга да перчатка киясе булыр. Цемент кул тиресен бик нык корыта.
Зур савытка, артык күп итмичә генә, цемент һәм комны яки әзер составны салабыз да (тузаны күп чыга, сак кына эшләгез!) аз-азлап кына су өсти барып, болгатабыз. Измә каймак куелыгында булырга тиеш. Су өскә чыгарлык булмасын.

■ Чүлмәк коясы зуррак савытның эчен машина мае белән майлап (кубарып алырга уңайлырак булсын



өчен), әзер измәне салабыз. Савытны тутырып бетермибез, яртысы җитеп торыр.
Кечерәк савытны (савытларны берсе эченә икенчесен тыккач, уртада 1 см чамасы ара калсын, бу – чүлмәкнең калынлыгы булыр) целлофан капка тыгып, измәгә батырабыз. Аның кыл уртада булуына, тигез утыруына игътибар итегез. Измә савыт кырыена кадәр менеп җитмәсә, тагын өстибез. Моның өчен кечкенә шпатель бик кулай.

■ Уртадагы савыт калкып чыкмасын өчен, эченә таш яки сулы банка ише авыр әйбер утыртабыз. Һич булмаса, өстеннән скотч белән ябыштырып, беркетеп куябыз.

■ Чүлмәк ике тәүлек чамасы кибә. Мастер-класста әлеге әзерләп куйган чүлмәгебез ике тәүлектә дә кибеп өлгермәгән иде.

■ Әзер чүлмәкне тышкы һәм эчке савытлардан арындырабыз. Кайчагында уңай гына да шуып чыга ул, кайчак савытны кисеп алырга туры килә.

■ Вак бөртекле наждак кәгазе белән чүлмәкнең эчен-тышын ышкып, шомартабыз. Аннан коры тастымал белән сөртеп, цемент тузаныннан арындырабыз.

■ Алда иң күңелле эш тора – чүлмәкне бизәү! Без өске ягын мозаика сыман кайма белән бизәргә булдык. Бәлки, сезнең ремонттан соң матур төстәге чынаяк плитәләрегез (кафель) калгандыр. Аларны вак-вак кисәкләргә бүлеп, чүлмәкне бизәгәндә кулланырга мөмкин. Без исә шпатлевка ярдәмендә мозаикага имитация ясарбыз. Моның өчен, булачак кайманың киңлеген исәпләп, аскы сызыгы буйлап скотч ябыштырып чыгабыз.

■ Кайма урынына шпатель ярдәмендә, калын итмичә генә, шпатлевка сылыйбыз. Ул бераз кипкәч (фен ярдәмендә эшне тизләтергә мөмкин), икенче кат сылыйбыз. Аның да бераз кипкәнен (ләкин тулысынча кибеп бетмәсен!) көтәбез дә шпатель очы белән кайманы вак-вак шакмакларга бүлеп, эз ясап чыгабыз. Һәр шакмакны үзебез теләгән аерым бер төскә буйыйбыз.

■ Әйткәнебезчә, кибеттә акрил буяуларның нинди генә төслесе юк! Ак буяуга төс кушып, яраткан төсебезне үзебез дә чыгара алабыз. Алай арзанрак та була. Без сары һәм яшел төс кулландык.

■ «Мозаика» кипкәч, скотчны кубарып алып, чүлмәкнең калган өлешен буйыйбыз. Безнең чүлмәк фил сөяге төсендә. Каймадагы яшел, сары һәм ак төсләр белән дә яраша ул. Әлбәттә, башка төсләр дә куллана аласыз, һәркем үз фантазиясеннән чыгып эш итә. Буяу кипкәч, бер-ике кат лаклыйсы һәм чүлмәк төбенә дрель белән тишек тишәсе генә кала.

Киңәш:

«Сөембикә» журналының алдагы саннарында төртке бизәк төшерү буенча мастер-класс узган иде. Чүлмәкне бизәгәндә дә шул техниканы кулланып карагыз. Яисә җилем ярдәмендә чүлмәккә вак ташлар ябыштырып, ул ташларны төрле төсләргә буярга мөмкин (буямасаң да матур була әле ул).

PRESSA.RU

Ябыгырга ниятләгән кешеләр порцияне киметеп яки бериш ризыкны гына ашап, артык килограммнардан арынмакчы булалар. Монысы – иң популяр ысул. Ә бит әле тагын дистәләгән төрле диеталар бар. Арадан иң яхшысын, сәламәтлеккә зыян салмый торганын ничек сайлап алырга соң?



Фото интернеттан алынды

ЗИФА БУЛЫЙМ ДИСӘҢ...

Ашамыйча ябыгу

Һәртөрле ризыктан баш тарту, әлбәттә, ябыктыра. Ләкин бу вакытта матдәләр алмашы бозыла, организм стресс кичерә. Аксым җитешле кермәгәнгә күрә организм үзенең мускул тукымасын «ашый» башлый. Ә менә май катламы «эреп бетәргә» ашыкмый.

Ач торуны туктатуга безнең җисемебез май запасы туплауга керешә. Ачлык дәвере тагын кабатланмагае дип курка ул. Нәтиҗәдә, ач тору тәмамлануга ук үлчәү уклары өскә таба менә башлый. Әле артыгын да җыеп ташлый.

Монодиеталар

Сәламәтлек өчен иң зыянлысы һәм иң хәтәре – монодиеталар, ягъни бер генә төрле азыкны ашап, ябыгырга тырышу. Карабодай яки кефир, кәбестә яки алма – монодиета өчен теләсә кайсы ризыкны сайларга мөмкин. Монодиеталар түбән калорияле булганга күрә тиз ябыктыра.

Ләкин монодиета идеаль вариант була алмый. Аларның һәркайсы организм өчен зыянлы, чөнки ризык балансы сакланмый. Шуңа күрә матдәләр алмашы акрыная, ашказаны-эчәк авырулары килеп чыгарга, булганы көчәеп китәргә мөмкин.

Аксымлы диеталар

Аксым күп, ә углеводлар аз булган диеталар чыннан да нәтиҗә бирә. Тик алай да ике-өч килограммга киму сәламәтлеккә килгән зыянны аклыймы соң?

Аксымлы диетаның асылы күпләп ит, сөт ризыклары, йомырка (сарысыннан башка гына), балык ашаудан гыйбарәт. Углеводлар белән майлар бөтенләй ашалмый. Андый диетаны балансланган дип әйтеп булмый. Болай туклану нәтиҗәсендә, бөерләр зарарлана, организм чүпләнә. Бәвел бүлеп чыгару әгъзаларына һәм йөрәккан тамырларына көч килгәнгә күрә, кеше бик тиз арый, холестерин микъдары артып китә, йөрәк кага башлый.

Майсыз диета

Май кеше организмында мөһим функция башкара. Ул күзәнәк мембраналарының эластиклыгын тәэмин итә, майда эри торган витаминнарны үзләштерергә ярдәм итә. Майлар җитешмәү акыл эшчәнлегенең сыйфатында үзен сиздерә, гормональ дисбаланска китерә.

Кыска вакытлы майсыз диета сәламәтлеккә сизелерлек зыян салмас. Әмма озак вакыт майдан баш тартканда күңелсез нәтиҗәләр үзен сиздерә башлар. Тән тиресе төссезләнер, чәч коела башлар, авитаминоз, тәшвишләнү, таркаулык, талчыгу, йокысызлык күзәтелер. Ризыкта май җитмәүдән килеп чыккан үзгәрешләрнең беразы гына әле болар.

Чи ризык ашап тору

Бу очракта сәламәтлеккә зыян салмас өчен диетология җәһәтеннән күпмедер белемең булу зарур. Пешмәгән ризык ашап кына организмны бөтен витаминнар белән тәэмин итеп бетереп булмый. Чи ризык ашаган кешеләрдә B_{12} витаминына кытлык башлана. Андый кешеләрнең теш эмале ашалучан була, бөерләренә таш утыра, гастрит, панкреатит башлана, аллергия килеп чыга.

Ә ничек итеп ябыгырга соң?

Ябыгуның иң дөрес юлы – туклану балансын саклау. Түгелгән энергия кергән энергиядән артыграк булырга тиеш. Ризыкны төрләндереп һәм вакытында ашарга кирәк. Су эчү хакында да истән чыгармагыз. Диета сайлаганда рационны кисеп кенә теләгән авырлыкка ирешеп булмый. Нәтиҗәле һәм зыянсыз ябыгу өчен актив физик күнегүләр белән метаболизмны «куаларга» кирәк. Дөрес туклану, спорт, үз-үзеңне тәрбияләп тору – барыбызга да мәгълүм ябыгу сере шушы.


Кучкар. Вакыйгаларга бай һәм бик уңышлы ай. Тормышның теләсә кайсы өлкәсендә уңыш казана алачаксыз. Кешеләр үзләре сезгә тартылыр, чөнки сездән яхшы энергия бөркелеп тора.


Үгезбозау. Көз башы яңа тәэсирләр, зур мөмкинлекләр вәгъдә итә. Көнкүреш ыгы-зыгысы белән язмыш әзерләгән бүләкне күрми калмагыз. Планеталар шундый итеп тезелгән ки, теләсә кайсы мәсьәләне җиңел генә хәл итү юллары табылачак.


Игезәкләр. Тормышта тоткан урыныгыз ныгыр, макталуга, игътибар үзәгендә булырга әзер торыгыз. Моңа кадәр сезне өнәмәүчеләр хәзер фикердәшләрегезгә әверелер. Яшерен хыялыгызны чынга ашыру мөмкинлеге килеп чыгар.


Кысла. Тормышыгызның тыныч һәм имин чорына керәсез. Үзегез теләгән эш белән шөгыльләнү форсаты килеп чыгар, эшегездән, үз-үзегездән чын рухи канәгатьләнү кичерерсез.


Арыслан. Мөһим карарлар кабул итми, җитди эшкә тотынмый торыгыз. Күңелегезнең үтә дә нечкә чагы. Хисләрне бәйдә тоту өчен рухи көчегезне сарыф итәргә туры килмәгәе. Эчке сизгерлегегез гаҗәеп.


Сөмбелә. Тормыш бизәкләренә бай ай булыр. Грандиоз планнарыгыз шулкадәр күп, арадан иң мөһимнәрен генә аерып алырга туры килер. Көчем җитмәс дип курыкмагыз, ачык энергия агымына керәсез, барысын да булдырырсыз.


Бизмән. Өр-яңа перспективалар, искиткеч мөмкинлекләр көтелә. Тормышыгызны үзгәртердәй яңалыклар булыр. Ул яңа танышлык яисә яңа эш булырга мөмкин. Тормышыгыз гына түгел, аңа булган карашыгыз да үзгәрер.


Чаян. Вакыйгалар үзәгендә кайнарсыз. Кинәт кенә барысы да сезнең фикер, сезнең сүзгә мохтаҗ булып чыгар. Ярдәм итә аласыз икән, баш тартмагыз, бу айда кабул иткән карарларыгыз, биргән киңәшләрегез дөрес булып чыгачак.


Укчы. Хыяллар чынга аша, теләкләр кабул була торган вакыт. Теләкләрегезне һәм фантазиягезне богауда тотмагыз. Никадәр күбрәк теләсәгез, шулкадәр зурракка ирешерсез. Карьера үсеше көтелә.


Кәҗәмөгез. Күңелле һәм рәхәт мизгелләр кичерерсез. Зур планнар корудан курыкмагыз, башка сыймастай кебек күренсәләр дә, аларның чынга ашу ихтималы бик зур. Ярдәм кулын кире какмагыз, бәлки ниятләрегезне чын итәргә нәкъ менә ул булышыр.


Сукояр. Ыгы-зыгылы, вакыйгаларга бай ай. Үзегезгә якынаерга теләгән чит кешеләргә саграк карагыз, мәкер тозагына эләгүегез бар. Уйламаган-көтмәгән җирдән искиткеч тәкъдим алырсыз, ә ул сезнең күптәнге хыялыгыз булачак.


Балык. Шундый да уңышлы ай – язмышның юмартлыкларына хәтта үзегез үк аптырарсыз. Уңышлы гына түгел, күңел тынычлыгына ирешә, һәр эштән рәхәтлек кичерә торган да вакыт әле бу. Бәхетне куркытмас өчен язмышка рәхмәт әйтергә онытмагыз.

*Чит илләр **август**та кабынган йолдызлар*

Татарстан



Ләлә Миңнулина (21.08.1952) – **Татарстанның халык артисты.**

Казанда туып-үсә. Театр училищесында Марсель Сәлимҗанов курсында укый. 1974 елда Республика күчмә театрына эшкә керә. Рольләрне шулкадәр чын, ихлас уйнавы белән тиз арада халык мәхәббәтен казана ул. Әмма энисе каты авыру сәбәпле, аңа театрдан китеп торырга туры килә. Театрдан аерылуы 1985 елда тагын кабатлана. Тормышының бу чорында аңа почтальон да булырга, балалар бакчасында да, хәтта заводта да эшләргә туры килә. Һәм бу тәҗрибәсе кабат театрга кайтып, актерлык эшчәнлеген дәвам иткәндә ярап куя. Ул күп уйный, төрле-төрле геройларны тасвирлый, табигыйлыгы белән җәлеп итә. Өч дистәдән артык роль арасында күңелгә иң уелганы дип, артистка үзе «Кырларым-тугайларым» (Т. Миңнуллин) спектаклендә – Мөслимә; «Кара йөзләр» (М. Гафури) спектаклендә Галимә рольләрен атый.

Россия



София Ротару (7.08.1947) – **җырчы, СССРның, Украина һәм Молдавиянең халык артисты.**

Украинаның Маршинцы авылында алты балалы гаиләдә туа. София җырларны тиз отып алуы һәм матур итеп җырлавы белән балачактан гаҗәпләндерә. Беренче класстан ук мәктәп һәм чиркәү хорына йөри. Беренче уңыш аңа 15 яшендә үк елмая – районда узган үзешчән сәнгать смотрында җиңү яулый. Аннары өлкә конкурсы, Киевта узасы фестивальгә юллама... 1964 елда аны Кремльнең Съездлар Сараена җырларга чакыралар. 1971 елда экраннарга «Червона рута» фильмы чыга. Төп рольдә яшь җырчы – София Ротару. Соңрак ире Анатолий Евдокименко белән шул исемдәге ансамбль оештырып, илкүләм танылуга ирешә. 1990 елда «София Ротару» дигән беренче альбомы дөнья күрә.



Мелани Гриффит (9.08.1957) – **актриса.**

Фотомодель һәм актриса Типпи Хедрен гаиләсендә бердәнбер кыз булып үсә. Беренче тапкыр реклама роликгында төшкәндә Меланига нибары 9 ай була. 1975 елда «Ночные ходы» (реж. Артур Пенн) беренче җитди ролен башкарып, уңыш казана. Актрисаны йолдыз итеп таныткан фильм – «Дикая штучка». Аннан соң ук дөнья күргән «Деловая девушка» фильмында башкарган роле өчен «Алтын глобус»ка ия була, «Оскар»га тәкъдим ителә. Кинода төшү белән бергә телевизион проектларда да катнаша. «Нью-Йорк таймс» газетасында үз колонкасын әзерли.

PRESSA.RU





АНЫ ДӨНЬЯ БЕЛӘ

Рәссам Нишә БАНУ белән танышуыбыз көтмәгәндә булды. Истанбулга Казаннан Туган тел бәйрәменә барган бер төркем Айа Суфия соборыннан чыгып киләбез. Арабызда танылган галим Хатыйп ага Миңнеголов та бар. «Игътибар иттегезме, күпме йөреп бер аһ итәрек чибәр кыз очратмадык. – ди ул. Шунда ук галимебезнең йөзе балкып китте. – Әнә берәүсе басып тора икән ләбаса! Картиналар янында! Барыйк әле шунда!» Собор эргәсендә урынланган «Җәннәт бакчасы» дип исемләнгән картиналар күргәзмәсенең хуҗабикәсе, дөресрәге, авторы – рәссам Нишә Бану икән бит бу гүзәл ханым! Искиткеч матурлык дөньясыннан гыйбарәт күргәзмәне карап чыгуга, рәссам тирәсенә җыелдык. «Казаннан, – дибез. – Татарлар...» Шул мизгелдә рәссамның йөзе картиналарындагы буяулардан да җетерәк булып яктырып китә. «Казаннанмы? Татарлармы? Сез минем кардәшләрем ләса! – дип, сөенечтән балкып, ул барчабызны берьюлы кочаклап алды. – Мин дә татар кызымын. Кырымтатар кызы. Истанбулда туганмын. Нәселем Бакчасарайдан. Сугыш башлангач, безнекеләр башта Румыниягә, аннан Төркиягә күченгәннәр».

Нишә Бану ханым белән сөйләшеп сүзләр бетмәде. 3 яшеннән, дәү әнисенең бирнә сандыгын мольберт сыйфатында файдаланып, рәсем ясый башлаганын да, 10 яшьләрендә портретлар ясауга һәвәсләнеп, үзләре яшәгән мәхәллә кешеләрен сурәткә төшереп бетерүе турында да, Мәрмәрә университетында башта немец филологиясе факультетында, соңрак шул ук университетның сәнгать факультетында белем алуы хакында да сөйләде ул. «Минем бер бабам хан сараенда нәкышче булган. Төркиядәге күп кенә сарайларны бабам – әниемнең әтисе Али Риза әфәнде бизәгән...» Милләтенә тартылуы бик көчле иде Нишә ханымның. Казанда күргәзмә оештыру хыялы да зур иде аның. Казанда күргәзмәсе әлегә күренмәде. Әмма Австриядә, Германиядә, Италиядә, АКШта, Швециядә һәм Европаның башка илләрендә 60 лап күргәзмәсе оештырылган, байтак эшләре шәхси күргәзмәләргә сатып алынган бу рәссам ханымның иҗатын Казанга китертәсе, аны татар дөньясы белән таныштырасы иде бит.

Үз иҗатында академизмны да, тыелгысыз һәм чикләнмәгән хыял байлыгын да оста файдалана белгән рәссам ханым үзенең иҗат өслүбен «спонтанлык», ягъни күңел түреннән, йөрәктән кинәт бәреп чыккан тойгыларның, аллы-гөлле буяуларга манылып, киндергә түгелеше сыман аңлатырга тырышса да, бу хисләр ташкыны озын гомерле булырга охшап тора.

Сәнгать белгече һәм философ Исмаил Туналы Нишә ханымның иҗатына мондый бәя бирә: «Дөньяны тойгылы хыял көче белән аңлаткан Нишә Бану рәсем техникасының хакимедер. Аның рәсемнәре һәр кешегә әңгәмәдәш була аладыр. Һәм Нишә Бану рәсемнәренең һичбер көндәше була алмастыр. Моңа ул чикләнмәгән, һич нигә буйсындырылмаган хыял егәре белән ирешә».

Аерылышканда без бергәләп фоторәсемгә төштек. Истәлеккә дип, сагынмаклык итеп.

Асия ЮНЫСОВА









НИШӘ БАНУ

PRESSA.RU

1 июльдән 2018 елның беренче яртыеллыгы өчен газета-журналларга язылу башланды



«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ИНДЕКСЫ П2204

Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар: 73002



ЯРТЫЕЛЛЫККА ЯЗЫЛЫРГА ӨЛГЕРМИ КАЛУЧЫЛАР ҺӘР АЙНЫҢ 15 НӘ КАДӘР ЯЗЫЛЫП, ЖУРНАЛНЫ КИЛӘСЕ АЙДАН АЛДЫРА АЛА!

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. **iPad** һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (**www.syuyumbike.ru**).

16+